ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№05 (400)
МАЙ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАНЛЫЛАР ЯЗМЫШЫНДА
БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ

4 612750 670011

№05 (400)
МАЙ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Хәмидә Гарипова, Илсөяр Закирова,
Әхмәт Шакиров, Ольга Туманская, Алсу Троицкая
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Бөек Ватан сугышы ветераннары.
Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе иркен

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-0812
Басарга кул куелды: 14.05.2025
Чыгу көне: 20.05.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

80 ҖИҢҮ КӨНЕ

Инде 80 ел буена май ае бездә Җиңү бәйрәме белән тәңгәлләшә. 1945 елда фашизмны тар-мар иткән солдатларның оныклары, оныкларының балалары сугыш турында барысын да белә. Яшенә карамыйча, чөнки алар – җиңүче бабаларының нәсел дәвамчылары. Бөек Ватан сугышының каһарманнары инде үзләре исән булмаса да, фотографияләре, күкрәк билгеләре, бүләкләре һәр гаиләдә кадерләп саклана. Һәр орден белән медаль – Татарстаныбыз героеның язмышы ул.

«4 елга сузылган сугыш һәм 80 ел буена Җиңү көнен бәйрәм итү – күбрәк түгелме?» – дип сукрана безне өнәмәүчеләр.

Ә без болай дияр идек: 1418 көн сугыш өчен, 80 Җиңү көне – азрак түгелме?

Сугышның һәр көне бер Җиңү көненә тиңдер. Шуңа күрә бездә һәр май – җиңүле.

Фашизм ерткычлыкларын онытмас өчен.

Халыкның каһарманлыгын хәтердән җуймас өчен.

Тынычлыкны саклар өчен.

Сезнең май редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп биреше,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп биреше,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

ҖИР АСТЫ ПАТШАЛЫГЫ «СӨЕМБИКӘ»СЕ

Казан метросының шәһәр меңьеллыгы алдыннан эшләп киткән беренче тармагы ачылышы белән «Алтынчәч», «Полина», «Ольга», «Катюша» һәм «Сөембикә»ләргә бурычлы. Тоннель казый торган куәтле комплекслар әлеге нәфис хатын-кыз исемнәре белән аталган. Алар кыска гына вакыт эчендә җир астыннан 8,7 километрны узарга мөмкинлек бирә, ягъни беренче биш станция арасын. Барысыннан да алдарак Тукай белән Сукно бистәләре станцияләре арасындагы токымны «Сөембикә» ватарга керешә. 2000 елның 22 маенда була бу хәл. Казан үзәгендәге җир асты юлларын төзи башлауга багышланган тантанадан соң өч ел узгач. Ул чакта истәлек ротондасы нигезенә киләчәк буыннарга хат салынган капсула да күмеп калдырыла.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

мәңгелек кыйммәтләр

6. Җиңү солдаты
Ветеран нәрсәләр турында сөйләде

9. Рейхстаг өстендәге байрак
Сержант Гази Заһитов аны кайчан урнаштырган

12. Балалар шагыйре һәм фашизм
Абдулла Алиш батырлыгы

13. Васыять хаты
Гадел Кутуй улына нәрсә язып калдырган

16. Дошманны дер калтыраткан комдив
Беренче булып кем немец генералын әсирлеккә алган

18.Казандагы «шарашка»
Сергей Королёв өчен фронт сызыгы кайда булган

22. Константин Заслонов отрядында
Татар шагыйре ничек разведка башлыгына әйләнгән

23. Биеклек хуҗасы – бәрелеш хуҗасы
Немецны күктә дә, җирдә дә кыйнаган каһарман

24. Бер сугыш – ике язмыш
Геройлар ничек туа

26. Көнчыгыш форт сакчысы
Кемнең батырлыгына хәтта дошман да сокланган

28. Үлем лагерен җиңгән очучы
Әсирлектән ничек кача алганнар

30. Очучылар мәктәбе
Кечкенә малайлар ничек бөркетләргә әйләнгән

36. Мәхмүт Гәрәевнең алты сугышы
Бөек стратег булып җитешкән солдат турында

40. Казан каймасы
Окоп казулар кайда оештырылган

42. Фронтка хат
Татарстанлылар якташларына нәрсә турында язган

43. Берлин урамындагы бәрелешләр
Соңгы югалтулар исемлегендә кемнәр бар

44. Мәңгелеккә калган имза
Рейхстаг диварында кем үзен язып калдырган

45. Икенче номерлы яшерен лаборатория
Атом бомбасын кайда ясый башлаганнар

50. Иң шатлыклы көн
Казанда Җиңүнең беренче көнен ничек билгеләп үткәннәр

52. Үлемсез шигырьләр
Моабит дәфтәрләре илгә ничек әйләнеп кайткан

54. Сугыш рәсемнәре
Рәссам аларны кайчан ясаган

56. Берлиндагы Җиңү байрагы фотосы
Әлеге үлемсез фотоның авторы кем

62. Хәтер йомгагы
Якташларыбыз нинди батырлыклар кылган

66. Җиңүгә без керткән өлеш
Сугыш кырларыннан күпме татарстанлы әйләнеп кайтмаган

76. Гамьле әңгәмә
Әлфия Айдарская: «Үз миссиямне үтәдем дип саныйм»

80. Әдәби сүз
Тылда ничек яшәгәннәр

84. Китап киштәсе
Сугыш турында нинди әсәрләр язылган

Фото: knigarekordovrossii.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

21.04

Марат Хөснуллин, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме җитәкчелегенең ИХО дәүләтләре илчеләре белән очрашуында:

– Без халыклар арасында тынычлык һәм татулыкның кадерен белергә, туганлык элемтәләрен ныгыту өчен бөтен көчебезне куярга тиеш. «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме багланышларын алга таба киңәйтү, тирәнәйтү безнең күп юнәлешле хезмәттәшлекне ныгытуда төп фактор булыр, дип ышанабыз.

10.04

Илсур Метшин, Казан мэры, – Казан һәм Иран шәһәре Исфахан арасында тугандашлык мөнәсәбәтләре урнашу турында килешүгә кул куйганнан соң:

– Исфахан – дөньядагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Казан бераз яшьрәк, безгә мең генә яшь әле. Шуңа да карамастан, безне Бөек ефәк юлы бәйли, кайчандыр ата-бабаларыбыз актив хезмәттәшлек иткән. Үзара мөнәсәбәтләренең яңа битен ачу минем өчен бик зур мәртәбә. Һәм ул уңышлы, үзара файдалы булсын, шәһәрләребез үсешенә яңа этәргеч бирсен.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

14.04

Сергей Рыжиков, космонавт, – орбиталь станциядән «Мәскәү – Татарстан» Мәскәү яшьләр форумында катнашучыларга мөрәҗәгать итеп:

– Яшьләрнең үз тамырларын белүе сөендерә. Борынгы Бөгелмә шәһәрендә тууымны тою минем өчен бик кадерле. Нәкъ менә шундый зур булмаган, ләкин күңелгә якын калалар безнең иксез-чиксез илебезнең көчен һәм бөеклеген тәшкил итә дә.

Фото: tatar-inform.ru

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

төп тема

Бу санда тәкъдим итәбез:

Сугышка **ничек** китәләр

Дошманга каршы **ничек** көрәшәләр

Фашизмны **ничек** җиңәләр

Дөньяны **ничек** азат итәләр

Туган якка **ничек** кайталар

Җиңүне **ничек** бәйрәм итәләр

Фото: tatar-inform.ru

ҖИҢҮ ЯУЛАГАН СОЛДАТЛАР: ЯЗМЫШЛАР, МИЗГЕЛЛӘР

Басмабызның май саны Җиңү тарихын язучыларны искә алуга багышлана. Кемгәдер рейхстагта автографын калдыру насыйп була, кемнәрдер сугышның беренче көннәрендә үк яу кырында ятып кала, кемдер фашист концлагерьларының бөтен кыргыйлыгын татый, ә кемдер, Европа уртасына барып җиткәч, Берлин урамнарында һәлак була... Төрле язмышлар... Араларында бәхетлеләре дә, фаҗигалеләре дә бар, ләкин алар барысы да – тереләр һәм үлеләр – Җиңү солдатлары... Язмаларыбыз алар турында.

Фото: Александр Ефремов

«ӘТИ СҮЗЕННӘН ЧЫКМАДЫМ...»

Руфия Фазылова

Китәләр... Бөек Ватан сугышы ветераннары елдан-ел кими. Кеше гомере санаулы гына шул. Бүгенге көндә исән-сау булган ветераннарның да күбесе Җиңү бәйрәменә бара алмады, сәбәбе яхшы аңлашыла – картлык. Тик, шөкер, арада егәрен югалтмаган ветераннар да бар. Батырлык өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Харис Салихов әнә шундыйларның берсе.

«ТУГЫЗ КЛАСС БЕЛӘН СУГЫШКА АЛДЫЛАР»

Харис Салихов хәрби хезмәткә унсигез яше тулганчы ук алына. Башта яшь егетләрне элемтәче булырга укыталар, аннан сугышка җибәрәләр.

– Ул чагында безнең кебек «укуы» булган егетләрне хәрби хезмәткә чүплиләр генә иде, – дип, хатирәләре белән бүлеште Харис абый. – Арча педучилищесының икенче курсында укыганда военкоматка чакырдылар. «Егет, сиңа вакыт», – диделәр. Тугыз сыйныф белеме булган егерме егетне элемтәчегә укытырга дигән боерык булган. Мәктәпнең җиде классы, педучилищеның ике курсы, барысы тугыз класс булып санала иде. Әнә шулай, салам матрасны бушатып, әйберләрне тулай торакның комендантына калдырып, өйгә кайтып киттем.

Сугыштагы хәлләрне сөйли китсәң, көн генә җитмәс. Бер генә очракка мисал китерәм: 1945 ел, Австрия, Дунай елгасы. Күпер аша элемтә чыбыгы суздык. Эшне бетергәч, янә чыбыкны ялгарга дигән приказ булды – төнлә немецлар күперне шартлаткан, элемтә өзелгән. Сафка тезелеп, командирның кемне сайлаганын көтәбез. Беребез дә куркак түгел, ләкин барыбызның да яшисе килә – кырык метрлап өскә менәргә кирәк, фашистларның атып үтерәселәре көн кебек ачык. Командир көр тавыш белән: «Үз теләге белән алынучылар бармы?» – дип сорады. Шунда Саратов өлкәсендә элемтәчегә бергә укыган дустым Сәгъдулла сафтан чыкмасынмы! Һәм ике дә уйламыйча:

– Үземә ярдәмгә Харисны чакырам, – диде.
– Ә ник аны? – ди командир.
– Ул Аллага ышана. Мин күпергә менәм, ул астарак чыбык төргәген сүтеп торыр. Һәм Алладан минем исән калуымны сорар.

Командир елмаеп куйды һәм безгә приказны үтәргә боерды.

Сәгъдулла пулялар яңгыры астында чыбыкны ялгады. Аның ничек елан кебек бормаланып хәрәкәт итүен күрсәң, ис китәрлек. Барыбыз да җиңел сулап куйдык. Әнә шул вакытта Аллаһы Тәгалә безне ярдәменнән ташламады.

«ӘТИГӘ БИРГӘН ВӘГЪДӘМНЕ ҮТӘДЕМ»

Харис Салихов гомере буена Аллаһка таянып яши. Сугышка киткәндә этисе аңа шундый әманәт әйтеп җибәрә. Әнә шул догалар аны берничә тапкыр үлемнән алып кала. Һәм бүгенгәчә саклап йөртә кебек.

– 1944 елның декабрь башы, авылдашым Сәйфетдин белән сугышка китәбез, – дип дәвам итте хөрмәтле ветеран. – Әти безне ат белән озата барды. Зиратка җиткәч, атын туктатты да: «Улым, дөнья хәлен белеп булмый. Менә монда әбиең, башка бик күп туганнарың, авылдашларың ята. Аларның исемнәренә тап төшерәсе түгел. Командирыңны тыңла. Тәртипле булсаң, бәлки исән кайтырсың», – диде. «Әти, борчылма, синең сүзеңнән чыкмам. Син минем өчен әүлия», – дидем мин. «Бездә әүлияләр юк, бөтен кеше дә гөнаһлы. Мин сиңа һәр көн дога кылып торырмын, син дә намазыңны калдырма», – дип җавап кайтарды ул. Әтигә биргән вәгъдәне үтәдем.

Салих абыйның этисе Салихҗан Гыйбадулла улы үзе дә Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайта. Балтач районы Чутай авылының гыйлемле, алдынгы карашлы кешесе була ул. Балаларын белемле, динле итеп тәрбияли. Салих абый бүген дә этисен бик зур хөрмәт белән искә ала:

– 1941 елның сентябрендә этигә сугышка китәргә чакыру килде. Алар авылдан берничә кеше иде. Ул көнне һич онытмыйм: олы юл кырыена сугышка китәсе кешеләр җыелды. Озатучылар бик күп иде. Әнкәй коймак пешереп алып килде. Мулла абзый белән шунда бергәләп намаз укыдык. Аллаһтан хәерле сәфәрләр сорап, сугышка китүчеләрне озатып калдык. Алар башта Суслонгерда булган. 1941 елның азагында Мәскәү янына җибәргәннәр.

Әти 1942 елны сугыштан яраланып кайтты. Сул кулы скелет шикелле асылынып тора иде, исләнеп беткән... Мазь-фәлән, димим, яраны юарга сабын да юк. Әни, селте сулары ясап, этинең кулын төзәтте. Әти миңа: «Безнекеләр барыбер җиңә, менә күрерсең. «Кәтүшә» дигән машина уйлап тапканнар. Үз күзләрем белән күрдем: снарядларны секунд эчендә җибәрә», – дип сөйләде. Аннары колхозга эшкә чыкты. Әтинең миңа рухи йогынтысы турында сөйләп бетерә торган түгел. «Шул атаңны Сталиннан да зур күрәсең инде», – дип әйтә иде нәнә (әни). Сугыштан кайткач, эти бер фикер әйтте: «Татар үз илендә берсе икенчесенә көнче, ә менә татар иленнән аерылса, аз булсалар, ул очракта берсе икенчесенә туган», – диде. Чөнки сугышта бөтен татарлар дус-тату булып, ярдәмләшеп торган.

Харис абый бүген балаларының зур игътибарын тоеп яши. Кызы белән кияве көн саен янына килеп йөри.

НАМАЗ БЕЛӘН УЗГАН ГОМЕР

Харис абый сугыш вакытында да намазын калдырмый. Берсендә, татар егетләренең бергәләп сәҗдәгә киткәнен күргәч, командирлары килә: «Нишлисез сез?» – ди ул, аптырап. «Богу молимся», – ди яшь солдат. Шуннан Харис Салихов командирына бәйнә-бәйнә аңлата: «Сезнең исәнлек, үзебезнең исәнлек өчен дә «Бог»тан сорыйбыз...» Командир шактый гына карап торганнан соң: «Просите, просите», – дип китеп бара.

– Дин иреге булмаса да, гомер буе иман белән яшәдем, Аллаһка шөкер, – дип дәвам итте ветеран. – Сугыштан кайткач та намазны калдырмадым. 1990 нчы елларда авыл саен мәчетләр төзелә башлагач, ничек сөенгәнемне белсәң! Югыйсә минем һөнәр кайда да, дин кайда: утыз ике ел милициядә эшләдем. 1970 нче елларда Казан шәһәренең Совет районы эчке эшләр бүлегендә җитәкче урынбасары да булдым.

Олыгаеп барганда күңел кушканча эшләдем: 1993 елда Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары Мөселман мәдрәсәсен тәмамладым. Һәм шуннан соң мине ТР мөселманнарының Диния нәзарәтенә рәис урын-

басары итеп куйдылар. Бүгенге көнгә кадәр ТР Эчке эшләр министрлыгына караган «Хәтер» мәчетенең имам-хатыйбы булып торам.

«ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕН БИРҮНЕ ДИН БЕЛӘН ФӘН БЕРГӘЛЕГЕН ТАНУ ДИП КАБУЛ ИТТЕМ»

Алда әйтелгәнчә, Харис Салихов Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлеге мәртәбәле исемне аңа «Дин вә фән» исемле китабы өчен 2017 елда бирәләр. Бөек Ватан сугышы ветераны бу китабын унбиш ел әзерли. Дөрес, үзе генә түгел, күп галимнәрне дә җәлеп итә. Ә иң төп ярдәмчесе – Америкада яшәүче улы.

– Китап язарга алынганда, Тукай премиясенә тәкъдим итәрмен дип башыма да китермәгән идем, – ди Харис Салихов. – Төп максат Габдулла Тукай, Александр Пушкин иҗатында Коръәннең, дини мотивларның чагылышын ачыклау иде. Бу теманы ныклап өйрәнү өчен улымның ярдәме белән Америкага барып, анда да тикшеренергә насыйп булды. Ул китапта баланы, ата-ананы дини һәм дөньяви мәдәниятләр нигезендә тәрбия кылу ысуллары тәкъдим ителә. Эшемне тарихчы Рафаэль Хәкимов, Энгель һәм Индус Таһировлар, Әнвәр Хуҗиәхмәтов, Айдар Хәлимнәр бәяләде. Тукай премиясен бирүне дин белән фән бергәлеген тану дип кабул иттем.

Совет хакимияте юк ителгәч, илдә идеология калмады. Үзләренә кыйбла таба алмаган кешеләр саны көннән-көн артты. Бу шартларда кешеләрнең әхлакый дәрәҗәсен дин вә фән белән генә күтәреп була иде. Әгәр тарихка күз салсак, күп аллалык чорында ук халыкны бер Алла тирәсенә җыярга тырышканнар. Безнең эрага кадәр яшәгән галим Аристотель, галәм сукыр бер очрак, могҗиза көче яисә күп алла тарафыннан идарә ителми, ә югары көчнең рациональ законнарына буйсына, дип әйтеп калдырган. Гасырлар үтү белән, гарәп дөньясы зур алгарыш кичерде. Җәдитчеләр динне фән белән дә аңлата башлады. Әл-Хәрәзми, Әбүгалисиналар дин белән фәннең бергәлегенә хезмәт итте.

Бу бергәлек минем аңыма әтием тарафыннан сеңдерелде. Мәктәптән кайткач, әтинең беренче соравы: «Нинди дәрес үттегез?» Пушкин, дисәң, аның Коръән турындагы шигырен укып күрсәтә. Тукай, дисәң, халык шагыйребезнең иҗатында дини тема яктыртылышы турында сөйли. Минем беренче фәнни эшем дә Габдулла Тукай, Александр Пушкин иҗатларын өйрәнүгә багышланды. Ул вакытта шагыйрь атеист дип сурәтләнә, дини шигырьләре дөнья күрмәгән иде. Тукайның «Күктәге пар йолдыз кебек дин белән фән тора» дигән шигъри юллары хезмәтемнең төп принцибы булды. Татар фикере белән аңлатканда, дин ул – вөҗдан, фән ул – аң. Аларның икесе дә тигез булганда гына тәрәккыяткә ирешеп була. Тукай шушы тәрәккыят өчен көрәшче булган.

БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК

Харис абый бүген балаларының зур игътибарын тоеп яши. Кызы белән кияве көн саен килеп йөри. Ә оныгы Алинә күрше фатирда гына тора икән. Кадерле кешеләрен үзен генә бик калдырырга тырышмыйлар, ни дисәң дә, туксан сигез яшь бит!

– Бабай үзен карт дип күрсәтәсе килми, – диде Алинә. – Һаман да егетләр егәре белән йөрисе килә. Тик яшь бара шул. Соңгы арада кан басымы уйный, шуңа ялгызын урамга бик чыгармыйбыз. Ә үзенең гел йөрисе килеп тора. Җиңү бәйрәменә дә алып бардык. Ничә көн алдан җыенды. Әйтәм бит, кеше арасында буласы килә аның.

Чынлап та, Харис абый тынгысыз, җор телле кеше. Әледән әле шаяртып ала, «матурым» дип кенә сөйләшә. Тугызынчы май алдыннан игътибар аеруча күп булган үзенә: атна саен журналистлар килгән. Ул һәркайсыбызга шат, истәлекләре белән бүлешергә әзер. Саубуллашканда, дога кылды һәм болай диде:

– Биш үлемнән калдым. Биш тапкыр һөҗүм иттеләр, икесе сугышта, аннары милициядә эшләгәндә, бер тапкыр мәчеттә үтергәнче кыйнап киттеләр... Барысыннан соң да аякка бастым. Бүген дә үземне әйбәт хис итәм. Билгеләнгән табибларым бар, алар әйткәнне төгәл үтим. Майлы, баллы ризыклар бөтенләй ашамыйм. Гомер буе тәмәке тартмадым, аракы эчмәдем. Аллаһ кушканча яшәдем. Әнә шулар барысы да һаман сафта булырга ярдәм итәдер...

«КҮЗГӘ ЧАК ШӘЙЛӘНӘ ТОРГАН МАНАРА ЯНЫНДА ЗАҺИТОВ БЕЛӘН МИН КЫЗЫЛ БАЙРАКНЫ БЕРКЕТӘ БАШЛАДЫК...»

Берлин. 1945 елның 30 апреле. Җирле вакыт белән 22 сәгать 40 минут. Өлкән сержант Гази Заһитов һәм сержант Михаил Минин рейхстаг өстенә кызыл байракны – Җиңү байрагын беркетәләр...

Фотода: капитан В. Н. Маков төркеме сугышчылары. Сулдан уңга: сержантлар М. П. Минин, Г. К. Заһитов, А. П. Бобров, А. Ф. Лисименко.

Беренче булып рейхстаг өстенә байракны Михаил Егоров һәм Мелитон Кантария күтәрмәгәнлеге сугыштан соң дистә еллар узгач кына билгеле була. Аңлашылмаучанлык 150 нче укчы гаскәр командиры генерал Василий Шатиловның җиңүле донесениесе аркасында килеп чыга: 30 апрельдә үк ул командованиегә рейхстаг алынуы һәм аның өстенә Җиңү байрагы беркетелүе турында ялгыш хәбәр юллый.

Җиңү турындагы хәбәр өстәгеләргә барып ирешсә дә, рейхстаг өчен сугышның әле кызган чагы гына була. 30 апрель кичендә генә капитан Владимир Маков җитәкчелегендәге штурмлау төркеме ут астында рейхстаг түбәсенә чыга. Төркемгә Гази Заһитов, Александр Лисименко, Алексей Бобров, Михаил Минин керә.

Үзәк фасад, «Германия» скульптура төркеме өстендә Минин һәм Заһитов кызыл байрак беркетеп куя. Маков рация буенча бу турыда җитәкчелеккә кыска гына хәбәр җибәрә.

Ләкин иң югарыга, Сталин белән Жуковка, бу юлы донесениене берәү дә җиткерми, чөнки иртәнге ялгыш хәбәр өчен башың белән җавап бирергә туры килергә мөмкин. Шуның аркасында рейхстагка Җиңү байрагын беренче булып күтәргән сугышчыларны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итүгә дә юл куелмый. Аларның барысына да Кызыл Байрак ордены тапшырыла...

Икенче көнне, 1945 елның 1 маенда, сугыш тынгач, сержантлар Михаил Егоров һәм Мелитон Кантарияны икенче байрак белән рейхстаг гөмбәзенә үткәрәләр. Икесенә дә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Безнең көннәрдә РФ Оборона министрлыгының Хәрби тарих институтында Җиңү байрагын күтәрүгә кагылышлы барлык архив документларын тикшерәләр. Нәтиҗә мондый: рейхстаг түбәсенә беренче булып кызыл байракны капитан Владимир Маков төркеме беркеткән. Институт ул вакытта биш сугышчыга Россия Федерациясе Герое исемен бирү (үлгәннән соң) турындагы үтенечен хуплый...

Эш ничек була соң? Михаил Минин истәлекләреннән: «Алдан үзе белән фонарь элләктергән Гази Заһитов йөгерде. Ярымҗимерек баскычны ул яктыртып барды. Без баскычка чыга торган бөтен коридорларга гранаталар тондырып, автоматтан атып, тикшерә бардык... Мин чормага чыга торган урында, байракның тоткасына дип, стенадан метр ярым озынлыктагы нәзек торба йолкып алдым. Иркен чормага эләктек, тик түбәгә ничек чыгарга дигән проблема туды. Бу юлы да Заһитов коткарды: фонаре белән йөк чыгырын һәм каядыр югарыга сузылган ике зур чылбырны күреп алды, шуларны яктыртты. Чылбырга ябышып, ишетү тәрәзәсе аша бинаның көнбатыш фронтоны өстендәге түбәгә чыктык.

Күзгә чак шәйләнә торган манара янында Заһитов белән мин кызыл байракны беркетә башладык. Кинәт түбәдә шартлаган снаряд яктысында Лисименко без көндез үк билгеләп куйган ориентир – ат белән алагаем зур хатын-кыздан торган бронза скульптураны күреп алды. Байракны шул хатынның башындагы таҗына беркетү яхшырак дигән карарга килдек. Егетләр мине снаряд һәм миналар ярылудан дерелдәп торган атның койрык өстенә утырттылар, һәм мин байракны бронза хатынның таҗына беркеттем... Вакытны билгеләп куйдык. Җирле вакыт белән 22 сәгать 40 минут иде».

БЕЛЕШМӘ:
Гази Заһитов, татар, БАССРның Яңагыш авылында туып-үсә. РККА сафларында – 1940 елдан. Фронтта – беренче көннән. 3 нче удар армиянең 79 нчы укчылар корпусы 136 нчы армия туп-артиллерия бригадасының разведка төркемендә сугыша. Берлин өчен сугышларда рейхстагны алу һәм кызыл байрак беркетү өчен ирекле­ләрдән төзелгән штурм төркемнәренең берсенә керә. II һәм III дәрәҗә Дан, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, «Батырлык өчен», «Сугышчан казанышлар өчен» медальләре белән бүләкләнә. Сугыштан соң туган авылында колхоз рәисе, МТСта механик булып эшли. 1953 елда юл һәлакәтендә вафат була.

Фото: oeru.ru

ВТБ ТАТАРСТАНДА ГЕОГРАФИЯСЕН КИҢӘЙТӘ

Дмитрий Сивков

2025 ел башыннан республиканың берьюлы биш шәһәрендә заманча һәм уңайлы ВТБ офислары ачылды. Хәзер халкы 20 меңнән арткан кечкенә шәһәрләрдә яшәүчеләр дә янәшәдә генә урнашкан банк хезмәтләреннән тулысынча файдалана ала.

КЛИЕНТЛАРНЫ КАЙГЫРТЫП

Илнең теләсә кайсы почмагында да финанс хезмәтләре күрсәтүне яхшырту өчен, ВТБ үзенең физик бүлекләре челтәрен киңәйтә. Әлеге планнарын тормышка ашыру максатыннан, ВТБ «җиңел» офисларның яңа форматын эшләгән. Зур булмаган мәйданда аз чыгым сарыф итеп ачылган бу нокталарда банкта күрсәтелә торган барлык хезмәтләрне дә алып була. Менеджерлар продуктлар һәм хезмәт күрсәтү сораулары буенча консультация бирә, цифрлы сервисларны көйләргә, лояльлек программасына кушылырга булыша.

ВТБда әйтүләренчә, 2026 ел азагына кадәр челтәрне шактый киңәйтү планлаштырыла. Бу 100 миллионлап россиялегә банк хезмәтләрен күрсәтү мөмкинлеге тудырачак. Банк бүлекләре матур, үзенә дәшеп тора торган һәм уңайлы: һәркайсында су кулерлары, каһвә станцияләре куелган һәм бушлай Wi-Fi бар. Яңа хезмәт күрсәтү нокталарына хәтта йорт хайваннары белән керү дә рөхсәт ителә. Моннан тыш, ВТБ клиентларга ял көнендә дә хезмәт күрсәтүне кертә – бүген инде бүлекләр челтәренең яртысы шимбә көнне дә эшли.

180 ТОРАК ПУНКТНЫ ИНДЕ ҮЗ КОЛАЧЫНА АЛГАН

Татарстанда ВТБ офислары челтәрен киңәйтү процессы шактый актив бара. Элегрәк банк үз бүлекләрен зур шәһәрләрдә генә ачса, узган елдан бирле яңа заманча хезмәт күрсәтү нокталары халык саны 20 меңнән арткан шактый кечкенә торак пунктларда да пәйда була башлаган. «Җиңел» офислар белән беррәттән, ВТБ мультиформаттагы бүлекләр дә ача – аларының мәйданнары зуррак, физик затларга гына түгел, бизнес даирәсендәге клиентларга да хезмәт

ВТБ банкының матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА. «ВТБ Банк» ГАЖ

ОЦЕНИВАЙТЕ СВОИ ФИНАНСОВЫЕ ВОЗМОЖНОСТИ И РИСКИ

күрсәтелә. Яңа бүлекләр халыкка уңайлы урыннарда ачыла. Кагыйдә буларак, бу – шәһәр һәм бистә үзәкләрендәге халык та, транспорт та аеруча күп йөри торган урыннар.

– Безнең өчен яңа офисларны аларга ихтыяҗ зур булган җирдә ачу мөһим. Былтыр «җиңел» офислар Зәйдә һәм Менделеевскида ачылды. Мультифункциональ бүлекләр Түбән Кама һәм Чаллыда эшли башлады. Ә 2025 елның беренче кварталында яңа сату нокталары инде Татарстанның алты шәһәрендә – Азнакай, Арча, Яшел Үзән, Кукмара, Нурлат, Буада ачылды. Бүген банкның төбәктәге челтәрендә, Почта Банк офислары белән бергә, 54 бүлек исәпләнә, – дип сөйләде ВТБның Татарстандагы идарәчесе – банкның вице-президенты Мәрьям Дәүләтшина.

Аның әйтүенчә, офислар челтәрен киңәйтү республикабыз халкына финанс хезмәтләре күрсәтүне яхшырту мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, күптән түгел Буада ачылган офис шәһәрнең үзендә һәм Буа районында яшәүчеләргә генә түгел, күршедәге Апас, Иске Чүпрәле, Тәтеш халкына да хезмәт күрсәтә ала. Мәрьям Дәүләтшина тагын шуңа да тукталды: ВТБ банк продуктларын өйгә кадәр китереп бирү хезмәтен дә республикабызда актив үстерә икән.

– Бүген каядыр барып хезмәт күрсәтү сервисы инде республика территориясенең 80 процентка якынын колачлый, ВТБ курьерлары безнең продуктларны Татарстандагы 180 нән артык торак пунктка илтеп җиткерә. Әлеге сервистан файдалану бик гади: сайтта гариза тутыргач, менеджерлар уңайлы вакытта килеп җитәчәк, дебет һәм кредит карталарын ачарга, эш хакы һәм пенсияне ВТБга күчерергә булышачак, шулай ук цифрлы сервисларны көйләячәк һәм барлык финанс мәсьәләләре буенча консультация бирәчәк, – ди ВТБ ның Татарстандагы идарәчесе – банкның вице-президенты.

ТҮБӘН КАМА, ЗӘЙ, МЕНДЕЛЕЕВСК, БУА – ЙӘ, ТАГЫН КАЙДА?

ВТБ ның Татарстандагы яңа офислары адресларына күз салыйк.

Түбән Кама. Түбән Кама – куәтле сәнәгать кластеры булган перспективалы шәһәр, анда халык саны тиз арта, финанс хезмәтләренә ихтыяҗ зур. Корабельная, 53 адресы буенча «Парус» Сәүдә үзәгендә урнашкан мультифункциональ офис – ВТБның шәһәрдәге икенче бүлеге.

Заманча һәм уңайлы офис актив үсештәге торак районда урнашкан.

Зәй. ВТБның «җиңел» офисы үзәктә – Чапаев урамындагы 2 нче йортта урнашкан. 40 меңләп кеше яшәгән район үзәгендәге яңа бүлекне шәһәр халкы яратып та өлгергән инде. Офиста ике хезмәткәр эшли, алар клиентларга ноутбуклар ярдәмендә хезмәт күрсәтә. Килүчеләр үзләренә ошаган уңайлы урынга утыра ала, белгеч аларның һәркайсына финанс продуктларының кирәклесен сайларга ярдәм итә.

Менделеевск. ВТБ офисы шәһәр халкы арасында популяр урында – Бурмистров урамы, 2 нче йортта урнашкан. Янәшәдә генә – район хастаханәсе, «Юность» кинотеатры, Гассар исемендәге мәдәният йорты. Белгечләр дебет һәм кредит карталарын ачарга, кредит алырга, мобиль кушымтаны җайларга булыша, хезмәт күрсәтүгә караган сорауларга җавап бирә.

Азнакай. ВТБ бүлеге шәһәр үзәгендә, Ленин урамындагы 21а йортында урнашкан. Клиентларга уңайлы шартлар тудырылган, хезмәткәрләр кертем, займ, дебет һәм кредит карталарын алырга булыша.

Арча. ВТБ офисы үзәк мәйдан һәм муниципалитет хакимияте янәшәсендә, Комсомол урамындагы 1 нче йортта урнашкан. Халык «җиңел» офисның өстенлекләрен бәяләп өлгергән инде: уңайлы мохит, ВТБ продуктлары һәм хезмәтләренең тулы спектры – бердә финанс мәсьәләләре хәзер иң заманча дәрәҗәдә хәл ителә.

ВТБ офисларының күпчелеге үзәктә урнашкан, моңа игътибар иткәнсездер. Банкның стратегиясе дә нәкъ шунда бит – һәркем өчен файдалы булу. Кукмарада офис Ленин урамындагы 11а йортында, шәһәрнең үзәк мәйданы янәшәсендә, Нурлатта исә үзәк парк янында – Совет урамы, 113 нче йортта урнашкан.

Банкта яңа бүлекләр шәһәрләр һәм алар янындагы районнар халкында популяр булыр, аларның үсешенә үз өлешләрен кертер, дип ышаналар. Т

АБДУЛЛА АЛИШ. «БЕЛӘМ, КАЙГЫҢ ЗУР, ӘММА ТЫНЫЧ БУЛ – ИСӘН КАЛСАМ, КАЙТАМ...»



Балалар өчен гаҗәеп әкиятләр иҗат иткән язучыны Плётцензее төрмәсендә җәзалап үтерәләр. 2968 номерлы әсирнең карточкасында төрмә хезмәткәре битараф кына: «Үлеменең сәбәбе: башы киселү» дип теркәп куйган.

Абдулла Алиш хатыны Рокыя, уллары Алмаз һәм Айваз белән.

Концлагерьның 2968 номерлы әсире татар халкының сөекле язучысы Абдулла Алиш була. Кыска гына гомере эчендә (1908 елның 15 сентябрендә туа) төрле өлкәләрдә хезмәт куярга өлгерә: мелиоратор да була, КазГРЭС төзелешендә десятник та, журналист та. Ниһаять, профессиональ язучы булып җитешә. 1939 елда Муса Җәлил, Алишка характеристика биреп, болай яза: «Язучы Абдулла Алиш әсәрләре теленең җиңеллеге, мавыктыргыч һәм һәрчак эчтәлекле булуы белән аерылып тора...»

Алиш балалар өчен яза. «Бөтен иҗатымны балаларга бүләк итәргә телим», – дия ул. 1940 елда «Ана әкиятләре» китабы дөнья күрә – татар әдәбиятының алтын фондына кергән җыентык. Берничә мәртәбә рус телендә дә басыла.

Әкиятче Алиш 1941 елда үз теләге белән сугышка китә. Фронттан язган хатларының берсендә ул әнисенә болай мөрәҗәгать итә: «Беләм, кайгың зур, әмма тыныч бул – исән калсам, кайтам. Әле куанычлы очрашулар да булыр, туганнар да җыелыр...»

Табигате буенча оптимист Алиш, язуын-яза да, ләкин бу очрашуның буласына үзе үк ышанмый, диярсең. Тагын мондый юллар да өсти: «Әнием, сиңа зур һәм соңгы үтенечем бар: минем балакайларны, үземне тәрбия кылгандай, иркәләп, кайгыртып тор, хәлләрен белеп яшә...»

Алиштан хатлар октябрьдә өзелә: хәбәрсез югала... Еллар узгач, сугыш тәмамлангач кына, беләләр: Брянск фронтында сугышкан, әсирлеккә эләккән. Аннан соң – концлагерьлар: Литвада, Польшада, Германиядә. Соңгысында – Җәлил белән очрашу. Җәлил аңа үзенә ышангандай ышана.

«Идел-Урал» легионында шулай итеп яңа кеше пәйда була – «тәрҗемәче». Бу версия – «хуҗалар», ягъни немецлар өчен. Җәлил белән көрәштәшләре өчен – тагын бер «үз» кеше, подпольщик. Аннары инде батальоннарны бер-бер артлы партизаннар ягына чыгару буена яшерен оешманың хәвефле эшчәнлеге башлана.

Җәлил, Алиш һәм яшерен оешманың башка әгъзаларын легионерлар фетнәсен күтәрер алдыннан кулга алалар. Аннан соң – Моабит төрмәсе. Кыйнау-җәзалаулар, сорау алулар...

1944 елның башында Абдулла Алиш тоткынлыктан иреккә хәбәр юллауга ирешә. Анда ул барысының да дәүләткә янаучы җинаятьчеләр буларак кулга алынуларын, судны көтүләрен әйтә. Алиш дусларына сәламнәр юллый, бәхет һәм шатлык тели, кем дә булса сугыштан исән әйләнеп кайтса, улларын аның өчен кочаклап үбәргә васыять әйтә...

Яшерен оешмада катнашучыларны 1944 елның 25 августында Берлинда Плётцензее төрмәсендә җәзалыйлар. Төрмә чиновнигы Глюк әсир Алишның төрмә карточкасында 2968 нче номерны терки һәм болай язып куя: «Берлин. Шарлоттенбург. 26 август, 1944 ел. Язучы Абдулла Алишев, мөселман. Казанда, Дзержинский урамы, 18-19 адресы буенча яши. Вафат булды: 1944 ел, 25 август, Берлин, Шарлоттенбург, Кенигсдамм, 7. 1908 елның 15 сентябрендә Көектә туган (Россия). Үлеменең сәбәбе: башы киселү».

P.S. Төрмәдә башта – суд көнен, ә аннан соң җәза көнен көткәндә, Абдулла Алиш шигырьләр язган. Аның блокнотларының берсе (15 шигырьне туплаган), дистәләгән куллар аша үтеп, элеккеге әсир Нигъмәт Терегулов кулына эләгә. Ул аларны ватанга алып кайта. «Без – әсирлектә, әмма барыбер сугыш эчендә, – дип яза әкиятче Алиш, үләренә санаулы гына көннәр калганда. – Ни генә булмасын, үлемне без кыю, күзенә карап каршыларбыз. Гомеребезне Ватан өчен биреп, аның изге җиңүе хакына һәлак булырбыз».

Фото: «Сөембикә» журналы, 2008, 8 нче сан

«ӘГӘР ПУЛЯ МИНЕ САЙЛАСА, СИН БУ ХАТНЫ АЛЫРСЫҢ...»

«Әниеңнән бу хатны саклавын һәм сиңа егерме яшь тулган көнне тапшыруын үтендем... Әгәр пуля мине сайласа, син бу хатны алырсың. Менә сиңа егерме яшь тулды да. Котлыйм, улым! Әйдә, ирләрчә кочаклашыйк...»

Яулар арасында хәл җыеп алганда өенә язып салган бу хаты турында Җиңү китерәчәк 1945 елның апрелендә, госпитальдә ятканда, Кызыл Армиянең кече лейтенанты Гадел Кутуй, әлбәттә, искә төшерми калмагандыр. Улы Рөстәмнең аны кайчан да булса укыячагына да өмете зурдан булгандыр. Кечкенә генә Польша шәһәре Згеж һәм аның госпиталендә пулялар очуын-очмый. Дөресен генә әйткәндә, Кутуй бирегә кечкенә генә бер пүчтәк аркасында килеп эләкте лә... Польшаны азат итеп барганда, сугышчан заданиеләрне үтәгәндә, бик каты суык тидереп, вакытында дәваланмыйча...

Бөек Җиңүне көтеп җиткерә ул. Әмма гаиләсе белән очрашырга, туган ягына әйләнеп кайтырга гына насыйп булмый. Әтисенең хатын Рөстәм Кутуй егерме яше тулган көнне укый. Бөек Ватан сугышы фронт хәбәрчесе Гадел Кутуй госпитальдә 1945 елның 16 июнендә вафат була. Диагнозы – туберкулёзның катлаулы формасы.

Ул болай да сәламәтлеккә артык туенмый, әмма гел көр күңелле, энергиясе ташып торган кеше була. Сугыш башланганда инде Кутуй – күренекле татар язучысы (аның «Тапшырылмаган хатлар» повестен бөтен ил егылып укый). Күп кенә башка коллегаларыннан аермалы буларак, ул эвакуациягә китми, сугыштан ераккарак качмый. Үз теләге белән, доброволец булып языла, туп-туры фронтка юл ала.

Сталинград мәхшәреннән имин чыга, алгы сызыкта артиллериядә көрәшә. Рядовой була. «Батырлык өчен» медале ала. 1944 елның көзенә аның күкрәген инде Кызыл Йолдыз ордены бизи, офицер дәрәҗәсенә күтәрелә. Хәзер Кутуй – «Кызыл Армия» фронт газетасының хәбәрчесе, очерклар белән репортажлар өчен материалларны яу вакытында шулай ук алгы сызыкта туплый.

Ә ял иткән араларда улына багышлап фантастик әсәрен яза – «Рөстәм маҗаралары»н. Шигырьләр иҗат итә. «Рус шәһәрен ярсып яклаганда, Күзләремә Казан күренә!» – дип яза ул фронтта тетрәнгеч шигъри юлларын.

«Тапшырылмаган хатлар» 1930 нчы елларда беренче мәртәбә дөнья күрә, язучы үзе һәлак булгач та, озак еллар дәвамында, хәзерге көнгә кадәр әллә ничә мәртәбә басыла. Рус телендә – 16, татар телендә 6 басмасы бар. АКШта, Мисырда һәм башка илләрдә дөнья күрә.

Бу кадәр популярлыкның сере нәрсәдә соң, диярсез? Әдәбиятны производство романнары басып алган бер чорда Кутуй кешеләрнең чын тойгы-хисләре турында язарга җөрьәт итә. Бәлки, шундадыр? Ә бит ул хисләр вакытның үзеннән дә, тарихи хәлләр белән шартлардан да һәрчак өстенрәк.

Сүз уңаеннан:

2017 елда ТНВ каналында «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча төшерелгән сериал экранга чыкты. 2022 елның декабрендә Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында «Рөстәм маҗаралары» спектакле куелды. Спектакль – күпсанлы фестивальләр һәм «Алтын битлек» театраль премиясе лауреаты. Финалы Гадел Кутуйның улы Рөстәмгә язган хатыннан юллар белән тәмамлана. Менә ул хат: *«Әниеңнән бу хатны саклавын һәм сиңа егерме яшь тулган көнне тапшыруын үтендем. Шул чакта без синең белән сөйләшербез. Гап-гади бер көн булыр ул. Синең өчен. Сугыш инде хатирәләрдә генә калыр. Без җиңәчәкбез, улым, безнең җиңми хакыбыз юк. Ишетәсеңме? Әниең: «Сиңа хат бар, улым, ул бик озак еллар буе килде, бар, икенче бүлмәгә чык та укы аны...» – дияр. Мин үлем турында уйламыйм, чөнки ул гел янәшәдә, ахыр чиктә, аңа ияләшәсең. Юк, мин куркусыз булганга түгел, әмма үзең турында уйлап-кайгырып утырырга вакыт булмаганга. Артыбызда иге-чиге юк ватаныбыз җәелеп ята. Әгәр пуля мине сайласа, син бу хатны алырсың... Менә сиңа егерме яшь тулды да. Котлыйм, улым! Әйдә, ирләрчә кочаклашыйк... Син тәмам үсеп беткәнсең, улым! Сиңа васыятем шул: кешеләрне ярат... Әтиең.»*

«Тапшырылмаган хатлар» сериалын төшерү вакыты.

Фото: belem.ru

АМЕРИКАДАГЫ «ҮЗЕБЕЗ»НЕҢ ЕГЕТ – ИСХАК ӘХМӘРОВ

АКШта бизнесы, күз явын алырдай матур хатыны һәм Нью-Йоркта фатиры була аның.

Исхак Әхмәров, ягъни АКШта совет резидентурасының булачак җитәкчесе 1901 елның 7 апрелендә ярлы гаиләсендә туа. Унҗиде яшенә мануфактура кибетендә приказчик дәрәҗәсенә җитә. Октябрь революциясе аңа чын мәгънәсендә кеше арасына чыгарга мөмкинлек бирә, һәм ул аны кулдан ычкындырмый. Бухгалтерлык курсларын тәмамлаганнан соң, Әхмәров Казанда Мәгариф халык комиссариатында эшли. Аннан соң укырга керә – Мәскәүдәге Көнчыгыш халыклары университетына, МДУның халыкара багланышлар факультетына.

1932 елда төрек, француз, инглиз телләрен камил белгән Исхакны беренче мәртәбә легаль булмаган разведчик сыйфатында Пекинга җибәрәләр. Янәсе, ул – Көнчыгышны өйрәнә торган төрек студенты. 1935 елда яңа бурыч көтә – АКШка командировка. Ул анда китәр алдыннан гына аңлаешсыз, серле рәвештә легаль булмаган разведка резиденты һәлак була.

Энергиясе ташып торган, аралашырга ярата торган интеллектуал тиз арада Америка мохитендә «үз кешегә» әверелә. Ул мәртәбәле Колумбия университетына укырга керә, госдеп, финанслар министрлыгы, башта төр Америка ведомстволары хезмәткәрләре арасыннан безнең разведкага эшләрлек агентлар эзли.

Бу эшкә Америка коммунистлары генераль секретаре бертуганының кызы – күз явын алырдай чибәр Хелен Лоурины да җәлеп итә. Озак та үтми, Хелен аның кәләшенә әверелә. Исхак Әхмәровның Хеленга өйләнергә рөхсәт итүләрен сорап Үзәккә юлланган рапорты, әйтүләренә караганда, барысыннан да бигрәк Лаврентий Бериянең җенен чыгара. Аның ачуын чыгару юньле тәмамланмаган булыр иде, билгеле, әмма АКШ коммунистлары лидерына Сталин бик яхшы мөнәсәбәттә була...

Берия моның үчен барыбер, өлешчә булса да, алмый калмый: аларны ватанга кайтаралар, Әхмәровны разведкада түбәнрәк дәрәҗәгә төшерәләр. Ләкин озакламый Икенче бөтендөнья сугышы башлана, бу парны кабат Америкага җибәрергә туры килә.

1942–1945 елларда Әхмәров АКШта совет резидентурасын җитәкли, Хелен (агент буларак псевдонимы Таня) – аның ярдәмчесе. Әхмәровларның тормышы җитеш һәм җайга салынган: мех эшләнмәләр җитештерә торган фирмалары, Нью-Йоркта фатирлары бар, бизнес эшләре буенча ил буйлап шик уятмыйча йөри алу мөмкинлекләре дә.

Вербовка узган агентлар аша ил буйлап алар җыйган мәгълүмат – бәһасез. Әхмәров аша СССРда Тәһран конференциясе алдыннан АКШның планнары нинди булуын ачыклыйлар, аның аша катгый яшерен «Манхэттен» операциясенең тормышка ашырылуы турында алдан ук билгеле була.

Исхак Әхмәровны совет разведкасының «умыртка баганасы» саналган Рихард Зорге, Ким Филби, Рудольф Абель кебек кешеләр белән бер рәткә куеп карарга була. Атаклы коллегаларыннан аермалы буларак, аның үзенең дә, хатынының да кемнәр булуы ахыргача ачыкланмый. Аларны «ача алмыйлар».

Ирле-хатынлы Әхмәровлар исән-имин генә Советлар Союзына әйләнеп кайта. Биредә полковник Әхмәров 10 ел дәвамында КГБның легаль булмаган разведка идарәсе башлыгы ярдәмчесе булып эшли. Исхак Әхмәров 1976 елда вафат була, Хелен иреннән соң тагын биш ел яши.

Фото: chelreglib.ru

КУРКУ БЕЛМӘС ЖАН

Яшерен оешма партизаны Жан шәхсән үзе генә дә абвер, СД һәм полициянең егерме агентын юк итә. Немецлар аны 1943 елның февралендә кулга ала. Нинди генә җәзалауларга дучар ителсә дә, герой беркемне дә сатмый, аңардан хәтта чын исемен дә әйттерә алмыйлар.

Жанның Казан егете Иван Кабушкин булуы турында ике дистә ел узгач кына беләләр. Сугышның беренче көнен кече лейтенант Иван Кабушкин СССРның Көнбатыш чигендә каршылый. Берничә көнгә сузылган сугыштан соң әсирлеккә эләгә. Аны хәрби әсирләр колоннасында оккупацияләнгән Минскига китерәләр.

Әсирлектән качып, партизан хәрәкәтенә кушыла. Кабушкин әлеге хәрәкәтнең хәрби Советына – элеккеге совет хәрбиләренең яшерен оешмасына керә. 203 нче партизан отрядының разведка башлыгы ярдәмчесе була.

Жанга хыянәтчеләрне һәм фашист агентларын ачыклау һәм юк итү төркеме белән җитәкчелек итү ышанып тапшырыла. Төркем уңышлы гына эш итә: Кабушкин үзе генә дә абвер, СД һәм полициянең егерме агентын юкка чыгара.

Оператив төркем башлыгы буларак, Жан дошман машиналарына һөҗүмнәр, лагерьлардан хәрби әсирләрнең качуын оештыра, корал, сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек таба. 1942 елның маенда ВКП (б) ның яшерен шәһәр комитеты җитәкчелеге юк ителгәннән соң, Кабушкинга Минскида яшерен оешманы яңадан торгызу бурычы йөкләнә.

Ләкин шул ук елның көзендә немецлар шәһәр комитеты әгъзаларын берәм-берәм кулга алырга керешкәч, Жанны эзәрлекли башлыйлар. Аны 1943 елның февралендә кулга алалар: элемтәче, немецларга эләгеп, җәзалауларга түзә алмый...

Гестапода партизанны кызган тимер, ток белән җәзалыйлар, аннары махсус таш капчыкта ярты ай әчертмичә, ашатмыйча тоталар, ләкин рухын сындыра алмыйлар. Жан беркемне дә сатмый, хәтта үзенең чын исемен дә әйтми. Аны 1943 елның 4 июлендә Минск төрмәсендә җәзалап үтерәләр...

Искиткеч батырлыгы һәм тугрылыгы өчен Иван Константинович Кабушкинга (үлгәннән соң) Советлар Союзы Герое исеме бирелә. СССР Югары Советы Президиумының бу турыдагы Указы 1965 елның 8 маенда басылып чыга.

Кабушкин Татарстан башкаласында җидееллык мәктәпне тәмамлаган, армиягә алынганчы трамвай йөртүче булып эшләгән. Казан урамнары буйлап ул йөрткән Х №24 трамвай вагоны сакланып калган. Вагон «Метроэлектротранс» МУП бинасы янында урнаштырылган. Белоруссиянең Бөек Ватан сугышы тарихы музеенда Иван Кабушкинга багышланган стенд урнаштырылган, Минск һәм Барановичи шәһәрләрендә аның исеме белән аталган урамнар бар.

Иван Кабушкинның батырлыгы турында «Руины стреляют...» дип аталган 6 серияле телевизион сериал төшерелә.

Фото: fotostrana.ru

БЕЛЕШМӘ:
Гани Бекин улы Сафиуллин. Генерал-лейтенант. Советлар Союзы Герое. 2 Ленин ордены, 3 Кызыл Байрак ордены, 2 II дәрәҗә Суворов ордены, 2 II дәрәҗә Кутузов ордены, күпсанлы медальләр белән бүләкләнгән. Казанның бер урамы аның исемен йөртә. ТАССРның башкаласында яши, шунда хезмәт итә. Казанның Арча зиратында җирләнгән.

ГАНИ САФИУЛЛИН: ТӨНГЕ ҺӨҖҮМНӘР ОСТАСЫ

1927 елның августы. РККАның кавалерия полкында яңа кеше – тәҗрибәсе булмаган рядовой Сафиуллин. 16 елдан соң комдив Гани Сафиуллин Сталинград сугышында беренче немец генералын әсирлеккә алачак...

Арчаның Иске Кишет авылы ятиме һәм элеккеге сукбай малай... Армия аңа форсат тудыра, һәм ул аннан файдалана. Сугыш башланганда, Гани Сафиуллин полк командиры була. Аннан соң Смоленск, Великие Луки янындагы бәрелешләр, чигенү ачысы...

Беренче уңыш – 1941 елның 24 ноябрендә Калинин фронтында: төнлә кинәт һөҗүм ясап, полк авылдагы немецларны юк итә. Төнге һөҗүмнәр Сафиуллинның яраткан алымына әйләнә. Башта полк, аннан соң дивизия белән командалык иткәндә, ул бу манёврны бик оста куллана: дошман өстенә һәрвакыт көтмәгәндә һөҗүмгә ташлана – немецлар «кагыйдәсез», йокламыйча сугышырга өйрәнмәгән...

Сталинград сугышы Сафиуллинның укчылар дивизиясен ныклыкка сыный. 1942 елның 20 августында күп югалтуларга дучар булган, арыган, йончыган дивизияне яңа сугышчылар белән тулыландырып өчен алгы сызыктан ялга чыгаралар. Әмма 5 көннән соң полкларына янә сугышка керергә туры килә – Дон аша немецларның алгы частьлары бәреп кергән. Шуннан соң Сталинград янында өч ай дәвамында өзлексез сугышлар бара. 19 ноябрьгә кадәр өч ай дәвамында оборонада булалар, немецларның боҗрада калган төркемнәренә контрһөҗүм башлана.

Дистәләрчә чакрымнарны сугыша-сугыша узып, гыйнварда сафиуллинчылар немецларны Сталинград хәрабәләрендә тармар итә. Соңыннан саныйлар: Иделдәге бәрелеш вакытында дивизия дошманның 8 меңнән артыграк солдат һәм офицерын әсирлеккә ала, 102 коралын, 2000 автомашинасын, 18 самолётын кулга төшерә.

Фото: wikipedia.org, nk-online.ru

Әсирләр арасында генерал Мориц фон Дреббер – Сталинградта әсирлеккә алынган беренче генерал да була. Бу турыда «Правда» газетасының 1943 елгы 1 февраль санында болай дип язылган: «Парламентёрлар рус полковнигына генералларының бөтен штабы белән совет ультиматумын тулаем кабул итәргә әзер икәнлеген җиткерүне сорый.

– Ниһаять, аңлаганнар, – ди полковник. – Парламентёрлар керсеннәр!

Блиндажга чандыр гәүдәле, озын буйлы лейтенант керә. Ул болай дип хәбәр итә: 297 нче дивизия командиры генерал Мориц фон Дреббер җиңүче алдында коралын ташлый һәм әсирлеккә төшәр өчен дивизиясенә кайсы урынга җыелырга кирәклеген сорый...

Полковник сәгатенә карап ала. Ярты төн күптән авышкан икән инде. Ул үзенең полкына сөйләшүләр вакытында утка тотуны туктатып торырга куша һәм генералның бөтен штабы белән үзе янына килүен көтә. Полковник бу дивизияне яхшы белә, аның офицерларының фамилияләре, аларның сугышчан сыйфатлары белән дә таныш. Җәй көне яу кырында Чугуево янында ул 297 нче дивизия белән очрашкан иде, ә узган елның көзендә – Цыбенко белән Алексеевка хуторлары тарафында.

Төнге икеләр тирәсендә генерал Мориц фон Дреббер штабы белән килеп төшә.

Генералдан:

– Сезнең полкларыгыз, солдатларыгыз кайда соң? – дип сорыйлар.

Фон Дреббер көлеп куя да:

– Миннән сорыйсызмы? Минем полкларым кайдамы? Исән калганнарның барысы да хәзер сездә, полковник әфәнде. Мин солдатларым коралларын ташласын дигән боерыкны бирдем, әмма алар моны күпкә алдан эшләгән иде инде.

Немец генералы яңа хәленә тиз ияләшкән булса кирәк. Ул күп сөйләшә, хәтта уен-көлке дә кушып җибәрә.

– Ничә яшь сезгә? – дип сорый ул полковниктан.

– Утыз биш.

– Ярь-яшь, ә үзе чал чәчле немец генералын әсирлеккә алды. Мин – Сталинград янында әсирлеккә төшкән беренче генерал.

– Русларга беренче булып әсирлеккә төшкән немец генералы, – дип кабатлый полковник, – соңгысы булмас, дип өметләнәм.

«Яшь рус полковнигы» Гани Сафиуллин Сталинградтан соң генерал-майор дәрәҗәсен ала. Ул шуннан соң 1943 елның көзендә Днепрдагы бәрелешләрне тизәйтүдә мөһим роль уйнаячак корпус белән командалык итә.

Сафиуллин һәм аның корпусының 72 офицеры һәм солдаты Советлар Союзы Герое була. Аннан соң инде алда Румыния, Венгрия, Чехословакия көтә, ә Бөек Җиңүдән соң – Япония белән сугыш.

P.S. 1949 елның апрелендә 38 нче гвардия һава-десант корпусының командир урынбасары генерал-лейтенант Гани Сафиуллинны, вазифасыннан азат итеп, «намус хөкем»е чыгарачаклар – Тула гарнизонының Офицерлар йорты залында хәрби трибунал утырышында «партиягә каршы чыгышы» өчен. Тәҗрибәле фронтовик дезертирлыкта гаепләнгән солдатны якламакчы була...

Гани Сафиуллинның бюсты Түбән Камада каһарман исемен йөрткән кадет корпусы территориясендә урнаштырылган.

КАЗАННАН КОСМОСКА КАДӘР

Ольга Туманская

1940 нчы еллар. Илебездәге гамәли космонавтикага нигез салучы Сергей Королёв та, башка галимнәр белән бергә, Казан «шарашкасында» эшли. Нинди хисләр кичерә, нәрсә турында хыяллана икән ул? Дистәләрчә елдан соң Королёв йөргән эзләрдән үтеп, шуны аңларга тырышып карыйк әле.

«БИРЕДӘ КОРОЛЁВ ЯШӘГӘН»

Зур, бик якты бүлмә. Кояш нурларына чумган! Җиһазлардан – карават, ашъяулык урынына җәймә ябылган аш өстәле, язу өстәле, бер-ике утыргыч, тумбочка. Кирәк-ярактан – өч пыяла банка, ике шешә, кружка һәм чәй кашыгы. Менә, бөтен байлык шул! Көлкеме? «Минем үземә дә көлке шул. Тик мин бер дә кайгырмыйм... Тормышта бит иң мөһиме бу түгел, һәм гомумән, болар барысы да – вактөяк кенә», – дип язган Королёв туганнарына үзенең – ниһаять! – иректә тормышы хакында.

Әйе, ул Казанда иреккә тиенгән – 1944 елның 27 июлендә «шарашкадагы» башка галимнәр белән бергә аны да вакытыннан алданрак азат иткәннәр, суд хөкемен алганнар. Хәер, бу ирек шартлы булган: паспорт урынына – азат ителү турындагы белешмә, тик ул күп хокуклардан мәхрүм итә – сайлауда катнаша, демонстрациягә чыга алмый, атна саен «Черек күл»дә теркәлү мәҗбүри... Әмма Королёв барыбер шат. «Мин элегрәк (сугышка кадәр) тормышның гүзәл мизгелләренең кадерен белмәгәнмен икән, хәзер исә кояш нурының да, бер йотым саф һаваның да, каткан икмәк кисәге-

Лядов урамы, 5 нче йорт, 100 нче фатир – биредә Королёв яшәгән!

В этом доме

с 1944 по 1946 г.г. жил

главный космический конструктор

Королёв

Сергей Павлович

Бүген Лядов урамы, 5 нче йортта ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Биредә Королёв яшәгән» пластик табличкасы гына боегып тора.

Фото: wikipedia.org, nk-online.ru

нең дә никадәр кадерле икәнен аңладым», – дип язган ул алдарак искә алынган хатында.

Ул гомере буена шундый талымсыз булып калачак. Беркайчан да тормыш авырлыгыннан зарланмаячак. Бернәрсә дә тупламаячак, әйберләрен кадерләмәячәк. Әмма Колымадан алып кайткан алюминий кружкасын күз карасыдай саклый. Казаннан нәрсә алып кайтты икән соң ул? Үзе өчен һәм бөтен бу дөнья өчен бәһасез нәрсәләрне – континентара баллистик ракета төзү буенча тәүге сызым һәм исәпләүләрен.

Лядов урамы, 5 нче йорт, 100 нче фатир – Королёвның Казан адресы менә шундый. Алтынчы подъездга керү ишеге бүген магнитлы йозакта. Әмма без шулай да түр ишектән кереп йөрүен күз алдына китерик: шул ук баскыч басмалары, шул ук култыксалар... Бишенче кат, мәйданчыкта дүрт фатир – безгә сулга. Йөзенче номерлы ике бүлмәле фатирга аяк басабыз – менә ул тәрәзәләр! Һаман шулай ук кояш нурларына чумып утыралар. Тәрәзәдән күренеп торган балалар бакчалары да, каршыдагы арка да шул ук, чын, барысы да сакланган, тәрәзә төбендәге биек каенны гына кисканнәр...

Королёв бу фатирның бер бүлмәсендә яшәгән. Икенчесендә кем соң? Мәгълүматлар төрле. Үзенең гаиләсенә ул «тагын бер иптәшем белән яшим», дип яза; соңрак аның кызы Наталья үзенең китабында инженер Шнякин исемен атаячак. Әмма йортта яшәүчеләр конструкторның күршесе НКВД хезмәткәре булуын хәтерли, дөрес, инде конвойчы түгел, бәлки сакчы сыйфатында. Күрше фатирда Глушко яшәгән. Бөтен подъезд «шарашка»ның элекке зекларына (тоткыннарына) бирелгән булган! Хәер, бүген биредә ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Биредә Королев яшәде» пластик табличкасы гына боегып тора. 100 нче фатир да хәзер буш, дип сөйлиләр. Бәлки, аны кемдер инде, киләчәктә бәһасезгә әйләнәсен аңлап, күптән сатып алгандыр?

ЙОЛДЫЗЛАР ИРЕКТӘН КАДЕРЛЕРӘК

Безнең көннәр. Моторлар төзү заводы ишегалды. Капка төбендә үк – КМТБ эшчеләре койган Королёв горельефы. Совет гамәли космонавтикасына нигез салучы галим сугыш елларында биредә эшләгән. Ул монда килергә бик омтылган, хәтта үзенең төрмәдә утыру вакытын аңлы рәвештә озынайткан!

Колыма алтын приискларындагы каторгадан соң Королёв Туполев «шарагасында» – Омскида НКВДның ябык конструкторлык бюросында хезмәт куя. Башка тоткын конструкторлар белән бергә Ту-2 бомбардировщигын чыгаруны җайга сала һәм үзенең вакытыннан алдан азат ителүен көтә. Кинәт ул икенче бер «шарашка» җитәкчесе Валентин Глушконың аны Казанга күчерү артыннан йөрүен белеп ала. Анда реактив ракета двигателен төзү буенча эш алып барыла! Королёв гомере буе шуның турында хыялланмаганмыни? Ирекә чыгу өмете кабынуга карамастан, ул үзе дә Глушко «шарашкасына» күчерүләрен юллый башлый. Королёв Казанга килгәндә, яшерен РД-1 инде әзер диярлек була. Галимнең бурычы – аны самолётка яраклаштыру

Замана шаһитлары галим-конструкторлар өчен НКВД махсус төрмәсе яки «шарашка»ның Казан авиация заводы идарәсе бинасында урнашуын хәтерли әле. Дүртенче катта – конструкторлык бюросы. Өченчесендә – төрмә тулай торагы.

Һәр иртәне КМТБнең 4 мең эшчесен Сергей Королёв горельефы каршы ала. Ул беренче совет реактив ракета двигателенең нәкъ менә биредә җыелуын һәм шул рәвешле безнең илебезнең ерак космоска тәүге адым ясавын искә төшереп тора.



Менә ул – тимерчыбык сеңерле «хәшәрәт» КМТБ музеендагы легендар РД-1 установкасы.

һәм сынаулар үткәрү. Бер ай эчендә генә дә аның җитәкчелегендә 900 сызым сызыла! Һәм алар барысы да кирәкле булып чыга...

КМТБ *музеенда мин әлеге легендар установканы күрдем: тимерчыбык сеңерле хәшәрәт ул. Артында – аны дөньяга тудыручыларның фотосурәтләре. СССР НКВДсының төрмә тибындагы махсус конструкторлык бюросы тоткыннары. Кайсы исемне генә атасаң да, йолдызлы шәхес – Глушко, Королёв, Жирицкий, Севрук, Лист, Чаромский, Стечкин... Музей директоры Гүзәл Габдуллина алар турында сәгатьләр буе сөйли ала.*

Сүз уңаеннан, РД-1 двигателе Пе-2 очкычында гына түгел, Лавочкин, Сухой, Яковлевның винтлы самолетларында да сыналган. «Мин капчыктагы мәчене алам дип уйлаган идем, ә капчыкта юлбарыс булып чыкты», – дигән аның турында Лавочкин.

«БУ ТОТКЫННАР... ЯШИ»

Казан авиация заводы. Завод идарәсе бинасы. Әйдәгез мәрмәр баскычтан дүртенче катка менүебезне һәм сулга борылуыбызны күз алдына китерик. Шаһитлар әйтүенчә, сугыш елларында «шарашка» нәкъ менә шунда урнашкан була.

Яңа тоткын Королёв бирегә 1942 елның 19 ноябрендә килә. «Киң җилкәле уртача буйлы кеше, зур түгәрәк башы кыска муенга утыртылганга, гәүдәсе бераз бөкрерәк тоела. Зур кара күзләреннән акыл сирпелә», – үзенең язмаларында ракетачы инженер Эдельман Королёвны шулай сурәтли. Бу вакытта инде конструктор каторга кичерешләреннән бераз айныган, Туполев «шарагасында» тамагын туйдырган, ә иң мөһиме – үзенең яраткан эшенә әйләнеп кайткан һәм шунлыктан «мөлаем, аралашучан һәм хатын-кызларга ихтирамлы» кеше кебек тоелган. Коллегалары аның ягымлы энергиясен, кешеләрне бурычны хәл итүгә юнәлтә белүен, оештыру осталыгын, ярдәмчел һәм игътибарлы булуын искә төшерә. «Соңрак аңа хас булган хакимлек итәргә яратучан холык сыйфатлары Казанда бер дә сизелмәде».

Тоткыннар бер кат астарак яши. Королёв бүлмәсендә тагын 23 кеше була. Үзләренә генә йөрергә ярамый, аларны һәр җирдә НКВДның кораллы хезмәткәрләре озата йөри. Бу «шәм» хезмәткәрләр саны тоткыннарныкыннан азрак була, шунлыктан кайвакыт, кирәкле җиргә барыр өчен, сакчының бушавын көтәргә туры килә.

Әмма, махсус төрмәнең эчке тәртибенә карамастан, Глушко тәҗрибә-конструкторлык бюросында мөмкинлекләр дә күп була. Двигательләр конструкторы Алексей Исаев 1942 елда мондагы шартларны күрә һәм икенче бер галим-конструктор Борис Чертокка: «Бу тоткыннар бездән яхшырак яши. Без хыяллана да алмаган стендлары, лабораторияләре, җитештерүләре бар. Аларны саклыйлар, шунлыктан ихластан сөйләшеп булмаячак. Әмма безгә, иректәгеләргә караганда ашатуын да яхшырак ашаталар. Иң мөһиме – аларның двигательләре күпкә ышанычлырак эшли», – дип сөйли.

Тоткынлыкта интексәләр дә, Казан «шарашка»сындагылар хыялда гына булса да үзләре күнеккән тормышта яшәргә тырыша. 1943 елда Королёв һәм Севрукны командирлар ашханәсендә туклануга күчерәләр, анда исә тәүлегенә 800 грамм икмәк бирелә! Аны Севрук каһвә бөртекләренә алмаштыра, кичләрен исә үз «ресторанына» якын дусларын җыя. «Әйдә, «Риога» барабызмы?» – дип сөйләшә торган булалар. Каһвәне отбойга кадәр эчеп утыралар кайвакыт. Тәнәфесләрдә шаян спорт ярышлары оештыралар – кем кемне караватастына төртеп кертә? Аннары китап укыйлар. Китапларны да, каһвәне дә ялланып эшләүчеләр аша табалар, алар тоткыннарга, бөтен кагыйдәләрне бозып, булыша. «Шарашка»га «халык дошманнары» түгел, фидакарь галимнәр ябылуын гади кешеләр яхшы аңлый. Исаев әйтүенчә, Казан «шарашка»сында яшәүчеләр белән ике көн аралашкан арада ул сыеклыклы реактив двигательләр турында күбрәк әйбер

белә – һәрхәлдә, Ракета фәнни-тикшеренү институты белән озак вакыт буе хезмәттәшлек итү чорыннан күпкә күбрәк мәгълүмат туплый.

«ПЕШКА» ФЕРЗЬГӘ ӘЙЛӘНӘ

Казан авиация заводының җыю цехы каршында басып торганда, әлеге зур капканың ничек ачылуын һәм урамга... самолёт төртеп чыгаруларын күз алдына китерү бер дә кыен түгел. Менә ул Пе-2 бомбардировщигы! Самолёт артыннан исә цехтан эшчеләр йөгереп чыга – барысының да үз «Пешкаларының» ферзьгә әйләнүен күрәсе килә.

Сериялөп җитештерелә торган машинаның койрыгына РД-1 реактив двигательле яңа тизләткеч установка куелган. Шуның нәтиҗәсендә самолёт тизрәк һәм биектәрәк оча, моның өчен махсус төймәгә генә басарга кирәк! Пилот кабинасында яшь сынаучы – Александр Васильченко. Бу егет – булачак Советлар Союзы Герое. Аның янәшәсендә сынаучы инженер, тоткын Сергеев. Завод эшчеләре әлеге фамилия артына кем яшерелүен 1966 елдан соң гына беләчәк – «Сергеевны» телевизордан күргәч! Әлбәттә, язмада гына – ул чакта Королев үзе инде вафат...

Эксперименталь очышлар сериясе 1943 елның 1 октябрендә башлана. Бервакыт 7 мең метр биеклектә самолётның двигателе шартлый. Койрык ягына ут каба, һәм ялкын тиз арада кабинага якынлаша. «Сикер!» – дип кычкыра пилот инженерга, биеклекне киметә төшеп, әмма ул баш тарта – авариянең сәбәбен ачыкларга кирәк була. Васильченко яна торган машинаны җиргә утырта ала. Үзе бик каты пешә. Королёвның муены, кулы, йөзе һәм күзе пешә – конструктор сукырая. Берничә көн буе тоташ караңгылыкта яши, әмма, бәхеткә, күзләре ачыла. Реактив двигатель һәм ракета тизләткече төзү эшләрен шәхсән контрольдә тоткан Лаврентий Берия нәкъ менә шул очрактан соң Королевны очудан тыйган, диләр.

КОНСТРУКТОРГА КАНАТ БИРЕГЕЗ!

Каторгадан һәм махсус төрмәдә яшәүдән соң иреккә чыккан Королёв Лядов урамындагы фатирында ялгызлыгыннан ләззәтләнә. «Кайтам, кичке ашка тиз генә бирер нәрсә пешереп ашыйм да, караватка ятам, бераздан йокыга да талам. Рәхәт!» – дип яза ул әнисенә. Әмма ул махсус конструкторлык бюросында эшләвен дәвам итә – көненә 15–18әр сәгать баш ватарга туры килә.

Эшкә Королёв 9 нчы трамвай белән бара алган – ул йорты каршысында ук туктаган. Әмма трамвай бик начар йөргән, сәгать саен диярлек ватылган. Шәһәргә чыгасы булса, Соцгородтан Казанга сәяхәт ике сәгатькә сузылган. Тик Королёв шәһәрдә сирәк булган, эшкә исә трамвайсыз, җәяү дә барып җитеп була – нибары 15 минут вакыт кирәк!

Цех капкасы ачылыр да, урамга легендар Пе-2 бомбардировщигы тәгәрәп чыгар кебек! Сугыш вакытында нәкъ менә биредә, Казан авиация заводында, яңа РД-1 тизләткеч установкасы сыналган. Сынауда Королёв катнашкан.

Кайсы юлдан барган икән ул? Әйдәгез, күз алдына китерик әле. Подъезддан чыккач, каршыдагы йортның аркасы аша үтеп, «Крылья Советов» паркына керәсең. Үзәк аллеядән бераз баргач, сулга борыласың. Елның бөтен фасылында да матур, ышык, кошлар сайравына күмелгән парк илһамландыра. Бүген Королевны мондагы агачлар гына «хәтерлидер» инде. Берьялгызы гына аллеяләр буйлап йөргән конструктор нәрсә турында уйлаган икән? Иптәшләре белән бергәләшеп өйгә кайтканда, нәрсә турында сөйләшкәннәр?

Кайчандыр, 1929 елда, ул Циолковскийның «Исследование мировых пространств реактивными приборами» китабын укыган һәм планер белән самолётларда гына түгел, атмосферадан узып та очып булуны аңлаган. Әлеге идея – кешелекне яңа биеклеккә алып чыгу – Королёвны озак еллар буе илһамландырган. Ә менә биредә, Казанда, ниһаять, ул бу идеяне тормышка ашырып булуына ышанган.

«Крылья Советов» паркы.

БЕЛЕШМӘ:
Зәки Нури (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов) 1921 елның 24 декабрендә Татарстанның Буа районы Татар Төкесе авылында (хәзер – Чүпрәле районына керә) туа. Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Орша шәһәренең Мактаулы гражданины. Фронтовик, Константин Заслоновның партизаннар берләшмәсендә сугыша. 1944–1946 елларда – Орша шәһәр башкарма комитеты рәисе урынбасары. 1971–1974 елларда – ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе Президиумы әгъзасы (1970–1975). 1961–1968, 1974–1978 елларда ТАССР Югары Советы депутаты. 30 дан артык китап авторы. Язучының иҗади мирасында Янка Купала, Якуб Колас һәм башка белорус шагыйрьләренең татарчага тәрҗемәләре аерым урын алып тора. 70 тән артык милләт халыклары иҗаты энҗеләрен җыеп, татар телендә «Азәрбайҗан шагыйрьләре шигырьләре», «Белоруссия шагыйрьләре шигырьләре», «Казахстан шагыйрьләре шигырьләре» җыентыкларын бастырып чыгара.

ПАРТИЗАН ОТРЯДЫНДА КҮПЕРЛӘР ШАРТЛАТУЧЫ

Илле ел элек булган кинохроника кадрлары Орша тимер юл вокзалында шагыйрь һәм язучы Зәки Нурины каршы алу мизгелләрен саклап калган. Барысы да беркетмәдә каралганча: ипи-тоз, чәчәкләр... Ләкин барысы да шулкадәр ихлас, болай җитәкчеләрне түгел, бәлки якын дусларны гына каршы алалар. Күпләргә ул чыннан да дус, якын гына түгел, сугышчан дус була. Белоруссия дә аның өчен күптән Татарстан кебек үк якын...

Беренче тапкыр сугышның ни икәнен 19 яшьлек чик сакчысы Нуретдинов 1941 елның июнендә Белоруссия җирендә күрә. Аннары алар әле күп булачак: сугышы да, камалыш та, торган саен Көнбатышкарак чигенгән фронт сызыгы да. Котылу мөмкинлеге биргән партизан отряды да. Монда чик сакчысы Нуретдинов башта күпер, эшелоннарны, немец техникасын шартлатучы буларак хезмәт итә. Аннары командиры – атаклы Константин Заслонов төпле, ышанычлы Зәкине атлы разведка командиры итеп билгели. Отряд та ул вакытка инде зурая – партизаннар бригадасына әйләнә…

Нуретдинов партизан бригадасында Белоруссияне азат иткәнче сугыша, Ватан сугышы орденына һәм «Ватан сугышы партизанына» медаленә лаек була, гәрчә партизаннарга бүләкләр сирәк тәтесә дә. Ә аннары элеккеге шартлатучы Орша шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары вазыйфасында җимерелгәннәрне торгызуда катнаша. Туган ягына ул сугыштан соң ике ел үткәч кенә кайта. Урманнар белән шөгыльләнә (сугышка кадәр урман-техника техникумын тәмамлаган була) һәм шигырьләр яза. Ә Белоруссия аның белән мәңгегә кала: Татарстанга Зәки партизан отрядында ук танышкан Валясын да алып кайта.

Тиздән Зәки Нуриның беренче шигырьләр җыентыгы басыла, ул профессиональ язучы булып китә. Күп шигырьләре, әлбәттә, сугышка багышлана. «Үлгәннәр дә үч алды» әсәре дә сугыш турында. Белорус урманнарындагы партизан тормышына, сугышчан дусларына багышлап яза ул үзенең бу әсәрен. Геройларның исемнәре дә чын диярлек, төп персонаж – Константин Заслонов. Разведка башлыгын гына автор Мансур дип атаячак, ә полкташлары бу геройда Зәкине күрә.

Партизан отрядындагы дуслык гомерлеккә әйләнә. Оршада Заслонов отряды геройларына мемориал төзергә уйлагач, ярдәм сорап Татарстанда яшәүче разведка башлыгына мөрәҗәгать итәләр. Зәки Нури, ул вакытта инде танылган шагыйрь, депутат, Белоруссия ССР җитәкчелегенә хат яза. Минск үтенечне җавапсыз калдырмый – ярдәм кулын суза.

Кинохроника кадрлары Зәки Нуриның 1972 елда ветеран-партизаннар очрашуына килүен чагылдыра. Менә алар барысы бергә урманда, кайчандыр сугыш вакытындагыдай учак тирәли утырышканнар. Тик гимнастёрка һәм телогрейкадан түгел, ә бәйрәм костюмнарын кигәннәр, орденнарын такканнар. Менә алар мемориаль стелага чәчәкләр салалар. Ә менә җирле мәдәният йортында чыгышлар бара: Зәки Нури үзенең «партизан» шигырьләрен укый, яшьләр кул чаба... Өч елдан соң, 1975 елда, Зәки Нурига Орша шәһәренең Мактаулы гражданины исеме бирелә.

Фото: gorkiy.tatmuseum.ru

«ОЧА ТОРГАН ТАНК» КОМАНДИРЫ

Николай Столяров, Бөек Ватан сугышының атаклы очучысы, Казанның Дары бистәсендә туып-үскән. Бронза бюстны аңа әле исән чагында ук куйганнар...

«Миннән еш кына һавада уздырган дүрт йөз сәгатьнең кайсысы иң авыр булуы турында сорыйлар, – дип искә ала Николай Столяров. – Ә сугыш вакытында җиңел «рейслар» булмады. Безнең штурмовикларны юкка гына «Оча торган танклар» дип атамый иделәр бит. Бездән нәрсә таләп ителде? Тизлек, манёврлылык, объектны тиз таба белү. Авиациядә: «Биеклек хуҗасы – бәрелеш хуҗасы», – диләр».

Ил-2 штурмовигында Николай Столяров очканда, сугышның хуҗасы кем икәне полкташларына гына түгел, хәтта дошманнарга да мәгълүм була. 141 нче гвардия авиация полкы командиры Алексей Компаниец, үзенең очучысын тасвирлап, болай дип яза: «Иптәш Столяров – искиткеч очучы-штурмовик, ул һәр хәрби очышта батырлык һәм каһарманлык күрсәтә, шул ук вакытта дошманның тере көченә һәм техникасына зур зыян сала. Ул, иң тәҗрибәле һәм куркусыз очучы буларак, һәрвакыт командованиенең аеруча катлаулы һәм җаваплы бурычларын үтәр өчен җибәрелә һәм, бернинди кыенлыкларга да карамастан, үзенә тапшырылган барлык хәрби бурычларны да бик яхшы башкарып чыга».

Компаниец әлеге характеристикасында сугыш вакытында еш кына игътибар бирелмәгән иң мөһим нәрсәне дә билгеләп үтә: «Һава яуларында ул үз кешеләрен дә, хәрби техникасын да югалтмый иде».



Фото: regnum.ru, tatfrontu.ru

Үзенең беренче Советлар Союзы Герое Алтын Йолдызын Николай Столяров 1944 елның июлендә – Курск сугышы вакытында, Днепрны кичкәндә, Полтава, Кременчуг һәм Кировоградны азат иткәндә дошман авиациясенә каршы һава сугышларында күрсәткән батырлыгы өчен алачак. Икенче Йолдызы бер ел узгач, Корсунь-Шевченко, Львов-Сандомир, Берлин һәм Прага операцияләрендә хәрби бурычларны үрнәк итеп үтәгәне өчен биреләчәк.

Сугыш елларында Николай Столяров немецларның позицияләрен һөҗүмгә һәм бомбага тотарга 185 тапкыр оча. Шәхсән үзе дошманның 8 самолётын, 52 танкын, 24 артиллерия батареясын, 200дән артык автомашинасын һәм бик күп тере көчен юк итә. Хәрби-авиация мәктәбендә тизләтелгән курсларда сигез ай тирәсе укып, 1941 елның декабрендә сугыш тәҗрибәсе бөтенләй булмаган 20 яшьлек кече лейтенант сыйфатында фронтка эләккән очучы өчен искиткеч күрсәткечләр бу...

Николай Столяров 1922 елның 22 маенда Казанда туа. Әти-әнисе белән шәһәр читендә, Дары бистәсендә яши. Аларның йортын – искереп җиргә сеңгән өйне – әле күптән түгел генә Киров районындагы Лебяжье урамында күрергә мөмкин иде. Николай тәмамлаган урта мәктәп тә Киров районында урнашкан. Ул параллель рәвештә аэроклубта укый һәм пилот таныклыгы ала. Сугыштан соң Столяров туган шәһәренә әйләнеп кайтмый инде – Хәрби-һава академиясен тәмамлый, Мәскәүдә яши һәм эшли. Ә 1953 елда туган каласы Казанда ике тапкыр Советлар Союзы Герое Николай Столяровның бронза бюсты куела. Һәйкәлнең авторы – Мәскәүдә Халык казанышлары күргәзмәсендәге данлыклы «Эшче һәм колхозчы» композициясен ясаган Вера Мухина.

БЕР СУГЫШ – ИКЕ ЯЗМЫШ

Рядовой Миңнулла Гыйззәтуллин, унсигез яшь. Лейтенант Гали Шәмсетдинов, егерме тугыз яшь. Советлар Союзы Герое исеме икесенә бер көнне бирелә, тик берсенә – үлгәннән соң...

Миңнулла Гыйззәтуллин.

Гали Шәмсетдинов.

1944 елның җәенә танкист Шәмсетдинов сугышның нәрсә икәнен шактый татып өлгергән кеше була. Фронтта сугышның беренче көннәреннән катнаша ул. Танкта калып яна, дүрт тапкыр яралана. Бөек Ватан сугышының иң дәһшәтле танклар бәрелешендә – Курск сугышында катнаша, исән кала.

Букрин һәм Лютеж плацдармнарында Днепрны ике тапкыр кичә. Киевны азат итешә. 1943 елның 5 ноябреннән 6 сына каршы төндә, атаклы «фаралар кабызган атакада», үзенең танкында дошман ныгытмалары полосасына бәреп кереп, берничә туп һәм пулемётны, дистәләгән немецны юк итә, Кызыл Йолдыз орденына лаек була.

Львов-Сандомир операциясе рота командиры лейтенант Шәмсетдиновның йолдызлы сәгатенә әйләнә. Волковец хуторы янындагы сугышта аның экипажы унлап немец «тигр»ы һәм «пантера»сы белән сугыша, дүрт «тигр»ны яндыра. Соңрак, Куткож тимер юл станциясенә бәреп кереп, аның ротасы дошманның бронепоездын юк итә, алга таба елга кичүен кулга төшерә һәм аны төп көчләр килеп җиткәнче саклап тора.

Бу сугыштан соң шагыйрь Александр Безыменский дивизия газетасында «Шәмсетдиновка дан!» дигән сокланулы шигырен бастыра. Шигырьне герой үзе бик тыйнак кабул итә.

Ул профессиональ хәрби була. Аны, Әгерҗе районының Салагыш мәктәбе директорын, 1939 елда хәрби хезмәткә алалар. Сугышка кадәр танк училищесын тәмамларга өлгерә. Гали Шәмсетдиновка Львов өлкәсендәге сугышлардагы батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирү турындагы Указ 1944 елның 23 сентябрендә чыга. Әмма лейтенантка Йолдызын тапшырырга соңаралар – Чистай районының Яушырмә авылында туып-үскән егет 1944 елның 22 июлендә Львов өлкәсенең Гамулец хуторы янында һәлак була...

Ә гвардия рядовое Миңнулла Гыйззәтуллин, 1944 елның 23 сентябрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелгәндә, алты айдан аз гына артыграк сугышырга өлгергән була.

Балык Бистәсе районының Күки авылында туып-үскән егетне Кызыл Армиягә унсигез яше тулганчы алалар, фронтка ул бераз соңрак, 1943 елның декабрендә эләгә. Сандомир плацдармын алуда батырлык күрсәтә. Польшаның Баранув-Сандомерский шәһәре тирәсендә пехотачы Гыйззәтуллин фашистлар уты астында Висланы кичә, дошман траншеяларына таба шуыша һәм гранаталар ыргыта. Аннары, окопка төшеп, автоматтан ут ача һәм елганы кичүче иптәшләрен дошман утыннан саклый. 22 немецны юк итә.

Гыйззәтуллин бәхетле булып чыга. Сугышып, Германиягә кадәр барып җитә, Берлин операциясе вакытында яралана. 1947 елда демобилизацияләнә һәм Татарстанга кайта. Казан ТБЭ заводында эретеп ябыштыручы булып эшли.

Фото: kazgau.ru, wikipedia.org, millattashlar.ru

Татар язучылары һәм сәнгать әһелләре (сулдан уңга): Сибгат Хәким, Усман Әлмиев, Нур Баян, Җәүдәт Фәйзи, Муса Җәлил. 1939 ел.

КУРКУ БЕЛМӘС ҺӘМ БАШ ИМӘС ШАГЫЙРЬ

«Роталарның сугышчан рәтендә булып, яугирләрне һөҗүмгә күтәрде һәм алар белән бергә шәһәргә бәреп керде...» Бу Нур Баянны бүләкләү кәгазеннән бер өземтә. Хәрби начальникныкы түгел, шагыйрьнеке.

Нур Баянга I дәрәҗә Ватан сугышы орденын китерәчәк бәрелешләр 1944 елның сентябрь–октябрь айларында Венгриядә бара. Безнекеләр һөҗүм итә, һәм «майор иптәш Баян еш кына полк подразделениеләренең сугышчан рәтендә булып, үз үрнәге белән сугышчыларны батырлыкларга өндәде» дип билгеләнә шул ук бүләкләү кәгазендә.

1944 елның 16 октябрендә полкташлары белән һөҗүмгә күтәрелүчеләрнең беренче сафында кайсы шәһәргә керүе дә билгеле – Береттьоуйфалу. Шагыйрь Нур Баян сугышның беренче елыннан ук фронтка китә. Пәһлевандай гәүдәсе дә юк, күзлекле – гап-гади интеллигент. Дивизия газетасы редакторы, укчы полк парторгы була, әмма үз үрнәге белән ышандыруны, материалларны алгы сызыктан алып кайтуны өстен күрә. Кызыл Йолдыз һәм Ватан сугышы орденнары – шуның дәлиле.

Сугыш бетәргә ике атна кала һәлак була. 1945 елның апрелендә Австрия өчен сугышта. 15 майда Актаныш районының Әнәк авылында туып-үскән шагыйрь Нур Баянга 120 ел тулды. Казанда һәм Яр Чаллыда урамнарга аның исеме бирелгән.

P.S. Бөек Ватан сугышы кырларында 31 татар язучысы һәлак була (Татарстанның Язучылар берлегенә 50 язучы кергән. – *Ред иск.*).

Фото russianlook.com нан алынды

БЕЛЕШМӘ:
Пётр Михайлович Гаврилов. Майор, Советлар Союзы Герое, Брест крепосте оборонасында катнашучы. Казан губернасы Лаеш өязе Әлбәден авылында (хәзер Татарстанның Питрәч районы) туган. Кызыл Армия сафларында – 1918 елдан. Бөек Ватан сугышы алдыннан – Брестта урнашкан 44 нче укчы полк командиры. Немецлар Брест крепостена һөҗүм иткәннән соң, берничә подразделениедән җыелган сугышчылар төркемен җитәкли, төркем Кобрин ныгытмасының Төньяк капкалары янында сугыша. 24 июньнән Көнчыгыш форт оборонасын җитәкли. 1941 елның 29 июне кичендә Көнчыгыш форт бомбага тотылганнан соң, Гаврилов, төркемендә калган сугышчылар белән бергә, казематларга яшеренә һәм каршылык күрсәтүне дәвам итә. Төркем берничә көн чыгарга омтылыш ясый. 23 июльдә берүзе кала һәм авыр яраланган килеш әсир төшә. Сугыштан соң Краснодарда яши һәм эшли. Васыять итеп калдыргача, Бресттагы мемориаль комплекс каберлегендә көрәштәшләре янында күмелә. Казандагы, Бресттагы, Краснодардагы, Иркутскидагы һәм Питрәчтәге урамнар Петр Гаврилов исеме белән атала.

УТЫЗ ИКЕ КӨНГӘ СУЗЫЛГАН БАТЫРЛЫК

Әскәр Сабиров

44 нче укчы полкның элеккеге командиры, Брест крепосте сакчысы һәм Хаммельбург, Регенсбург немец концлагерьларының элеккеге тоткыны Пётр Гаврилов илленче еллар башында Краснодарда яши. Шәһәр кырыенда үз куллары белән вак-төяктән салынган тыйнак кына йорт, кечкенә генә хәрби пенсия (аңлашыла ки, әсирлек стажга керми) һәм күршеләрнең кыек карашлары...

ИСӘН КАЛГАНГА, ГАФУ ИТЕГЕЗ

Ярар, болай да яшәргә була. Ни дисәң дә, бу туган авылы Әлбәдендә аны 1946 елның июлендә авылдашлары каршы алуыннан яхшырак. Анда аны, немец тоткынлыгында булган кешене, халык дошманы кебек кабул итәләр. Урып-җыюда эшче куллар бик кирәк, ләкин аның ярдәменнән баш тарталар. Толлар артыннан каргыш яудырып кала. Питрәчкә, чүлмәк фабрикасына эшче булып китә. Аннан – бирегә, Краснодарга.

Гавриловка бәхет елмая, дияргә була. 1945 елның 2 маеннан соң, аларны, Регенсбург әсирләрен, америкалылар азат итә, майорны урман аударырга түгел, Башкириягә укчы полкына запаска җибәрәләр. Тикшергәннән соң, хәтта званиесен дә кире кайтаралар һәм армиядә калдыралар. Иркутск өлкәсендә аны япон хәрби әсирләре тотылган лагерьга башлык итеп билгелиләр. Партиядән чыгарылган Гавриловның (тоткынлыкта булган, партбилет югалган) хәрби карьерасын дәвам итү мөмкинлеге, әлбәттә, булмый инде. Бер ел да тотмыйча демобилизациялиләр, хәтта хезмәтендәге рәхмәтләргә дә карамыйча...

Краснодарда Пётр Гавриловның ни дисәң дә эше бар – станоклар төзү заводында экспедитор, ләкин алар көчкә очын-очка ялгап яши. Шулай килеп чыга: сугыштан соң ул хатыны Екатеринаны һәм уллыкка алган малаен эзләп таба алмый – алар вафат булгандыр дигән фикергә килә. Тагын бер тапкыр өйләнә, ә еллар үткәннән соң, Брестка баргач, улының исән икәнлеген, армиядә хезмәт итүен ишетә. Екатерина да исән булып чыга, тик нык авырый икән. Гаҗәп, Гавриловлар параличланган хатынны инвалидлар йортыннан үзләренә – Краснодарга алып кайтырга карар кылалар. Үлгәнчегә кадәр аны карыйлар-тәрбиялиләр.

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

ҮЛГӘННӘР АРАСЫНДА ИСӘПЛӘНӘ

Ул арада язучы Сергей Смирнов Брест крепостен геройларча саклаучылар турында документаль китап язарга ниятли. Аның кулында Брест крепостеның Көнчыгыш фортын каһарманнарча саклаган кызылармиячеләр турында немец донесениеләре була, ләкин оборонада катнашучылар арасында исән калганнарны тиз генә таба алмый. Ниһаять, Смирнов Брестта Көнчыгыш фортта сугышкан элеккеге лейтенант Яков Коломиец белән очраша. Коломиец Көнчыгыш форты оборонасын оештыручы кеше турында күп сөйли, ләкин аның фамилиясен исенә төшерә алмый. Смирнов аңа сугышчыларның истәлекләре буенча төзелгән командирлар исемлеген күрсәтә. «Мин 44 нче укчы полкның элеккеге командиры майор Гаврилов фамилиясенә җиткәч, Коломиец сискәнеп китте һәм, зур ышаныч белән, Көнчыгыш форт оборонасын майор Гаврилов оештыруы турында әйтте», – дип сөйли соңрак үзенең «Брест крепосте» повестенда Сергей Смирнов.

Смирновның исемлегендә Гаврилов үлгәннәр арасында исәпләнә. Коломиец киресен сөйли: «Гаврилов үлмәде!» Язучы Генштабка запрос юллый һәм ветеранның исән икәнлегенә инана. Гавриловның адресын алганнан соң, Смирнов аңа хат яза. «Мин хатта аны ничек эзләвем турында яздым, минемчә, аның Брест крепостенда, гаять зур каһарманлык күрсәтеп, батырлык кылуын да әйттем. Илнең бу турыда ишетәчәгенә һәм геройның кыюлыгын һәм фидакарьлеген лаеклы рәвештә билгеләячәгенә озак калмаганлыгына ышанам, дип тә өстәдем».

Ике атнадан соң Сергей Смирнов Пётр Гаврилов белән очрашачак. Аларның әңгәмәсе берничә көнгә сузыла. Геройның партия сафларына кире кайтырга тырышып та, уңышсызлыкка очравы турында ишеткәннән соң, язучы КПСС Үзәк комитетының партия контроле комиссиясенә мөрәҗәгать итә һәм анда майор Гавриловның нинди батырлык кылуы турында белгәннәрен сөйли. Бер үк вакытта Смирнов үз истәлекләрен сөйләгән барлык ветераннардан да Гавриловның крепость оборонасында катнашуы турындагы дәлилләрен, мөһер сугып, үзенә җибәрүләрен сорый.

БӘХЕТ БИЮЕ

Смирнов майор Гаврилов эше тикшерелә торган партия комиссиясе утырышында катнаша, ә аның Мәскәүдәге фатирында Пётр Михайлович карар көтеп утыра. Гаделлек тантана итүен ишеткәннән соң, язучы: «Мин 56 яшьлек олы кешенең кинәт кенә бала-чагадай, сөенечтән нишләргә белмичә, сикерә-сикерә биюен күрдем...», – дип яза.

Майор Гавриловның батырлыгы турында язучы Сергей Смирнов беренче тапкыр илгә радиодан «Брест крепосте геройлары турындагы хатлар арасында» дип аталган тапшыруда сөйли. «Брест крепосте» китабының берничә бүлеген майор Гавриловка багышлый. Бу Гавриловның Көнчыгыш фортны ничек саклаулары турындагы җентекле бәяне булачак. Өзек 1941 елның 23 июле – сугышның утыз икенче көнендә Гавриловның соңгы бәрелешкә күтәрелүенә кадәрге вакытны үз эченә ала.

Аның ничек әсирлеккә төшүе турында лагерь табибы хатирәләре китерелә: «Әсир майор командир формасында иде, ләкин бөтен киеме сәләмәгә әйләнгән, битен дары сөреме каплаган, сакал-мыек баскан. Ул яраланган, аңсыз хәлдә һәм соңгы чиккә җитеп ябыккан иде. Тире белән тарттырылган коры сөяккә калган скелет кына...»

Пётр Гавриловка Советлар Союзы Герое исемен 1957 елның 30 гыйнварында бирәләр. 1941 елда Брест крепосте оборонасында хәрби бурычын үрнәк рәвештә башкарганы һәм шул вакытта күрсәтелгән искиткеч зур кыюлыгы һәм каһарманлыгы өчен.

БЕЛЕШМӘ:
Михаил Петрович Девятаев. Гвардия өлкән лейтенанты, очучы-истребитель, Советлар Союзы Герое. 1941 елның 22 июненнән – хәрәкәттәге армиядә. Һава сугышларында 9 дошман самолётын бәреп төшерә. Соңгы «фоккер»ны 1944 елның 13 июлендә юк итә, шул ук көнне үзен дә бәреп төшерәләр, аңсыз килеш әсир төшә. Лодзь хәрби әсирләр лагереннан качу омтылышы өчен аны Заксенхаузен үлем лагерена күчереләр. Шундагы яшерен оешма кешеләре үлем көткән Девятаевның номерын башка, үлгән тоткынныкына алыштыралар, бу аның гомерен саклап кала. Степан Нитенко исеме астында Девятаев Узедом утравына җибәрелә, анда, Пенемюнде ракета үзәгендә, рейхның яшерен коралы – «Фау» ракеталары эшләнә. 1945 елның февралендә Девятаев һәм аның әсирлектәге тугыз иптәше немецларның «Хейнкель» самолётын кулга төшерә һәм шуңа утырып кача. Самолётны һавага күтәргән Михаил аны фронт сызыгына кадәр алып барып җиткерә – совет зениткалары белән утка тотылган «Хейнкель» 61 нче армиянең артиллерия часте карамагына төшеп утыра. «Фау» җайланмалары һәм яшерен завод турында Девятаев тапшырган төгәл мәгълүматларга таянып, полигон бомбага тотыла. 1945 елның сентябреннән соң, Девятаевны Сергей Королёв эзләп таба, Узедомда элеккеге әсир совет космик техникасының булачак баш конструкторына немец «Фау»лары ясалган урыннарны күрсәтә.
Илленче еллар ахырында ул су асты канатлары булган беренче суднолар – «Ракета» капитаны була, соңрак «Метеор»да шулай ук капитан булып эшли. Башкалабызның Мактаулы гражданины Михаил Девятаев Казанның Арча зиратында күмелгән.

ТОТКЫН КИЕМЕНДӘ ЮГАРЫ ПИЛОТАЖ ҮРНӘГЕ

Әскәр Сабиров

Атаклы Покрышкин дивизиясенең элеккеге очучысы һәм Заксенхаузен үлем лагереның элеккеге хәрби тоткыны Михаил Девятаев 1950 нче еллар башында – Казанда кечкенә генә катерның капитаны. Моны да зур бәхет дияргә була: сугыштан соңгы елларда эшкә урнашырга дип кая гына бармасын, кире боралар.

Мордовиядәге үзенең туган авылы Торбеевода балачак дусты, райком секретаре да яңгыратып яңагына суккандай итә аны: «Сиңа монда эш бар дип беләсеңме?! Монда Идел юк, әйдә, бар, үзеңнең Иделеңә кит»...

ГОМЕРЛЕК МӨҺЕРМЕ?

Казанда да элеккеге әсирләрне кочак җәеп каршы алмыйлар. Девятаев баштарак кайда туры килсә, шунда эшләп азаплана, баржаларга утын төйи. Аннан соң елга портында, кызганып, вокзал буенча кизү торырга алалар үзен. Аннан соң менә – катер капитаны. Ләкин ул төп гадел-сезлек белән һич кенә дә килешә алмый: аны, фашистлар әсирлегеннән дошман самолётында кача алган хәрби очучыны, хыянәтче дип саный-лар. Һәм һәрвакыт бу хакта искә төшереп торалар: берьюлы берничә вазыйфа башкарганнарга – өстәмә түләү, ә аңа – юк. Затон башлыгы тыныч-ландырырга тырышмак була: «Син әсирлектә булган кеше, эшкә алганга рәхмәт әйт». Хатыны Фәүзияне әледән-әле органнарга чакырып тора-лар: «Ирең нәрсәләр сөйли?» Девятаев Мәскәүгә хатлар юллый, тикшерүләрен, хыянәтче мөһерен алып атуларын сорый – җавапка тынлык.

Фото: Heinrich Hoffmann / ullstein bild via Getty Images

1956 ел. XX партия съездында Сталинның шәхес культы фаш ителә, ил репрессияләр һәм бер гаепсезгә хөкем ителгән миллионлаган кешеләр турындагы дөреслекне белә. Берничә айдан соң маршал Георгий Жуков ҮК Пленумында чыгыш ясарга әзерләнә: фашистлар белән хезмәттәшлек итмәгән әсирләрнең берсендә дә гаепләре юк, алар хыянәтче түгел... Пленум булмый кала, ләкин шулай да СССРда партия дәрәҗәсендә үк шуны аңлый башлыйлар: тоткынлыкта да үзләрен батырларча тотканнар бар, алар Ватанга хыянәт итмәгән.

ИСТРЕБИТЕЛЬ АВИАЦИЯСЕ «АРТИЛЛЕРИСТЫ»

1956 елның октябрендә «Советская Татария» газетасында бүлек мөдире, журналист Ян Винецкий, геройлар эзләп, Казандагы хәрби комиссариатларның бусагаларын таптый. Шуларның берсендә аңа ниндидер башка сыймаслык хәл турында сөйлиләр. Янәсе, фашист самолётында качкан артиллерист бар, җитмәсә, үзе белән бергә тугыз иптәшен дә коткарган. Винецкий, үзе дә элеккеге очучы буларак, берниндн артиллеристның да (ә Девятаев фильтрация лагерендагы писарьның ялгышы аркасында «артиллерист» булып китә) самолётны урлап кача алмаганын аңлый. Шулай да бу кешенең адресын ала.

«Артиллеристка» кунакка Винецкий, «Литературная газета»ның үз хәбәрчесе Булат Гыйззәтуллин белән бергә, кичке җидедә килә һәм иртәнге җидегә кадәр аларның сүзләре бетми. Девятаев үзе искә алганча, бу кичтә каенанасына самавырны биш мәртәбә яңартырга туры килә...

Очрашудан соң ай-ай ярым вакыт үтә. Шул вакытта гына Винецкий үзе турында искә төшерә – шалтыратып болай ди: «Михаил Петровичка әйтегез, мин органнарга барырга һәм бөтенесен дә тикшерергә рөхсәт алдым». Соңрак ачыкланганча, әлеге эш белән КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре дә кызыксынган икән...



Актёр Павел Прилучный «Девятаев» фильмында төп каһарман ролендә, 2021 ел.

БӘЙРӘМ ТАБЫНЫ

Ниһаять, очерк языла. Аны турыдан-туры «Литературная газета»га юлларга уйлыйлар. «Бөтен дөнья белсен өчен», – дип дәлилли үз ниятен Гыйззәтуллин. Яңа ел алдыннан бастырырга вәгъдә бирәләр. Аннан соң, 23 февральдә чыгачак, дип хәбәр итәләр… Ләкин Девятаевка «Патриот» журналыннан полковник килә: «Михаил Петрович, әйдә, берәрне тотып куйыйк әле! Мине монда Винецкий материалын тикшерергә җибәрделәр…»

Ян Винецкийның язмасы «Литературка»да 1957 елның 23 маенда басыла. Куанычыннан нишләргә белмәгән Девятаев тимер юл вокзалына йөгерә һәм газеталар сатып ала – ун сумга! Эштә затон башлыгын да алыштырып куйганнармыни. Җитмәсә, тагын Мәскәүдән, СССР елга флоты министры Зосима Шашковтан шалтыраталар: тиз арада – Мәскәүгә!

Мәскәүгә Михаил Петрович «Советская авиация» журналында эшләүче Георгий Евстигнеев белән бергә оча – спиртлы эчемлекләр төялгән Ил-14 транспорт самолётында. Пассажирларының каһарман очучы икәнен белеп алган лётчиклар аны коньяк белән сыйлыйлар. Шулкадәр юмартланалар ки, самолёт Мәскәүгә төшеп утыргач, Девятаев мондый кыяфәттә зур түрәләр янына барырга ярамаганлыгын аңлап ала. Министрга герой икенче көннең иртәсенә генә барып җитә, әмма соңга калганга ачулану түгел, йөзләренә дә чыгармыйлар. Киресенчә, министр барысын да чакырып, очучының батырлыгы, әсирлектә булганы өчен эшеннән чыгарылулары һ.б. турында сөйли. Ә сүзен төгәлләп, болай ди: «Михаил Петрович хәзер кайсыгыз янына керсә дә, ишекне аягы белән тибеп ачсын».

1957 елның августында Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Бүләк тапшырылганнан соң, ул ай буе Константин Симоновның дачасында кунак була. Язучы аның хөрмәтенә банкет оештыра, шунда Герой беренче тапкыр устрицаларны авыз итеп карый.

«ТАТАРСТАН» АРХИВЫННАН

«ТУГЫЗЫНЧЫ МАХСУС МӘКТӘП»

Алсу Троицкая

Фото: Александр Ефремов, kpfu.ru. Язмада ХһКнең Казандагы махсус 9 нчы мәктәбенең 80 еллыгына багышланган «Честь имею!» китабыннан өзекләр кулланылды.

Хәрби-һава көчләренең Казандагы махсус 9 нчы мәктәбен тәмамлаучыларның язмышы төрле. Әлбәттә, күбесенең тормыш юлы авиациягә бәйле. Араларында галимнәр, инженерлар, төзүчеләр, сәнгать әһелләре дә бар. Әмма бу мәктәпне тәмамлаучылар тормышта ни белән генә шөгыльләнсәләр дә, ир-ат дуслыгының бәһасен белгән чын ватанпәрвәрләр булып калалар.

БУЛАЧАК ГЕРОЙЛАР

1941 елның гыйнварында Казан урамнарында курсантлар формасы кигән чибәр егетләр пәйда була, барысында да кара шинель, куе зәңгәр төстәге китель һәм чалбар, киң каеш һәм хром ботинка. Зәңгәр петлицаларында – ВВС (ХһК) эмблемасы, аеру билгеләре өчпочмаклары һәм «СШ» хәрефләре. Беренче курсантлар. Аларның тәүге чыгарылышы 1941 елның 20 июненә туры килә.

Хәрби-һава көчләре махсус урта мәктәбенең беренче җитәкчесе Йосыф Туишевның педсоветтагы ялкынлы чыгышын укытучылар игътибар белән тыңлый:

– Безнең бурычыбыз – булачак геройлар тәрбияләү! Бернәрсә белән дә исәпләшмичә, партия һәм халыкка тугры калып, Ватан өчен гомерләрен бирергә әзер булган Кызыл Армия сугышчыларының тиңдәшсез каһарманлыклары турында без шәкертләребезнең күңеленә үтеп керерлек итеп сөйләргә тиеш...

Мәктәптә дәресләр тугыз ай элек кенә башланган. Һәм беренче чыгарылыш нәкъ сугыш алдыннан – 1941 елның 20 июнендә була. Әле генә мәктәпне тәмамлаган беренче рота егетләренең күбесе шунда ук фронтка китә.

Җиңү көненә кадәр Казанның 9 нчы махсус мәктәбен 651 курсант тәмамлый, һәм аларның

шактыена хәрби очышлардан әйләнеп кайту насыйп булмый...

1941 елгы тәүге чыгарылыш курсантларының бер өлеше башлангыч Югары авиация мәктәбенә укуларын дәвам итәргә җибәрелә. Алар арасында Александр Муравьёв (сугыштан соң ул туган мәктәбенә командир һәм әдәбият укытучысы сыйфатында әйләнеп кайтачак) та була. Аның «Девятая Казанская» дигән китабында беренче чыгарылыштагы курсташы Дамир Әюпов белән очрашуы сурәтләнә. Ул кайбер иптәшләренең язмышы белән таныштыра: «Дистәгә якын кеше һәлак булган. Синең белән бер партада утырган Борис Гужавин укчы-радист булган, самолётын 1943 елда бәреп төшергәннәр. Шулай ук Саша Шелымагин, Гриша Назаров, Женя Егоров – барысы да укчы-радист булып очкан. Сорокин белән Евлампиев Сталинград янында пехотада сугышканда һәлак булган. Андреев та шунда ук. Кайдадыр Сюнька Кулик та башын салган... Февральдә исә Рәим Учаров кайтты. Аның да сугышчан биографиясе данлыклы. 1942 елның көзеннән ЛИ-2 самолётында укчы-радист булган. Берлинны бомбага тотканда катнашкан. Бервакыт, фронт сызыгыннан читтә самолётына зыян килгәч, парашют белән сикергән, адашып йөргәч, партизаннар янына килеп чыккан, диверсияләрдә катнашкан, шуңа Кызыл Йолдыз ордены аңа бик кыйммәткә төшкән...»

«ХӘРБИ-ҺАВА УЧИЛИЩЕЛАРЫ ӨЧЕН КАДРЛАР ТУПЛАУ, КЫЗЫЛ АРМИЯ ХһК ОЧУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ОЧУЧЫ-КҮЗӘТЧЕЛӘРЕН ӘЗЕРЛӘҮ МАКСАТЛАРЫНДА РСФСР, УССР, БССР, ГРУЗИЯ ССР ҺӘМ ӘРМӘНСТАН ССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЛАРЫНА МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ СИСТЕМАСЫНДА ХӘРБИ-ҺАВА КӨЧЛӘРЕНЕҢ 20 МАХСУС УРТА МӘКТӘБЕН (СИГЕЗЕНЧЕ, ТУГЫЗЫНЧЫ ҺӘМ УНЫНЧЫ СЫЙНЫФЛАР СОСТАВЫНДА) ОЕШТЫРЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘРГӘ».

Совет хөкүмәтенең 1940 елның 6 ноябрендәге 2276 нчы «Хәрби-һава көчләре махсус урта мәктәпләрен оештыру турында»гы карары.

Исемлектә 9 нчы булып торган Казан махсус мәктәбенә Ленин һәм Лобачевский урамнары чатындагы бина бирелә. Бүген ул бинаны РФ Фәннәр академиясенең Казан филиалы били. Сугыш башлангач, анда госпиталь ачыла, махсус мәктәпне исә 6 нчы урта мәктәп бинасына күчерәләр (элекке Мариинск гимназиясе бинасы). Бүген биредә КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге лицей урнашкан.

ХЫЯЛГА ТАБА!

Гомумән, бөтен махсус мәктәпләр дә бер типта оештырыла. Укыту 8 сыйныфтан башлана, укыту программаларында хәрби эшне өйрәнүгә басым ясала. Махсус мәктәпләр турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә аны тәмамлаучыларга унынчы сыйныфтан соң теләсә кайсы хәрби училищега керү мөмкинлеге

Бүген бу тарихи бинада КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге лицей урнашкан. Биредә кайчандыр булачак очучылар әзерләнүен исә бина фасадындагы истәлек тактасы һәм музей искәртеп тора.

1952 елда мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаган Геннадий Ванюрихин. Техник фәннәр докторы, профессор.

бирелә. Мәктәпкә укырга керү җиңел булмый: кандидатларны махсус комиссияләр сайлап ала. Барлык гомуми белем фәннәре, бигрәк тә математика, физика, химия һәм чит телләр буенча белемнәр, сәламәтлек һәм физик әзерлек тикшерелә. «Готов к труду и обороне», Осоавиахим, «Ворошиловский стрелок», парашют спорты һәм башка оешмаларның спорт значокларына ия булу хуплана. Аңлашыла ки, бирегә иң талантлы, белемле һәм спорт яраткан үсмерләр генә элэгә ала.

Әлеге яшүсмерләрнең балачагы да бер үк төрле диярлек: күпләренең этиләре юк, ачлык-ялангачлык, мохтаҗлык. Шуңа күрә ХҺК махсус мәктәбенә укырга керү аларга исән калырга гына түгел, хыяллары – зәңгәр күккә якынаерга да булыша. Үсмерләрне тулысынча карап-тәрбияләп кенә калмыйлар, аларны иң яхшы педагоглар укыта, хәрби очучы карьерасына әзерләнеп, алар армия чыныгуы ала.

...Генаның этисе фронтта һәлак була, әнисе исә, колхозда хезмәт көненә бирелә торган «таяк»ка эшләп, өч баласы белән көч-хәлгә җан асрый. Шуңа күрә җидееллык мәктәптән соң Генаның укуын дәвам итү мөмкинлеге бөтенләй булмый. Бервакыт авыл советы секретаре Александр Юновидов юлында очраган малайга «Красная Татария» газетасын күрсәтә. Анда ХҺК 9 нчы махсус мәктәбенә укучылар җыю турында хәбәр ителгән була.

– Гена, мәктәпне мактау грамотасы белән тәмамладың, сине Казан мәктәбенә имтиханнарсыз кабул итәргә мөмкиннәр, – ди ул үсмергә.

Тиздән Геннадий Ванюрихин махсус мәктәп укучысына әйләнә. 1952 елда аны көмеш медальгә тәмамлый. Соңрак ул техник фәннәр докторы, профессор була:

– Мәктәп минем тормышымда хәлиткеч роль уйнады дию һич арттыру булмастыр...

Сугыштан соңгы авыр елларда Казанның иң яхшы урта мәктәпләреннән берсендә уку (мин хәзер дә шулай уйлыйм) минем өчен дә, сугышта этиләрен югалтып, яшәү өчен нормаль шартлар булмаган авыллардан һәм кечкенә шәһәрләрдән килгән күпчелек үсмерләр өчен дә бәйрәм булды. Безнең белән укучы курсантларның берсе өенә: «Без төнлә ап-ак җәймәләргә ятып йоклыйбыз, иртә белән исә атланмайлы ипи ашыйбыз», – дип хат язган иде. Без бу хатны аның тумбочкасыннан «табып алдык» һәм бергәләп укып көлештек. Әлбәттә, бу «әчке эшләргә» тыкшыну иде, әмма мәктәптә кагыйдәләр шундыйрак булды – бездәге хәлләр дә Николай Помяловскийның «Очерки бурсы» әсәрендә сурәтләнгәннәргә бераз охшаш иде. Ә ачы хакыйкать шунда ки: күбебез моңа кадәр ап-ак җәймәнең дә, иртәнге яки кичке ашка атланмайлы ипинең дә нәрсә икәнен белми иде...

«САМОЛЁТЛАР ҮЗЛӘРЕ ГЕНӘ ОЧА АЛМЫЙ...»

«Тугызынчы Казан» мәктәбен ачканда Туишевка шәһәрнең иң яхшы укытучыларын сайлап алу мөмкинлеге бирелә. Шунлыктан биредә шәкертләр стройда йөрү, атарга өйрәнү, армия уставын ятлау һәм хәрби очучы һөнәре үзенчәлекләрен өйрәнү белән беррәттән, башка барлык предмет һәм фәннәр буенча төпле белем алу мөмкинлегенә дә ия була. Бу исә аларның барысының да киләчәк тормышында нык булыша. Мәктәпне тәмамлаучылардан менә дигән авиация инженерлары, конструктор, галим һәм, әлбәттә инде, пилот, очучы-сынаучылар чыга.

...1962 елның сентябрендә тавыш тизлегеннән югарырак тизлек белән оча торган Е-8/1 истребителен сынау тәҗрибә-конструкторлык бюросының шеф-пилоты Георгий Мосолов өчен чак кына фаҗигагә әйләнми кала. Тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә самолёт кабинасыннан катапультацияләнгәндә ул авыр җәрәхәтләнә. Табиблар аның гомере өчен озак көрәшә, коткарып кала, әмма СССРның атказанган очучы-сынаучысы, Советлар Союзы Герое, полковник, авиациядә тизлек һәм биеклек буенча алты дөнья рекорды (шулардан өчесе – абсолют) авторының очу биографиясе шуның белән тәгәлләнә.

Очучы-сынаучы, Советлар Союзы Герое, авиациядә алты дөнья рекорды иясе Георгий Мосолов.

Георгий Мосоловның авиациядә эшләү дәвере пешкәкле самолётлардан – реактив, тавыш тизлегеннән акрынраклардан тавыш тизлегеннән югарырак оча торганнарына күчү чорына туры килә. Ул үзе бу турыда менә нәрсә сөйли торган була: «Безгә, әлеге бурычларны беренчеләрдән булып хәл итә башлаучыларга, шунысы яхшы мәгълүм: алга таба ясалган һәр адым конструкторларның искит-

Ике якын дус – Юрий Гагарин һәм Георгий Мосолов.

* «Очерки бурсы» – Николая Помяловский повесте.

кеч акыл киеренкелеген, эшчеләрнең осталыгын һәм зирәклеген, инженерларның һөнәрмәндлеген, очучы-сынаучыларның эшкә фидаиләрчә тугрылыгын таләп итә иде. Чөнки самолётлар үзләре генә оча алмый. Аларны әле моңа өйрәтергә кирәк».

Аны «Микоян фирмасы тормышындагы тулы бер эпоха» дип йөртәләр – гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул «МиГ» корпорациясе генераль директоры – генераль конструкторының консультанты була. Георгий Мосолов – Казандагы 9 нчы махсус урта мәктәпне тәмамлаган 2 мең курсантның берсе. Атаклы мәктәпне ул 1944 елда бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган.

ТӨП УРАМНАН ОРКЕСТР БЕЛӘН

Актлар залыннан ишетелгән тавышлар какофониясе кинәт туктап кала – махсус мәктәптә тәртип шулай да иң мөһиме бит. Егетләр уен коралларын үз урыннарына куя.

– Иртәгә, шәхси ял вакытыгызда, репетициягә көтәм, – үсмерләр яратып «Дядя Стёпа» дип йөрткән укытучыларының тавышын барысы да ишетә, музыкантлар уку бүлмәләренә тарала.

Тынлы оркестр! Анда уйнау турында үсмерләрнең барысы да диярлек хыялланa. Һәм тынлы оркестр җитәкчесе, талантлы музыкант, педагог Степан Воронцов беркемне дә кире какмый. Бергә өлкән сыйныфлар да, яңа гына мәктәпкә кергәннәр дә йөри. Шәһәрдә популяр булган оркестр кайларда гына уйнамый! Бигрәк тә бию кичәләрендә уйнарга ярата. Һәм инде ул чакта тыелган танго һәм фокстрот, падеграс һәм падеспань биюләре аеруча кызыксыну уята...

«СПЕЦ» МОРАТОВ НИЧЕК АКТЁРГА ӘЙЛӘНГӘН

Йөреп арыгач, ул ВДНХ янындагы фонтан янына барып утыра, тәмәке кабыза. Янәшәдәге күзлекле кеше дә тәмәкесен

кабыздыртырга сорый, аннары йөзе көнчыгыш якка тарткан, җитмәсә матур очучы формасы кигән егетне кызыксынып күзәтергә башлый. Егетнең ВГИК бинасына карап-карап куюын сизгәч, елмаеп сорау бирә:

– Шунда укырга керәсегез киләме?

– Әйе.

– Йәгез, берәр нәрсә сөйләп күрсәтегез алайса.

Егетнең Маяковский шигырен яттан сөйләве ир-атка ошый:

– Иртәгә институтка килегез, 122 нче аудиториягә. Минем яныма, дип әйтерсез...

Чыннан да, бәхетле очрашулар көтмәгәндә була. Шул рәвешле Казандагы 9 нчы махсус мәктәпне тәмамлаган Раднэр Моратов Михаил Роммның үзендә укый башлый. Соңрак ул «Джентльмены удачи» комедиясендә төшеп дан казана, андагы Василий Алибабаевич роле «спец» Моратовны бөтен илгә таныта. Әмма, кызганыч, ул инде зәңгәр күкне буйсындыра алмый...

Футбол, волейбол, тынлы оркестр, бию коллективы, театр түгәрәге, җиңел атлетика, чаңгы, По-2 самолётыннан 800 метр биеклектән парашют белән сикерүләр... Дөрес, соңгысы махсус мәктәпнең укыту программасына керми, әмма егетләрнең бөтенесе дә диярлек ДОСААФ составында була. Биредә аларның парашют белән сикерүен шәһәр аэроклубы аша оештыралар. Табигый ки, мондый универсаль белем һәм күнекмәләргә ия курсантлар очучыдан алып актёрга кадәр – әллә кемнәр була ала.

Һәм гомумән, аларның нинди һөнәрдә уңышка ирешүе мөһим дә түгел бит. Аларның һәркайсы бу тормышта үз урынын таба...

Александр Серыйның «Джентльмены удачи» комедиясендәге Василий Алибабаевич роле «спец» Раднэр Моратовны бөтен илгә таныта. Әмма, кызганыч, ул инде зәңгәр күкне буйсындыра алмаячак... Фильмнан кадр.

Фото Усад урта белем биру мәктәбе укытучысы Татьяна Коробкованың «Советлар Союзы Герое Павлов Г.Р.» презентациясеннән алынды

ГРИГОРИЙ ПАВЛОВ: «ГИТЛЕРЧЫ, КҮРӘСЕҢ, ЮК ИТТЕМ ДИП УЙЛАП, МИҢА БӘЙЛӘНҮДӘН ТУКТАДЫ»

Сугышның икенче көнендә немец авиациясе һөҗүменнән соң Ковель янындагы аэродром бөтенләе белән тар-мар ителә: безнең самолётлар һавага күтәрелә дә алмый кала. Григорий Павлов канлы бәрелештән исән калган очучылар белән яңа эш урынына җәяүләп бара. Ике елдан соң, 1943 елның 2 сентябрендә, аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә...

Григорий Павлов Керасиново авылында туган (хәзер Татарстанның Биектау районына карый). Авыл егете өчен һавага юлламаны Казан аэроклубы бирә. Сугыш башланганда ул өлкән лейтенант була. Безнең очучыларга Геринг аслары биргән беренче сабакларны ул бик тиз отып ала. Немецлар Ковель янындагы аэродромны юк иткәннән соң өч көн үтүгә, Павлов үзебезнең И-153 самолётында беренче «мессер»ны бәреп төшерә, гәрчә безнең самолёт дошманныкыннан тизлеге белән дә, коралланышы белән дә кайтышрак булса да.

Сугышның дүрт елы дәвамында Григорий дошманның 25 самолётын бәреп төшерә: 16сын – шәхсән үзе, 9ын төркем белән алышка чыккач. Җиңү көненнән соң Хәрби-һава академиясен тәмамлый, аннан соң – Генераль штаб академиясен. Отставкага генерал-лейтенант буларак, Төньяк Кавказ хәрби округының Хәрби-һава көчләре командующие вазифасыннан китә.

Гомеренең соңгы елларында Григорий Павлов Киевта яши, «Сугыш барган күктә» дигән хатирәләр китабын яза. 1995 елда «Украина» нәшрияты аны басмага әзерли, әмма китап дөнья күрә алмый кала. Нәшрият кулъязманы авторга кайтарып бирә, җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләргә игътибар итәргә киңәш бирә. Озакламый Григорий Родионович вафат була...

Кулъязманы берничә ел гаиләсендә саклыйлар, җиде ел узгач, аның бер өзеген «Военно-исторический журнал» бастырып чыгара, соңыннан кайбер бүлекләре «Республика Татарстан» газетасында дөнья күрә.

ГРИГОРИЙ ПАВЛОВНЫҢ «СУГЫШ БАРГАН КҮКТӘ» КИТАБЫННАН ӨЗЕК:

«Юнкерс»лар һәм «мессершмитт»лар мөмкин кадәр түбәннән оча, пике ясый һәм туктаусыз ут яудыра. Мин аэродром чигендә хасил булган чокырларга ташландым. Баш өстеннән үкерә-үкерә дошман истребителе очып үтте, пулемёттан аткан очередь очучылар качкан чокырга туры килде. Аларга һавадан ату җайлы иде. Бу чокырларда гына качып-котылып булмаганын аңлаганнар, сикереп чыгып, үлемнән ераккарак качарга тырыша башлады. Әмма гитлерчылар аларга да ата иде. Бер генә нәрсә кала – җиргә егылырга да үз чиратың җиткәнне көтәргә.

Берничә минуттан дөнья тынып калды. Бары тик төтен, кан һәм янып бетеп барган самолёт калдыклары гына фаҗига турында искәртеп тора. Безнең күпләребез, исән калганнар өчен, бу фаҗига сугышның коточкыч кансызлыгын һәм гамьсезлекнең аянычлы нәтиҗәсен ачты. Авиаторлар немецларның аэродромда самолётларның күпләп җыелуын махсус көтеп һөҗүм итүен чамалый иде.

Июньнең кыска төне фаҗигале киеренкелектә узды. Кешеләр йокы һәм ял турында онытты – алар кайгысы юк иде. Янгын сүндерәләр, яралыларга ярдәм итәләр, үлгәннәрне җирлиләр. Алга таба ни булыр дип уйлыйлар. Без җиңәчәгебезгә ышана идек һәм җиңү хакына гомеребезне бирергә

дә әзер. Әмма сугышта дошманны җиңәр өчен бик күп белергә дә кирәк әле...

...Без Коськов, Варваровка, Врублевка, Тирановка аэродромнарын, Шепетовка тимер юл төенен саклап-каплап торырга тиеш идек, 148 нче бомбардировка полкының самолётларын озата бару, һава разведкасы ясау, дошманның җир өстендәге гаскәренә һөҗүмнәр оештыру, дошман самолётларын тотып алу да безнең бурыч иде.

Безнең очучылар ун тапкыр көчлерәк дошманга каршы чыкты. Бәреп төшерелгән бер немец очучысы сорау алганда болай дип кычкырып җибәрде:

– Сезнең очучылар – акылдан шашканнар! Көчләрнең шул дәрәҗәдә тигезсезлеген күрә торып һөҗүмгә ташлана!

«Мессершмитт»ның «Чайка»дан өстенлеген (тизлектә, вертикаль рәвештәге манёврда һәм утның көче ягыннан) мин беренче һава бәрелешендә үк аңлап алдым. Өчәр звено белән (тугыз «Чайка» И-153 самолёты) Славут, Острог, Ровно районнарында җир өсте гаскәрләрен сакларга очтык. Болытларның астына ук терәлеп, йомык саф белән барабыз. Алай уңайлырак: җир дә, һава да яхшы күренә. Болытлар арасындагы яктылыкта «мессершмитт»лар төркемен күреп алдым. Алар дүрт-биш мең метр биеклектә барраж ысулы белән пар-пар булып очлы пеленг ясап оча иде.

Санадым: унике. Безне күрерләрме? Безнең биеклек – 2000 метр. Тактик яктан дошман сиңа өстән һөҗүм иткәндә отышлы түгел. «Мессершмитт»ларга кадәр биеккә дә күтәрелә алмыйбыз – тизлек югала да авыр хәлдә каласың. Әмма безнең тугызлыкның әйдәп баручысына өстебездә «Мессершмитт»лар баруы турында ничек хәбәр итәргә? Радио юк. Ул аларны күрәме икән?

Алга чыгам да кулым белән өскә күрсәтәм, канатларны болгыйм. Әйдәп баручы башын селки: «Дошманны күрәм». Очышны алдан сөйләшенгәнчә, «елан» кебек дәвам иттерәбез. Безнең максат – бомбардировщиклар. Аларны куып тарату, бомбаларын безнең гаскәрләр өстенә ташларга ирек бирмәү.

«Юнкерс»лар һәм «хейнкель»ләр совет истребительләренең кыюлыгы белән таныш иде инде. «Мессершмитт»лар болытлар артыннан безне тоткарлап, үзләренең пикировщикларына ирек бирергә йөрмиме икән? Болытларга ук терәләбез һәм әлегә күренми торабыз.

Хачка охшаган ике күләгә бездән аста ялтырап алды – ике «мессершмитт» каршыдан кистереп үтте. Икенче пары ян-якта күренеп алды да өскә менеп китте. Аңлашылды: болар – һава разведчиклары. Хәзер инде алар радио аша һөҗүм төркемен чакырачак та, бәрелеш булачак.

«Мессершмитт»лар кинәт болытлар артыннан чыктылар да зур тизлектә аска томырылдылар – һөҗүмгә күчтеләр. Безнең әйдәп баручы, үзенең манёврлы «Чайка»сын канатына куеп, туп-туры дошманга ташланды. Без аның үрнәгенә иярдек. Һәм менә дошман истребительләре, һаваны утлы трассалар белән телеп-телеп, коточкыч өермәдә әйләнә башлады.

Минем «Чайка»ның вираж радиусы «мессершмитт»ныкына караганда шактый кечерәк, шулай да аның койрыгы янында әйләнәм. Берничә тапкыр дошманны прицелга да алдым, әмма безнең очучылар телендә «арык» дип йөртелгән Ме-109 самолёты зур тизлек белән миннән ераклаша, эреп югала башлады. Пулемёттан атуыбыз һавада сүнеп кала. Ул чагында мин, самолётның борынын өскәрәк чөеп, киртәле ут белән бәрә башладым.

Бер «арыгы», минем һөҗүмнән өскә таба качып, киртәле ут астына килеп керде, болытларга таба китә башлады. Әмма анда аны безнең очучыларның берсе ачкан пулемёт уты куып тотты, һәм дошман очкычы яшен суккандай шартлады. «Җиңдем!» – дигән шатлыклы уй йөгереп узды баштан.

Шул ук мизгелдә минем кабина өстеннән кызыл ялкын телләре ялтырап узды. Мин кинәт кенә идарә рулен алга тарттым, «Чайка» аска томырылды, ә «мессершмитт» өскә сикереп үтте.

Тиз арадагы реакция мине үлемнән коткарды. Нindидер мизгелдә реакция булмый калса, дошман уты минем самолётны телеп үтә иде. Шунда үзем өчен икенче бер нәтиҗә ясадым: җиңүгә алданып, яуда уяулыкны югалтырга ярамый.

Җиргә якынлашкач, самолётны пикедан чыгарганда, мин өскә карадым һәм, ни гаҗәп, анда беркемне дә күрмәдем. Гитлерчы, күрәсең, юк иттем дип уйлап, миңа бәйләнүдән туктаган иде...»

БЕЛЕШМӘ:
Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев. 1923 елның 23 июлендә туа. Армия генералы, Бөек Ватан сугышында, Япония белән сугышта, тагын 4 сугышта һәм локаль конфликтларны җайга салу операцияләрендә катнаша, шул исәптән – Әфганстанда да. Хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы. 1995 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр – Хәрби фәннәр академиясе президенты. 250 дән артык фәнни һәм публицистик хезмәт авторы. Алар арасында мондыйлар бар: «Хәрби фән», «Әгәр иртәгә сугыш булса», «Сугышның бәхәсле сәхифәләре», «Маршал Жуков. Гаскәр белән идарә итү сәнгатенең уникальлеге һәм бөеклеге», «Бөек Җиңү полководецлары һәм хәрби мирас» һ.б. Ленин ордены, дүрт мәртәбә Сугышчан Кызыл Байрак ордены, Александр Невский ордены һ.б. хәрби орден-медальләр иясе. 2019 елның 27 декабрендә Мытищидагы Федераль хәрби-мемориаль зиратта җирләнә.

СОЛДАТ ГӘРӘЕВНЕҢ МӘҢГЕЛЕК СУГЫШЫ

Әскәр Сабиров

«Миңа инде куркырга соң. 1941 елда Ташкент хәрби училищесын тәмамлап чыккан төркемебездән 26 кеше генә әйләнеп кайтты. 119 дан – 26. Миңа язмыш сугыштан соң болай да 40 ел гомер бүләк итте, ризасызлык белдерү гөнаһ булыр иде...» – дип җавап бирә Мәхмүт Гәрәев СССР оборона министрының: «Куркытмыймы?» – дигән соравына.

Үзенең алтынчы сугышына, Әфганстанга, генерал-полковник Мәхмүт Гәрәев 1989 елның февралендә килеп төшә – совет гаскәрләрен чыгарырга бер атна вакыт калганда. Вазыйфасы – президент Нәҗибулланы сакларга куелган безнең хәрби-оператив төркем белән җитәкчелек итү. Башың Себер китәрлек вазыйфа, дөресен генә әйткәндә: Көнбатыш хәрби аналитиклары барысын да инде исәпләп чыгарган була – Әфганстаннан безнең күпсанлы контингентны чыгаруга, Нәҗибулла хакимияте ике-өч атна эчендә җимерелеп төшәчәк.

ЫШАНЫЧСЫЗ БУЛМЫЙ

«1941 елда, Мәскәү янында хәлиткеч сугышлар барганда, бер сапёр юл баганасына: «Берлинга кадәр – 2000 км» дип язып куя. Тирән карга чума-чума янәшә атлаган җәяүле солдат болай дип өсти: «...Ярар, җитәрбез!» («ярар» урынына сүзнең катырагы әйтелә, әлбәттә). Фронтта булган әлеге хәлне ул бик еш искә төшерә. Шул ук вакытта һәрвакыт болай дип тә өстәп куя: «Мондый солдатлар һәм аларны тудырган һәм үстергән халык барысын җиңә, ул җиңелә алмый!»

Теге чакта, беренче сугышта, иң куркынычы бомбага тотулар булган аның өчен. Бу турыда 1942 елда аларның батальонына килгән хәрби корреспондентка сөйли ул. Кайдадыр Медынь

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

тирәсендә, Көнбатыш фронтта. Батальонны яңа гына алдагы сызыктан чыгарганнар, алар урман аланында окоплар казу белән мәшгуль чакка туры килә корреспондент. Хәбәрче төпченә, барысын да беләсе килә, куркыныч янаганда, кемнәрнең нәрсә кичерүен ачыкларга тырышып аптырата. Комбат Гәрәев аңа үз куркулары мисалында аңлатып бирә: һөҗүмгә барганда бер нәрсәне төгәл беләсең – йә син дошманыңнан өстен чыгасың, йә ул сине юк итә. Артиллерия снаряды төшкән бүрәнкәгә төшеп сеңгән очракта исән калырга мөмкинсең: ихтималлык теориясе буенча икенче снаряд анда төшмәскә тиеш. Әмма менә өстән бомбага тотканда, берничек тә котылу мөмкинлегең юк, көчсезлектән нишләргә белмисең...

1941 елның ноябрендә беренче мәртәбә бомба астында калганнан соң, догалар укый башлавы турында командир Гәрәев корреспондентка әйтеп тормый, билгеле. Комсомолларча, ул да динне искелек калдыгы дип саный. Әмма еллар узгач, әлеге эпизодны хәтеренә төшереп, аңлатырга кирәк дип таба: «Сугыш – коточкыч нәрсә. Адәм баласы, язмышы белән бергә-бер калгач, яклау эзли башлый. Әгәр син үзеңнән өстен һәм сине яклый, саклый ала торган көч барына ышанасың икән, иң өметсез мизгелләрдә ул синең ягыңдадыр кебек тоела. Һәм монда синең нинди дин вәкиле булуың инде әллә ни зур әһәмияткә ия түгел».

Батальонга килгән хәбәрченең фамилиясе Симонов булып чыга. Аларның хәрби юллары әле бер генә мәртәбә түгел, күп тапкырлар кисешәчәк, хәтта дуслашып та китәчәкләр. Инде беренче очрашудан соң күп сулар аккач, 1974 елда, язучы Константин Симонов фронтташ иптәшенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә: хәрби архивларга кертмиләр. Генштабның хәрби-фәнни идарәсе башлыгы Мәхмүт Гәрәев рөхсәт боерыгы бирә. Моның өчен аңа партиянең баш идеологы, КПСС ҮК секретаре Михаил Сусловның рөхсәтен алырга туры килә.

ЙӨЗ МЕҢ УРЫНЫНА БЕРҮЗЕ

– Совет гаскәрләре чыгарылгач, монда килергә ничек гайрәтегез җитте? Без ничек, кем ярдәмендә каршы тора алырбыз икән соң? – Әфганстан Хәрби көчләре югары башкомандующие, ил президенты Нәҗибулла Кабулда үзенең баш хәрби киңәшчесен әнә шулай каршы ала. Сүзләрендә аптырау катыш ирония дә яңгырый.

Гәрәев тә сүзгә төшеп калганнардан түгел: «Рус армиясендә борын-борыннан бер мәкаль йөри: «Яхшы командир бер татарны да ике рәткә тезеп бастыра ала». Мөселманнар буларак, бергәләп тырышып карыйк, бәлки, сезнең рәтләрне дә икегә тезә алырбыз. Соңгы чиккә, соңгы мөмкинлеккә кадәр тырышырга гына кирәк...»

Командировкасына ел ярым дигәндә, Мәхмүт Гәрәевне Әфганстаннан чакыртып алалар. Өенә ул инде армия генералы дәрәҗәсендә кайтып төшә. Совет армиясе чыгарылганнан соң, Көнбатыштагылар фаразынча, күп дигәндә, 3 атна гомере калган Нәҗибулла хакимияте әле Гәрәевтән соң да яшәп кала. Пакыстандагы газеталарның берсе бу хакта болай дип яза: «Руслар Әфганстаннан үзләренең йөз мең солдатын чыгардылар, әмма бер татарны керттеләр...»

«БЕРКЕМ ЮК, БЕРКЕМ ДӘ КАЛМАДЫ»

Кече лейтенант Гәрәев беренче тапкыр яуга 1941 елның ноябрендә керә. Немецлар башкалага бик якын килгән вакыт: Мәскәү янындагы Чернышевский казармаларыннан фронтка кадәр кыска гына ара калган була. Фронт сызыгына җәяү дә барып җитәргә мөмкин. 18 яшьлек Гәрәев взвод кабул итеп алырга тиеш, әмма өлгерми кала. «Батальонга килеп төштем. Каршыма кулы бәйләүле старшина килә. Яралы. «Батальон командиры кайда?» – дип сорыйм. «Юк», – ди ул. «Ә офицерлардан кемнәр бар?» – дим. «Беркем юк, беркем дә калмады», – ди. Миңа батальон белән командалык итәргә туры килде, гәрчә штат буенча комбат – подполковник, бер дә булмаса майор дәрәҗәсендә булырга тиеш булса да.

Әфганстанда командировкада.

Ике тәүлектән соң батальон командиры итеп бер капитанны җибәрделәр. Миңа рота белән җитәкчелек итү йөкләнде...»

Гәрәев өчен сугышның 1942 елның августында ук Калуга өлкәсендә тәмамлану мөмкинлеге була. Җәйге һөҗүмнәр вакытында ул аерым рота белән командалык итә. Атакага күтәрелгәндә яралана. Кулын тиз генә бәйли дә янә яуга ыргыла. Яңа командир килеп җиткәнче, ике көн сугыш кырында була. Ул арада кулы кара янып чыга. Медсанбаттагы хирурглар озак сөйләшеп тормый, кисәргә дигән карарга килә. Шунда олы яшьтәге бер санитарка ярдәмгә килә: егетне эшелон белән бергә Рязаньга җибәрттерә. Андагы госпитальдә Гәрәевнең кулын саклап калалар.

БЕР ГЕНӘ УЙ: «ИСӘН КАЛАММЫ-ЮКМЫ?»

1944 елда Мәхмүт Гәрәев батальоны Молодечнога (Мәхмүт Гәрәев бу шәһәрнең Мактаулы гражданины – *ред. иск.*) беренче булып керә. «Узып барышлый», Белоруссия операциясе вакытында, аның солдатлары Ворошилов исемендәге партизан отрядында сугышкан берничә мең кешене коткара. Тылларын чистартырга дип, немецлар партизаннарга каршы берничә дивизия ташлый. Отряд урмандагы күл буена яшеренә, әмма аларны бөтен яктан уратып алалар. Азык-төлексез калган сугышчылар һәлакәткә дучар ителә. Гәрәев подразделениесенең юлсыз шартларда көтелмәгән һәм кискен марш-бросок ясавы нәтиҗәсендә немецларның чылбыры өзелә, әсирлеккә һәм үлемгә мәҗбүр ителгән үзебезнекеләрне коткару мөмкинлеге ачыла...

«Сугышның буеннан-буена, 1944 елның уртасына кадәр, мин иң түбән звеноларда сугыштым, – дип сөйли бер әңгәмәсендә Мәхмүт Гәрәев. – Рота командиры, батальон штабы башлыгы, комбат, аннан соң – бригада звеносында оператив бүлек башлыгы. Җиңел вазыйфалар булганын хәтерләмим. Һәрвакыт – сугышта, окопта. Сугышның һәр көнен бүген исән каламмы-юкмы дип уздыра идек».

Мәхмүт Гәрәев полкташлары белән.

Илле елга сузылган армия хезмәте дәвамында ул СССР Генштабы башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бу үсеш – Садовое кольцо чигендә үз җиңүләрен «әвәләгән» штаб офицерларының карьерасы белән чагыштырып та булмый торган батырлык елъязмасы. Сугыш фәнен Мәхмүт Гәрәев Мәскәү яны окопларында, Ржев сазлыкларында, Кенигсберг өчен каты бәрелешләрдә үзләштерә. Инде аннан соң гына – академияләрдә...

ҖИҢҮДӘН СОҢГЫ СУГЫШЛАР

1945 елның 9 маен майор Гәрәев Ерак Көнчыгышта хәрби эшелонда каршылый. Япониянe җиңгәннән соң – Кытай, анда Мәхмүт Гәрәев Халык-азатлык армиясен төзергә ярдәм итә. Алга таба инде - Сүрия вакыйгалары, Мисыр, җитмешенче елларда ул безнең хәрби киңәшченең штаб башлыгы вазыйфасын башкара...

Хәрби фәннәр докторы Мәхмүт Гәрәев белән профессиональлектә күпләр ярыша алганмы? Ул үзе, бу сорауны биргәндә, тормышындагы бер вакыйганы искә алып сөйләргә ярата. Бу хәл аның яшь чагында, хәрби хезмәтенең башында була.

«Рота белән тар гына юлдан барабыз, як-ягыбызда – кыр. Каршыга сугышның ачысын да, төчесен дә татыган тәҗрибәле сержант килә, медсанбатка барышы. Минем яшь икәнемне күрептер инде, болай ди: «Әй, лейтенант, – ди, – син нәрсә, нишләп ротаңны колонналап алып барасың? Бүлгәләргә кирәк!» Мин бүлдем: бер рәтне – уңга, икенчесен сулга куйдым. Алга таба юл тотабыз. Каршыга – тагын бер сержант. Анысы да дәшми генә уза алмады: «Син нәрсә, лейтенант, солдатларыңны минага эләктереп, күккә очырырга телисеңме? Колоннага тез дә үзләрен, юлның кыл уртасыннан алып бар!» Тездем, алып киттем... Аннан соң, күп гомерләр үтте, мин ике академия тәмамларга өлгердем, әмма ике киңәшченең кайсы хаклы булуына тәки төшенә алмадым», – дип, көлеп, сүзен тәмамлый Мәхмүт Гәрәев.

1945 елның 1 мае.

Хәрби тарих белән кызыксыну – монысы да аның карьерасының аерылгысыз бер өлеше. Кайбер батырлыклар турында вакытында белүе-

без өчен без нәкъ менә аңа бурычлы һәм рәхмәтле: майор Петр Гаврилов һәм Брест крепостен яклаучылар турында, әйтик. Сугыштан соң берничә ел узгач, Гәрәев Брест крепостена дивизия полкының штаб башлыгы булып билгеләнә. Озакламый әлеге дивизиянең командиры вазыйфасын йөкләүләр аңарга. Сугышчылар чәрдәкләнеп беткән кирпечләрне актарганда коралларга, диварлардагы язуларга юлыгалар. Крепостьны саклаучыларның язуларына. Гәрәев бу хакта «Огонёк» журналына хәбәр итә. Шуннан соң Брестка язучы Сергей Смирнов килеп төшә...

ХАКЫЙКАТЬНЕҢ ТӨГӘЛ КОРАЛЫ

Галим һәм фронтовик Мәхмүт Гәрәев язган соңгы китапларның берсе – «Сражения на военно-историческом фронте» дип атала. Бу китап, әлбәттә, сугыш турында. Гәрәевнең җиденче, соңгы көннәренәчә дәвам иткән сугышы турында. Дөреслек, хакыйкать өчен сугыш. Ялганга һәм фальсификациягә каршы сугыш ул. Җиңүнең мәгънәсен һәм дәрәҗәсен киметергә, төшерергә тырышучыларга каршы сугыш.

Бу җиденче сугышны Мәхмүт Гәрәев һәм Хәрби фәннәр академиясе (ул – Академиянең алыштыргысыз президенты) соңгы дистә еллар дәвамында алып барды. Аның без искә алган китабы да, күпсанлы башка басмалары да – тарихны яңабаштан үз җайларына язарга омтылучыларга каршы ачылган утка тиң. Ул бу фальсификаторларга бернинди мөмкинлек тә калдырмый: фактлар, саннар, дәлилләр – Гәрәевнең коралына каршы корал юк җир йөзендә. Чөнки ул барысын да үз язмышы һәм йөрәге аша кичергән. Моннан тыш – җентекләп туплаган, өйрәнгән, чагыштырган, ваемлаган.

Ул һәр сан артында кеше гомере торганын бик яхшы аңлый – яу кырында ятып калганнар күз алдында торганга, мөгаен. Шуңа да бәхәсләр вакытында аның бер генә карышка да компромисска бармавы аңлашыла. Сүз югалтулар, саннарны алыштырулар турында булса – бигрәк тә. «Бу инде историография түгел, статистикага да бернинди катнашы юк моның, бу – пычрак сәясәт», – дия иде ул. «Кайберәүләрнең югалтуларны күбрәк булуын исбат итәсе килә, шул рәвешле алар Җиңүнең бәясен киметергә тырыша, – ди Мәхмүт Гәрәев. – Бу тема - бик четерекле һәм яраларга тия торган, фронтовиклар өчен – бигрәк тә. Бу мәсьәләдә ярыш юлына басу – коточкыч хәл».

Мәхмүт Гәрәев югалтуларны раслау комиссиясенең рәисе булып тора һәм аның иманы камил: «Югалтулар турындагы хакыйкатьне кешеләргә җиткерү – кирәк эш. Моны эшләмәсәк, без сугышның нәтиҗәләрен билгели алмыйбыз, җиңүнең нәрсә бәрабәренә яулап алынуын да бәяләү мөмкин түгел». Нәкъ менә Мәхмүт Гәрәевкә саннарның халыкка барып ирешүе өчен рәхмәтле булырга тиешбез: Советлар Союзының Бөек Ватан сугышындагы югалтулары – 26, 5 миллион кеше гомере. Шуларның

Җиңү парады. 2015 ел.

18 миллионы – гади халык, фашистлар яулап алган территорияләрдәге явызлыкларның корбаннары .

Алай гына да түгел, Мәхмүт Гәрәев, замана сәясәтенә яраклашырга тырышып, беркайчан да үз фикереннән баш тартмый. Бөек Ватан сугышында Сталинның роле нинди булган, дигән сорауга да җавабы кискен һәм анык аның: «Моңа хак җавапны тарихны өйрәнеп әйтергә мөмкин. Бөек Ватан сугышы тарихын гына да түгел. 1812 елдагы сугыштан соң, Россия барлык сугышларда да диярлек җиңелеп килә - Кырым сугышы булсынмы ул, Рус-япон сугышымы, Беренче бөтендөнья сугышымы. Минем фикеремчә, моның төп сәбәбе – хакимият башында торучыда, димәк, армия белән күп еллар дәвамында тәҗрибәле, яхшы җитәкчеләр идарә итмәгән, дигән сүз. Сугыш шартларында идарә тиешле дәрәҗәдә дөрес оештырылмаса, бер генә халык та җиңүгә ирешә алмый, алай гына да түгел, хәтта тиешле юнәлеш тә таба алмаска мөмкин...» Гәрәев бер генә мәртәбә дә Сталинны тиран булмаган дип расламый, шуңа да карамастан, әллә никадәр тәнкыйть утына тотыла. Һәм инде үзенең фактлар белән беркетелгән фикереннән дә баш тартмый.

– Бөек Ватан сугышы хакындагы хакыйкатьне әле киләчәктә әллә ничә буын галимнәр һәм язучылар ваемлар, дип уйлыйм. Ә спекуляцияләргә килсәк, яңалары табылып торачак, – ди ул. – Чөнки конъюнктура, әдәп-әхлак кагыйдәләре үзгәреп тора, мәдәният... Чөнки бу сугыш – асылда, кешелек тарихындагы яхшылык белән явызлык көрәшенең иң югары концентрациядәге чагылышы иде...

Ул Бөек Җиңүнең 75 еллыгына аз гына яшәп җитми. Ләкин аның бүгенге көндә бик кирәкле китаплары – югары дәрәҗәдәге төгәл коралы калды. Димәк, сугышчы Мәхмүт Гәрәев әле һаман да безнең сафларда. Ул һаман да көрәшүен дәвам итә.

БЕЛЕШМӘ:
КАЗАН КАЙМАСЫ. СССР Дәүләт оборона комитетының 1941 елның 13 октябрендәге карары нигезендә Казанны немец-фашист гаскәрләре һөҗүменнән саклау өчен төзелгән ныгытмалар системасы. Төзелеш җитәкчеләре – Ф.М. Ковальский, И. М. Ильина, А. П. Баранников һ.б. Оборона чиге Казан тирәсендә ярымбоҗра рәвешендә казыла. Чувашстан һәм Татарстан АССР территорияләре буйлап, Покровское авылыннан (Урмара, Кайбыч, Апас торак пунктлары аша) Куйбышев (ТАССР) шәһәренә кадәр сузыла.
Казан каймасының озынлыгы 331 км була, шул исәптән – 151 км танкка каршы чокыр, 79,61 км эскарплар, 1,96 км контрэскарплар. Шунда ук 392 команда һәм команда-күзәтү пункты, 98 яшерен ут ноктасы, 45 мм лы танкка каршы туплар өчен 44 дзот һәм 76 мм лы пушкалар өчен 12 дзот, 419 землянка төзелә. Мәскәү янында немец-фашист гаскәрләре тар-мар ителгәннән соң (1941–1942 еллар) Казан каймасы консервацияләнә.

ХЕЗМӘТ КОТОЧКЫЧ АВЫР – ТРАНШЕЯЛАРНЫ КУЛДАН КАЗЫЙЛАР

1942 елның 11 февралендә 331 км озынлыктагы «Казан каймасы» оборона ныгытмалары төзелеше тәмамлана.

Илебезнең йөз зур шәһәре тирәсендә оборона ныгытмалары төзү турындагы карар 1941 елның октябрендә кабул ителә, бу фронттагы вазгыять белән аңлатыла, чөнки немецлар ил эченә ыргыла. Татарстан халкын Казан каймасы төзелешенә мобилизацияләү 1941 елның 22 октябрендә ВКП (б) өлкә комитеты эшләрне оештыру турында карар кабул иткәннән соң ук башлана. Оборона корылмалары төзелешенә разнарядка буенча Казан – 83,5 меңнән артык, Нурлат районы – 7,8 мең, Биектау районы ике мең кеше җибәрергә тиеш була…

Нәтиҗәдә 1941 елның 14 декабренә окоп казуда 108 мең кеше мәшгуль була. Хатын-кызлар һәм балалар, картлар, ач, начар киенгән булуларына карамастан, каты салкыннарда лом, кәйлә, көрәкләр белән туң җирне казыйлар.

Бу коточкыч авыр хезмәт була. Өч метр тирәнлектәге траншеяларны кулдан казыйлар, халык ачтан, йончыгу-авырулардан кырыла. Төзелеш барган өч айда күпме кешенең вафат булуын әлегә кадәр беркем дә белми. Ләкин бурыч үтәлә: 1942 елның 11 февралендә Казан каймасын Дәүләт комиссиясе кабул итә.

Николай Курков истәлекләреннән: «Окоп казулар көздән башланды. Аягында басып тора алган бар халыкны окоп казырга җибәрделәр, кечкенә баласы булган хатын-кызлар гына калды. Безнең белән бер батальон солдат эшләде, алар шартлату эшләрен башкарды. Болай туфракны ату җиңелрәк иде, ләкин иртәнге якка җир яңадан ката. Солдатлар шулай ук дотлар (өч катлы бүрәнә өстеннән туфрак салынган землянкалар) төзеделәр. Мин окоп казырга әни урынына бардым. Ашау начар, учак ягып, шунда бәрәңге тәгәрәтә идек. Бик каты салкыннар торды. Өс-баш сәләмә, аякта чабата. Туң җирне Буадан алып килгән кәйләләр белән чокыйбыз. Мин авыруларны, авырлы хатыннарны ат белән күп тапкырлар Буага илттем. Баржаларда китерелгән халык бик юка киенгән иде. Җылы кием юк, алар авырый башлады, кайберләре салкыннан һәм ачтан үлде».

Фото: kremnik.ru

БЕРЛИНГА ТАНКТА БЕРЕНЧЕ БУЛЫП БӘРЕП КЕРГӘН

БЕЛЕШМӘ:
Гарәпша Шаһимәрдан улы Шаһимәрданов. 1905 елда Арча районы Түбән Әҗәк авылында туа. 1927–1929 елларда кавалериядә хезмәт итә. Саба районында тарих укытучысы булып эшли. 1941 елның 5 ноябрендә үз теләге белән фронтка китә. 1943 елның июненнән Казан бронялы танклар югары офицерлар мәктәбе тыңлаучысы. 1944 елның апреленнән – 37 нче механикалаштырылган бригада составында взвод командиры. 1945 елның гыйнварыннан – 1 нче Белоруссия фронтының 219 нчы танк бригадасында рота командиры, капитан. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Берлинны алган өчен» медале белән бүләкләнгән. Җиңүдән соң Саба районында яши һәм эшли, ике кыз һәм өч ул үстерә.

Америкада җыелган «Шерман» танкы Берлинны штурмлауга өч көн кала Густав-Адольф штрасседа пәйда була һәм үзенең чылбыр тәгәрмәче астына эләккән бар нәрсәне – өч дошман тубын һәм иллеләп солдатын юк итә.

Фашистлар өнендәге әлеге көтелмәгән кунак Гарәпша Шаһимәрданов танкы була. «Шерман»нар ротасы командиры капитан Шаһимәрдановның әле яулап алынмаган немец башкаласында күрсәткән бу батырлыгын һәм аннан соңгы кыю гамәлләрен югары бәялиләр. 1945 елның 5 маенда танк бригадасы командиры подполковник Евсей Вайнруб Гарәпшаны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим иткән бүләкләү кәгазен имзалый.

Шаһимәрдановның анда санап кителгән батырлыклары, һичшиксез, бүләккә лаек икәнен раслый. 22 апрельгә каршы төндә «Шерман»да дошманның тыныч йокысын бозган тарихи разведка рейдыннан соң, Гарәпша әле тагын ике тапкыр искиткеч кыюлык күрсәтә. 24 апрельдә, танк батальонына Гогенцоллерн каналы аша кичүне үз кулына алу бурычы куелгач, Шаһимәрданов үз ротасы белән немецларның тылына бәреп керә, 45 танк һәм үзйөрешле тупны кулга төшерә, 60 лап кешене юк итә. Ә бер атнадан соң, 1 майда, Берлинерштрасседагы кичү өчен барган яуда шулай ук сугышчан бурычын уңышлы үти: алдынгы отрядта хәрәкәт итеп, дошманның 4 танкка каршы һәм 2 зенит тубын, 95 ләп солдат һәм офицерын юкка чыгара.

Шаһимәрдановны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итү документларын 1 нче мехкорпус командиры генерал-лейтенант Семён Кривошеин, аннары 2 нче гвардия танк армиясе командующие генерал-полковник Семён Богданов һәм армиянең Хәрби советы әгъзасы генерал-майор Пётр Латышев бер-бер артлы раслый. Ә нәтиҗәдә, 1 нче Белоруссия фронтының бронетанклар һәм механикалаштырылган гаскәрләре командующиеның 1945 елның 30 маендагы боерыгы белән капитан Гарәпша Шаһимәрдановны I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләклиләр.

Ни өчен Герой исемен бирмиләр соң? Бәлки, югарыда кемгәдер Берлин урамнарына беренче булып үзебезнең Т-34 түгел, ә лендлиз буенча алынган «Шерман»ның бәреп керүе ошамагандыр, бәлки, ул чор өчен башка җитди сәбәпләр булгандыр...

Герой үзе ни уйлады икән? Иң мөһиме, аның гомере өзелми. Саба районыннан 1941 елның 5 ноябрендә үз теләге белән фронтка киткән тарих укытучысы туган ягына исән-сау әйләнеп кайта. Уллары әйтүенчә, бер генә нәрсәгә – танк белән туп-туры рейхстагка кадәр барып җитә алмавына гына көенгән ул.

P.S. 2007 елда РФ Оборона министрлыгы дөньяга чыгарган документлар арасында Гарәпша Шаһимәрдановны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итү кәгазе дә була. Берничә елдан соң документның күчермәсен аның туганнарына тапшыралар.

Фото: kremnik.ru

«БЕЗ НЫК ЫШАНАБЫЗ: СЕЗ ДОШМАНГА ТЫН АЛЫРГА БИРМӘССЕЗ, АНЫ КӨНБАТЫШКА ТАБА ТАГЫН ДА ЕРАГРАК КУАРСЫЗ...»

ПИСЬМО ТАТАРСКОГО НАРОДА ФРОНТОВИКАМ-ТАТАРАМ

Фронтовик татарларга татар халкыннан хат

1943 елның 5 мартында «Правда» газетасында Татарстан АССР хезмәт ияләренең барлык фронтовик татарларга язган хаты басылып чыга.

Бу өндәү-хатка академик Александр Арбузов, язучылар Кави Нәҗми һәм Таҗи Гыйззәт, композитор Нәҗип Җиһанов, актриса Гөлсем Болгарская, профессор Гыйлем Камай һәм тагын йөзләрчә мең татарстанлы: танылган галимнәр, мәдәният эшлеклеләре, предприятие җитәкчеләре һәм гади гражданнар – барлыгы миллион ярымнан артык кеше имза куя.

Якташлары сугышчыларны фашист хәшәрәтләрен юк итү, дошманны тулысынча җиңү өчен бөтен көчләрен тупларга өнди. «Ак диңгездән алып Кара диңгезгә кадәр сузылган фронтларда туган илебезнең һәрбер карыш туфрагын җаннан кадерле күреп, күкрәк киереп саклаучы һәм һөҗүмгә күчкән татар егетләре! – диелгән хатта. – Гаскәрләребезнең гүзәл җиңүләре көннәрендә татар халкы сезгә үзенең ялкынлы сәламен җибәрә... Без нык ышанабыз: сез дошманга тын алырга бирмәссез, аны Көнбатышка таба тагын да ераграк куарсыз һәм немец басып алучыларын беткәнче кырырсыз».

Бу 1942 ел ахыры – 1943 ел башында үзәк һәм җирле матбугатта СССР халыклары исеменнән фронтовик ватандашларга җибәрелгән наказ хатларының берсе була (беренчесе – 1942 елның 31 октябрендә «Правда»да басылып чыккан «Үзбәк халкының Бөек Ватан сугышы солдатларына хаты»).

Шунысы мәгълүм: «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хатын» әзерләүне ВКП (б) ның Татарстан өлкә комитеты ТАССР Халык комиссарлары советы каршындагы Тел, әдәбият һәм тарих институтына йөкли. Текст язуны Кави Нәҗми һәм Гази Кашшафка ышанып тапшыралар, аларга фольклорчы Хәмит Ярми ярдәм итә. Ә хатны рус теленә сүзенсүзгә тәрҗемә итү һәм әдәби эшкәртү эшен язучы Константин Федин башкара.

Татарстан АССР хезмәтчәннәренең барлык фронтовик татарларга язган хаты республика газеталарында, фронт газеталарында татар телендә басылып чыга, берничә тапкыр аерым брошюра булып та нәшер ителә. Кайбер тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, соңрак чыккан басмаларда хатның тексты төзәтелгән. Аерым алганда, документның беренче версиясендә татарларның Кырым һәм Кавказ халыклары белән туганлыклары турында искәртү булган, соңыннан ул юкка чыккан; ә хатның тагын да соңрак редакциясеннән татар ханы Шаһгали исемен телгә алуны һәм «элек татар халкы үз мәдәниятен саклап кала алган» дигән гыйбарәне төшереп калдырганнар.

Бөек Ватан сугышы елларында 160 тан артык татар Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

Фото: idel-tat.ru, tatar-inform.ru


Штамп части
Форма № 5/БП
219-й
СЕКРЕТНО
(после заполнения)
Районному (городскому)
военному комиссару Татарск. АССР области (края)
№ 71
Гор.

ИЗВЕЩЕНИЕ

Прошу известить гр. Хайсарову
проживающ. в
о том, что ее (его)
Хайсаров Касим
в бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, погиб „2" мая 1945 г. и похоронен с отданием воинских почестей в гор. Берлин
Командир
Начальник штаба
ЦТ НКО. 2148—44

1945 ЕЛНЫҢ МАЕ. СОҢГЫ ЮГАЛТУЛАР ИСЕМЛЕГЕННӘН – ДҮРТӘҮ

Егерме ике яшьлек автоматчылар командиры Касыйм Хәйсаровның Берлинштрасседа яуда һәлак булуы турындагы хәбәрен 1945 елның 6 маенда тутыралар. Җиңү көнендә туганнары өчен ул әле исән була. Туган ягына үлем хәбәре, ягъни «кара кәгазь» 31 майда гына килеп ирешә...

Касыйм Хәйсаров ТАССРның Чүпрәле районы Иске Чокалы авылында туып үскән егет. Берлинны алганда, Бөек Ватан сугышының соңгы көннәрендә һәлак булган ике йөздән артык сугышчының берсе ул. Аларның фамилияләре рейхстаг диварларында да юк, соңгы югалтулар исемлегендә генә. Ә гәүдәләре – немецлар мәркәзендә, туганнар каберлегендә.

1945 елның 1 маенда һәлак булган танк бригадасы сержанты Касыйм Хәйсаровны, хәрби дәрәҗәсенә туры китереп, Берлинштрассе белән Рихард (хәбәрдә шулай диелгән. – *ред. иск.*) чатында, Шарлоттенбург районында җирлиләр.

Ә менә 2 майда Берлин гарнизоны капитуляциясенә берничә сәгать кала һәлак булган 124 нче миномёт полкы транспорт йөртүчесе, Казан солдаты, өлкән сержант Василий Зубрицкий белән полкташлары Блюнкенфельдштрасседа хушлаша.

Шушы ук көнне, немец башкаласында, үзе өчен соңгы сугышта кызылармияче Николай Костин вафат була. Полк командиры белән штаб башлыгы Зәй районы хәрби комиссариатына хәбәр юллый: «ТАССР, Зәй районы, Иске Тәкмәк авылында яшәүче гражданка Костина Анастасия Клементьевага хәбәр итегез: аның улы, рядовой радист Костин Николай Григорьевич, социалистик ватаныбыз өчен көрәштә, хәрби антына тугры калып, каһарманлык һәм ныклык күрсәтеп, 1945 елның 2 маенда һәлак булды. Хәрби дәрәҗәләр белән Берлин шәһәре, Ликтенберг җирлегендә җирләнде. Коооординаталар: Х=21300 У=96600».

Ә 25 яшьлек гвардия сержанты, авыр танк бригадасының разведрота пулемётчысы, хәзерге Тукай районы Иске Абдул авылы егете Муллагали Йосыповны Берлинның төньяк округында җир куенына иңдерәләр...

Сугышның соңгы көннәрендә һәлак булган бу солдатларның тормыш юллары да, язмышлары да төрле. Бөек Ватан сугышының беренче елларында югалтулар ачысын татыган, 1940 елда ук сугышка алынган Муллагали Йосыпов белән 1942 елда сугышка кергән Касыйм Хәйсаров, әйтик. Кырык өч яшьлек, сугышның барлык михнәтләрен үз башыннан кичергән машина йөртүче Василий Зубрицкий һәм әле сугышуның ни икәнен дә юньләп татырга өлгермәгән 18 яшьлек Николай Костин.

Сугышның соңгы көннәренә караган югалтулар исемлегендәге язмышларның дүртесе генә бу. Яудан әйләнеп кайтмаган 350 мең татарстанлының – дүртесе.

Фотолар: kremnik.ru

БЕЛЕШМӘ:
Бөек Ватан сугышы елларында кылган батырлыклары өчен, 2 671 кеше Дан орденының тулы кавалеры була. Алар хокуклары буенча Советлар Союзы Герое исеме бирелгән затларга тиңләшә.

«ЭЧӘСЕ КИЛӘ, ӘММА КАН КУШЫЛМАГАН ЧИСТА СУ ТАБУЫ КЫЕН...»

«Без Сталинградны дошманга бирмичә, соңгы сулышка кадәр сугышкан һәм фашизм оясы – Берлинны штурмлаган солдатлар» – 1945 елның маенда бер сугышчы рейхстаг диварына штык белән әнә шундый сүзләр чокып язган. Имзасын да куйган: «Малкин П.И., 1918 елгы, Татариядән».

Малкин – кече сержант-артиллерист, ә сугышка кадәр – Тәтештә тыныч тормыш алып барган гади бер хезмәткәр. Илен якларга дип сугышка киткән солдат. Берлин өчен барган аяусыз көрәшләрдә 100 нче гаубица артиллерия бригадасы сугышчысы ике немец миномёт батареясын мәңгегә тынып калырга мәҗбүр итә, каршы торуның өч төенен өзә.

Иң кадерле солдат бүләге – I дәрәҗә Дан ордены. Аны Малкинга нәкъ менә шушы бәрелеш өчен тапшыралар. Бу – аның өченче Дан ордены. Беренчесен – III дәрәҗә Дан орденын – ул Ковельгә якынлашканда, 1944 елның 27 мартында ала. Пехота атакасы туктап калган киеренке бер мизгелдә, рядовой Малкин үзенең коралын алып чыгып, ике дистә дошман солдаты белән офицерларын кырып ташлый, немецларның өч пулемётын юк итә. Безнекеләр, яңа сулыш алып, кабат яуга ыргыла.

Өч айдан соң, 5 июльдән 9 июльгә кадәр, Ковель өчен барган өзлексез көрәштә Пётр Малкин дүрт мәртәбә сугышчан батырлык күрсәтә. Ул бу көннәрдә тар-мар итеп ташлаган пулемётлар белән снайперлар, танкка каршы пушкалар, дзотлар аның II дәрәҗә Дан орденына лаек булуын дәлилли.

Сталинградны саклауда катнашкан, Дан орденының тулы кавалеры булган Пётр Иванович Малкин Тәтешкә демобилизациядән соң ук әйләнеп кайта. Бу 1946 елның гыйнвар ае була. Кайткач, ул фельдъегер булып эшли. Туган шәһәрендә аның исеме белән урам да аталган.

Пётр Малкин истәлекләреннән: «Күз алдына китерегез – расчёт тора. Урман да, йортлар да, землянкалар да – бернәрсә юк. Ә черем итеп алырга кирәк. Өшемәс өчен, мәетләр өстенә ятып йоклый идек. Чиратлап. Беребез уяу, сакта тора, икенчебез бераз ял итеп ала. Яртышар сәгать йокы, ул арада организм бераз көч җыя, тик катып үләргә өлгермисең. Эчәсе килә, әмма кан кушылмаган чиста су табуы кыен. Идел буенда, ярдагы суларда – тоташ кан гына...»

Фотолар: fotoload.ru, tatfrontu.ru

БЕРИЯ ҮЗЕ КУРАТОР БУЛГАН ЛАБОРАТОРИЯ

Американың «Манхэттен» проекты* эшли башлаганнан соң бер ай узгач, ТАССРда атом-төш коралын әзерләүгә керешәләр.

1942 елның 28 сентябрендә СССР Оборона дәүләт комитетының 2352 нче номерлы боерыгы чыга: «Уран җитештерү буенча эшне оештырырга» диелгән анда. Оборона дәүләт комитеты рәисе Иосиф Сталин имзалаган документ бу. «Катгый яшерен» грифы куелган документ. Ул документ буенча түбәндәгеләр каралган: «СССР Фәннәр академиясенә (академик Иоффе) атом энергиясен уран төшен таркатып алуга караган тикшеренү эшләрен яңартырга һәм Оборона дәүләт комитетына 1943 елның 1 апреленә уран бомбасын яки уран ягулыгын җитештерү мөмкинлеге хакында доклад әзерләргә».

Бурычны үтәр өчен кирәкле чаралар билгеләнә. Беренчедән, СССР ФА каршында уранны тикшерү буенча махсус лаборатория оештырырга. Кайдамы? Мондый сорау тумый да, чөнки Фәннәр академиясе ул чакта Казанда эвакуациядә була. Моңа бәйле рәвештә, ОДК күрсәтмәсендә болай дип языла: «Татарстан АССР Халык комиссарлары советына (иптәш Гафиатуллинга) 1942 елның 15 октябреннән Казандагы СССР Фәннәр академиясенә атом-төш лабораториясен урнаштыру өчен 500 квадрат метрлы бина табарга һәм 10 фәнни хезмәткәрне торак белән тәэмин итәргә».

Сталин документы шактый кырыс сроклар куя. 5 октябрьгә Казанга самолёт белән 20 кг уран китерелә, шулай ук 200 кг авырлыктагы лаборатория җиһазлары. Боерык чыкканнан соң, бер айдан да кимрәк вакыт эчендә, ягъни 1942 елның 20 октябренә УССР Фәннәр академиясе «центрифугалау ысулы белән уран-235 бүлеп чыгару» лаборатория җайланмасының техник проектын эшләргә, аны шул ук көнне Казанның «Серп и молот» заводына тапшырырга тиеш була.

Авыр машина төзелеше халык комиссариатына, үз чиратында, 1943 елның 1 гыйнварына Казан предприятиесендә центрифуга җыярга боерык бирелә. Моның өчен, аерым алганда, Финанслар халык комиссариатына 30 грамм стратегик кыйммәтле металл – платина бүлеп бирү бурычы куела.

Сталин карары чыкканнан соң, Казандагы яшерен лаборатория икенче көнне үк эшкә керешә. Ленинград физика-техника институты директоры Абрам Иоффе 11 кешелек Казан төркеме турында боерык имзалый. Беренче совет махсус атом-төш лабораториясен Игорь Курчатов җитәкли.

Эш Казанның үзәгендә үк алып барыла – Карл Маркс урамы, 10 адресы буенча урнашкан КАИ бинасы подвалында. Рәсми рәвештә «2 нче лаборатория» булып йөри. Нигә икенче, дисезме? Проектны турыдан-туры үз кураторлыгында тоткан Лаврентий Берия сүзләреннән соң ябышып кала бу исем: «Лаборатория №1 – ул без, Мәскәү Кремле...»

Коточкыч кырыс срок куелуга карамастан, боерыкның үтәлүенә һичбер шик тә булмый. Эш хәрби вакыт законнарында гына да түгел. Сталин документы разведка җиткергән мәгълүматларга нигезләнә. Ә алар менә нәрсә ди: АКШ атом-төш коралын җитештерүдә сизелерлек ыргылыш ясады. Атом-төш коралы җитештерүдә алардан артта калу илнең үлем турындагы кәгазенә кул куюга тиң.

P.S. 2 нче лаборатория Игорь Курчатов җитәкчелегендә Казанда берничә ай буена эшли. 1943 елдан ул инде Мәскәүгә күчә. 1949 елда, ягъни алты ел узгач, Семипалатинск полигонында беренче совет атом-төш коралын сынап карыйлар. АКШның дөньяда өстенлек итү турындагы планнары юк ителә. Ә проектның 1942 елның сентябрендә Карл Маркс урамындагы подвалда башланганын онытмыйк...

Фото: russianlook.com

* *АКШның атом-төш коралы программасының яшерен атамасы.*

«ТЕРЕЛӘСЕҢ, ТУГАН ЯГЫҢА КАЙТАСЫҢ, МЕНӘ КҮР ДӘ ТОР!»

Луиза Янсуар

Ул үзен гадәти язмышлы кеше дип саный. Әмма бу гадәти генә язмыш түгел. Кечкенә генә буйлы, җыйнак-какча гәүдәле карчык иде ул без танышканда. Сабыр да, тыйнак та, балаларча кызыксынучан, тере, шаян да. Аны пулялар сызгырып очкан яу кырында, лагерь диварлары эчендә, тоткыннар арасында күз алдына китерү кыен иде. Ачык тәрәзәдән карап торган бөреләргә ишарәләп: «Яшәү нинди ямьле...» – дип әллә ничә кабатлады без сөйләшеп утырганда.

СНАРЯДЛАР ЯНӘШӘДӘ ШАРТЛАГАНДА...

– 1942 елның 3 маенда без, иңнәребезгә биштәр асып, пароходка утырып, Уфага киттек. Анда безне башта беренче чакыру буенча җибәрелгән кызлар белән бергә тоттылар, карантин тикшеренүе узганнан соң, кабат пароходка төяп, Горький шәһәренә радистлар курсына озаттылар.

1942 елның май азагында Горький шәһәренең (хәзерге Түбән Новгород. – *Ред. иск.*) Канавино районында радистлар курсында укый башлый Валентина Макова. Уку октябрь аена кадәр дәвам итә. Курсларда армия тәртибе хөкем сөрә иде, дип искә ала:

– Иртәнге алтыда торып басабыз, иртәнге ашны ашыйбыз да укырга керешәбез. Аннан, төшке ашны ашагач, тагын укыйбыз. Кичке аштан соң, 23 сәгатьтә, отбой бирәләр, егылып йоклыйсың. Үзебез өчен буш вакыт калмый да иде диярлек. Безне тиз арада фронтка җибәрер өчен әзерләделәр. Махсус предметтан тыш, стройга тезелергә дә өйрәттеләр, кичләрен рота белән йөрергә дә чыгаралар иде.

Кызларның бөтен вакыты диярлек Морзе әлифбасына нигезләнеп ачкыч белән эшләүгә багышлана.

1942 елның 18 октябрендә укулар тәмамлана. Валентина Макова Көньяк-Көнбатыш фронтка җибәрелә. Алар фронтларга билгеләнгәндә, 278 нче укчы дивизия Сталинград тирәсендә сугыша. 1942 елның 11 декабрендә бирегә җибәрелгән кызлар полкның элемтә ротасына килеп җитә.

– Мине икенче номер (коточкыч авыр аккумуляторларны күтәреп йөрүче ират. – *Ред. иск.*) белән бергә укчы батальонга җибәрделәр – рация буенча элемтә урнаштырырга кирәк иде. Әмма озак та үтмәде, дошман кайда икәнлегебезне ачыклады. Андый шартларда эшне дәвам итеп булмый иде. Дошман артиллериясенең элемтәне «тотып» алуын абайламый кала

Фотолар Валентина Макова, Аркадий һәм Михаил Хлебниковлар архивыннан.

алмыйсың: снарядлар янәшәндә үк шартлый башлый...

Радистларны полк командирының команда һәм күзәтү пунктына телефончылар итеп күчерделәр. Берәмләп дежур тордык, мөмкинлек булганда, икенчебез бераз черем итеп ала иде. Декабрь азагында өстебезгә танклар килә башлады, бу минем ут аша узган тәүге зур чыныгуым булды. Ротада авыр җәрәхәт алучылар күбәйде, үлем очраклары да үзен көттермәде.

1943 елның гыйнвар башында аларның полкын Сталинградтан төньяккарак җибәрәләр. Дошман өстенә бару инде Харьков юнәлешендә дәвам итә.

«ҖИР БЕЛӘН КҮК ӘЙЛӘНЕП КАПЛАНДЫ...»

– Сугышка кергәнче үк безне яхшылап кисәттеләр: командирлар белән дә, рядовойлар белән дә үзеңне тәртипле тот, монда – яу кыры, танцы-фәлән түгел, – дип сөйли Валентина Макова. – Өс-башны да чиста-пөхтә тотарга кирәк иде, чәчне-башны туздырып йөрмәскә. Хәрбиләрнең берсе белән дә (алар бәйләнгән, игътибар күрсәткән очракларда) якын мөнәсәбәтләргә кермәскә.

– Ә бәйләнә иделәрме? – дип төпченәм.

– Ул күбрәк үзеңне ничек тотуыңа бәйле булгандыр, – ди Валентина Петровна тыйнак кына. – Кызлар арасында төрлесе булды, билгеле. Чытлыграклар да бар иде... Әмма кисәтү кырыс. Мин үзем ул кисәтүне шунда ук хәтеремә киртләп куйдым.

1943 елның 8 мартында Валентина Макованы укчы батальонга билгелиләр, ул анда радиоэлемтә өчен җавап бирә. Ике атнага сузылган сугышлар вакытында хәтерендә нәрсә калганын болай сөйли:

– Япан кыр, пуляләр, шөпшәләр кебек, яннан сызгырып оча. Юынырга да, өс-башыңны карарга да мөмкинлек юк диярлек. Хәтта ашавын да төннәрен генә ашыйбыз. Элемтә булдырудан тыш, яралыларга беренче медицина ярдәме күрсәтү белән дә шөгыльләндек. Дошман тоташтан утка тота, хәл алырга бирми...

Ә 1943 елның 22 июль иртәсе аның өчен көтелмәгән хәтәр алып килә.

– Миңа 20 яшь, инде шактый тәҗрибәле сугышчы исәпләнәм. Ул иртәдә тиз генә капкалап алдык та, мин, тын торган арада, янәшәдә агып яткан сулыкка кашык юарга төштем. Шулчак, көтмәгәндә-абайламаганда, һавада әллә каян гына «мессершмит» пәйда булды. Дошман самолёты түбәннән кистереп очкан хәлдә миңа таба пулемёттан бер-бер артлы ядрә яудырырга керешә...

Эчемә нәрсәдер китереп бәргәнен тойдым да, аякларым буйлап җып-җылы нидер агуын абайладым. Җир белән күк әйләнеп капланды. Ә асылда ул мин әйләнеп капланганмын икән... Күзәтү пунктында моны күреп алганнар. Үзем нәрсә булганын аңлар хәлдә түгел идем: эчемне актарып ташлаган да, эчәкләрем җиргә салынып төшкән. Рота старшинасы Григорий Калашник мине кичекмәстән эвакуацияләүләрен оештырган. Грабаркага төяп, медсанбатка озатканнар...

«ӘНИЕМ БЕЛӘН ӘТИЕМНЕ КҮРӘ АЛСАМ ЯРАР ИДЕ...»

Медсанбат полктан 9 километр ераклыкта урнашкан була. Күпне күргән табиблар да эчәкләре әйләнеп чыккан кызның исән калырына ышанмый.

– Операция өстәлендә хирургның командасын ишетеп аңыма килдем, – дип сөйли Валентина Петровна. – Баштарак аңлый алмый тордым: кайда мин? «Бер-ике-өч... сана!» – дип боерды табиб. 21 гә кадәр санадым да кабат аңымны җуйдым.

Аңына өч көн узгач кына килә ул. Кызны кыр госпиталенә озаталар. Терапевт болай ди: «Ходайга рәхмәтләреңне укы, кызым, мондый җәрәхәт алган кешеләр, гадәттә, исән калмый».

Яралыларны Уфада оешкан эвакогоспиталь кабул итә. Валентина Маковины хирург бик җентекләп карый.

– Ә мин бары бер генә җөмлә сытып чыгара алдым, – ди Валентина Петровна. – Исән калып, әнием белән әтиемне күрә алсам ярар иде...

Яралары һәм операция җөе госпитальгә китергәндә тоташ үлек кенә була. Ике атнадан соң аны санитар самолётта Воронеж өлкәсендәге Россошь шәһәренә җибәрәләр.

Валентина Петровна тагын бер эпизодны искә ала:

– Шундый авыр шартларда да кешеләр искиткеч кешелекле иде, – ди ул. – Алай гына да түгел, әдәпле, итагатьле. Әйтерсең, тирә-

Өч бертуган Макова: Нина, Валя, Оля. 1934 ел.



Ангарлагерьга керү өчен бирелә торган пропуск.

юньдә бомбалар шартламый, ә без исә – балга биергә килгән туташлар белән әфәнделәр... Эвакогоспитальдәге олы яшьтәге хирург миңа «минем барышням» дип мөрәҗәгать итә иде. «Тереләсең, әлбәттә, туган ягыңа кайтасың, менә күр дә тор!» – әнә шул сүзләрен һич оныта алмыйм...

«СИН МИҢА КАПРИЗЛАР КҮРСӘТЕП ТОР ТАГЫН!..»

Россошьтагы госпитальгә илткәндә санитарларның үзара сөйләшүләрен ишетә: профильле урынга туры килмәде, нәрсә булып бетәр инде моның белән, диләр.

Баштарак сүзнең нәрсә турында барганын абайламый. Хатын-кызлар бүлегенә эләгә ул. Аннан кала, тагын 2-3 хатын була, аларның сыкрану-сызланулары һаман колак төбендә тора, ди Валентина Петровна. Нинди яра белән ятулары турында сорый – берсенеке – аборт, икенчесенеке – ялкынсыну...

Кичке ашка кара ипи белән борчак боткасы китерәләр.

– Миңа моны ашарга ярамый, – ди Валентина Петровна.

– Нәрсә бирсәләр, шуны аша! Әнә, солдатлар үлек эчендә ята, син монда капризларыңны күрсәтеп тор тагын миңа! – дип җикеренә санитарка, аны кемнеңдер походтагы «хатыны» дип уйлап.

– Мин дә бит – үлек эчендә, минем бәйләвечләремне алыштырырга кирәк, – дип пышылдый Валентина.

Шуннан соң санитарка дежур табибны чакырта. Диетик ашау билгелиләр дә, поездга утыртып, тылга – Камышин шәһәренә озаталар. Монда ул ике атна тора. Әмма яралары җитдирәк дәвалау таләп иткәнгә, Саратовка җибәрәләр. Монда Валентина Макова өч ай ята.

КҮКЛӘРНЕҢ МОГҖИЗАСЫ

1943 елның 14 декабрендә Валентина Маковага коры паек, тиешле документларны хәстәрләп тоттыралар да, инвалид буларак, кайтарып җибәрәләр. 19 декабрьдә ул Камбарка станциясенә килеп җитә. Станциядә пассажирлар өчен кунарга ачык һавадагы бер лавка каралган була. Валентина транспорт табарга тырышып карый, әмма барып чыкмый. Кич җитә, чатнама суык. Камбаркадан аның авылына кадәр юл – трасса буйлап 19 километр, ә Чулман аша турыдан – 15 километр.

Шинельдән булгач, җәяү дә кайтып җитәрмен, дип тәвәккәлли кыз. Әмма яралары үзенекен итә – тиз арада хәлдән тая. Шул чакта – ни могҗиза! – җигелгән атлы берәү килеп туктый. Җитмәсә, чанасында урын да буш! Березовкага бара булып чыга. Толыпка төренеп утыргач, инде юлда барганда, Валентина Макова бу ир-атның апасы Нинаның ире булуын ачыклый. Шулай итеп, кадер-хәстәрдә өенә – туганнары кочагына кайтып җитә.

Җизнәсе Виктор Васильковның юлына очравын Валентина Петровна әле хәзер дә Күкләрнең ярдәме, могҗизасы дип саный...

КИЯҮГӘ – ЛАГЕРЬГА...

1944 елда Валентина Макова Казан дәүләт медицина институтына укырга керә. Бер-бер артлы апасы Нина һәм энисе үлеп китәләр. Дәүләт имтиханнарын тапшыргач, Валентинаны, дипломлы белгеч буларак, Башкорт-станга билгелиләр. Березовкада этисе белән апасының 4 яшьлек кызы Вера берүзләре калган була. Шуңа күрә Березовкада

Дәвалау факультеты, 1 нче курс. 1945 ел.

Себер, Лена елгасы. 1954 ел.

эшләргә рөхсәт алып, 1949 елның сентябреннән сан-эпидстанциядә эпидемиолог булып эшли башлый. Әтисен, кечкенә Верочканы тәрбияли. Валентинаны үзенең насыйбы 1950 елның июлендә эзләп таба. Ул мәктәп елларыннан ук таныш авылдашы Аркадий Хлебников булып чыга.

– Мин мәктәптә укыганда Аркаша район газетасы редакциясендә эшләде, ә мин мәктәп газетасы өчен җаваплы идем, – дип сөйләде Валентина Петровна. – Аркаша бик яхшы, игътибарлы ир һәм эти булды. Тормышка карашларыбыз да туры килде, бер-беребезне бер караштан, ярты сүздән аңлап яшәдек, шөкер...

Кияүгә чыккач, туй сәяхәтенә чыгып китәләр алар. Мәскәүдә, Казанда, Киевта, Миргородта булып кайталар. Аннары, 1956 елда, Аркадий Хлебниковны МВД гаскәрләре буенча Ангарлагерьга лагерь пункты начальнигы итеп билгелиләр. Шулай итеп, Валентина Макова, инде Хлебникова фамилиясен алып, ире артыннан Себергә китеп бара...

«ҮЗЕГЕЗНЕ ГУМАНЛЫ ТОТЫГЫЗ»

Лагерьда, – Лена ярларында яшәгән елларын үтә бер җылылык һәм саклык белән искә ала ул. Биредә 1951 елның 28 апрелендә уллары Михаил дөньяга килә. 1954 елның 11 октябрендә кызлары Наташа туа.

– Матди яктан без бик яхшы яшәдек, хезмәт хакына өстәп, Себер өстәмә акчасы да ала идек, – ди. – МВД системасында озак еллар эшләгән өчен дә түләделәр.

Төрле хуҗаларда фатирларда яшиләр. Алты ел эчендә тугыз урын алыштыралар.

– Соңгы өч елда дүрт хуҗага бүленгән йортта тордык, – дип искә ала Валентина Петровна. – Аңа кадәр – бик яхшы фатирда: ике зур гына бүлмәсе, кухнясы, иркен балконы бар иде. 1952 елның гыйнварыннан мин лазаретта терапевт вазыйфасын башкарырга керештем. Лазаретта 400-500 ләп кеше була торган иде. Берара хатын-кызлар лазареты да эшләде. Махсус бүлек тә бар иде – анысында аеруча куркыныч тоткыннарны, нигездә, җинаятьчеләрне, тоталар. Тәрәзәләрендә һәм ишекләрендә – тимер рәшәткәләр. Табибны обход вакытларында һәрчак надзиратель озатып йөри. «Зона»га без коралсыз керә идек, әмма һәрвакыт сак белән. Табибларны эшкә алганда, баштан ук кисәтеп куйдылар: үзегезне гуманлы тотыгыз, тоткыннарга беркайчан да арестантлар икәнлеген искә төшермәгез, рәнҗетмәгез...

КАЗАНГА – ТЫНЫЧ ТОРМЫШКА...

Күп тә үтми, армиядә һәм МВД сафларында кыскартулар башлана. Аркадий Хлебниковны армиядән капитан дәрәҗәсендә кыскарталар.

– Себердә яшәгән алты ел эчендә без бары тик бер генә тапкыр отпускта булдык, – дип искә ала Валентина Петровна. – 1953 елда Березовкага кайтып килдек, Казанда Аркашаның туганынына хәл белергә сугылдык. Аркаша Казандагы финанс-икътисад институтының читтән торып уку бүлегенә керде. 1956 елның августында Казанга кайттык. 11 нче номерлы хастаханәнең 8 нче амбулаториясенә участок терапевты булып эшкә урнаштым. Аркаша, кайту белән, озак вакыт эшсез җәфа чикте. 1958 елда, ниһаять, Куйбышев исемендәге химзаводка үз белгечлеге буенча эшкә урнашты.

«ОРКЕСТР УЙНЫЙ, БӨТЕН ҖИРДӘ ҖЫР ЯҢГЫРЫЙ, ХАЛЫК БИИ...»

1945 елның 9 мае. Казан, Бауман урамы. Елмаюлы йөзләр, шатлыклы күз яшьләре, музыка... Җиңү!

Бауман урамында алма төшәр урын да юк. Бөтенләй таныш булмаган кешеләр кочаклаша, бер-берсен котлый. Шунда ук уртак шатлык уртасында кемдер үксеп елый. «УНИОН» кинотеатрында тынлы оркестр уйный, музыка, ачык ишекләрдән ургып, урамга тарала, парлар вальс әйләнә: бөтенесенә дә кавалерлар җитеп бетмәгәнгә, хатын-кызлар бер-берсе белән бии.

Бераз арырак, Качалов театры янында, Сталин һәм Ленин портретлары астында, берәү гармун тарта. Түгәрәк уртасында, бәхетеннән балкып, яшь хатын бии. Ә баш өстендә кәгазь самолётлар, тирбәлә-тирбәлә, җиргә төшә. Аларда – җиңү турында Совинформбюро сводкасы, соңгы яңалыклар. Кәгазь самолётларны Матбугат йорты тәрәзәләреннән очыралар....

Казанда яшәүче Нәзирә Бикмөхәммәтова (1945 елда аңа 16 яшь була) Җиңү көнен шулай хәтерендә калдырган. Ә иң якты, дулкынландыргыч вакыйга Казан урамнары шатлыктан

Фото: pastvu.com, kazanreporter.ru, online-news.ru

гөрли башлаганчы була. Төнге сәгать икедә диктор Левитан бөтен илгә Германиянең капитуляциясе турында хәбәр итә, хәрбиләр табель коралыннан һавага ата башлый.

ТАССР дәүләт музее директоры Владимир Дьяконов үзенең көндәлегенә болай дип язып куя: «Менә көтеп алынган көн килеп җитте. Төнлә радио аша (радионы инде берничә тәүлек сүндермибез) җиңү турында хөкүмәт хәбәрен тапшырдылар. Бөтен шәһәр шунда ук урамга сибелде. Ирек мәйданында – халык дәрья кук. Мондый сәгатьләрдә өеңдә утыру мөмкин түгел! Оркестр уйный, бөтен җирдә җыр яңгырый, халык бии. Фронтовикларны, күтәреп, һавага чөяләр, хатыннар аларны үбә...»

Дьяконов эшкә иртәнге 9 га барып җитә. Музейга керү урынында плакат элеп куялар: «Җиңү белән, иптәшләр!» «Бүген эшлибезме?» – дип сорый хезмәткәрләр. «Әлбәттә, юк!» – ди ул.

Бомбардировщиклар җыела торган авиация заводында 9 майда эшне иртәнге дүрттә үк туктаталар: митинг! 13 мең кеше, ялкынлы сүзләр һәм үзеңне җилкәдән тау төшкәндәй хис итү: ниһаять!

Күрше 16 нчы моторлар төзү заводында да – митинг, анда да бөек Сталин исәнлегенә сүзләр яңгырый. Биредә 10 меңнән артык кеше җыела. Ә кичен Соцгородта – «Крылья Советов» стадионындагы митингка инде 15 мең кеше килә: Җиңүне көтеп җиткерә алмаганнарны искә алалар, какшамас Кызыл Армиягә, тыл хезмәтчәннәренә рәхмәт сүзләрен яңгыраталар, Сталинга хат юлларга да карар кылалар....

Уртак шатлык, күтәренкелек рухы төн уртасына кадәр дәвам итә. «По-2» очкычы, шәһәр үзәге өстеннән берничә мәртәбә әйләнеп: «Җиңү белән, иптәшләр!» дип язылган листовкалар ташлый. Ирек мәйданы һәм Бауман урамы буйлап, балаларны шатландырып, Казанга гастрольгә килгән Дуров циркы артистлары уза. Соңрак, әле шактый вакыт, Дуров үзе - фил өстенә, ә аның ярдәмчеләре дөя өстенә утырган иде, дип сөйләячәкләр, гәрчә моңа рәсми дәлилләр сакланмаса да.

Кичке тугызда бәйрәм бераз вакытка тынып тора. Барысы да, тавыш көчәйткеч тәлинкәләр янына җыелып, Сталин сөйләгәнне тыңлый. Аннары Мәскәүдә бөек Кызыл Армия хөрмәтенә салют аталар, ә казанлылар туры трансляцияне тыңлый һәм, мәскәүлеләргә кушылып, һәр залп тавышыннан соң «ура» кычкыра.

Аннан соң туганнар, коммуналка, ишегалды күршеләре, барысы бергә җыелып, һәлак булганнарны искә ала.

Икенче көнне ВКП (б) ның Ленин райкомы секретаре Н. Козлов шәһәр комитеты секретарена болай дип хәбәр итә: «9 майда тәүлек әйләнәсе районда берниндн көтелмәгән хәлләр һәм тәртип бозулар булмады. Алкогольдән хәлсезләнгәннәрнең барысына да милиция һәм җәлеп ителгән партия-хуҗалык активы көче белән ярдәм күрсәтелде, кайберләрен өйләренә кадәр кайтарып куйдылар. Милиция органнарыннан алынган мәгълүмат буенча, контрреволюцион чыгышлар, диверсия, ут төртү һәм талау очраклары теркәлмәде. Районда ут һәм су белән тәэмин итүдә өзеклекләр булмады. 10 майда, заводлардан хәбәр ителгәнчә, эшчеләр һәм хезмәткәрләр барысы да предприятиеләргә эшкә чыкты».

Бауман урамында Җиңү көне. И. Попков һәм Ю. Ананьев фотосы

БЕЛЕШМӘ:
Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов). Татар совет шагыйре, хәрби корреспондент. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты (вафатыннан соң). Армиягә 1941 елның июнендә чакырыла. Өлкән политрук буларак, Ленинград һәм Волхов фронтларында көрәшә, «Отвага» газетасының хәбәрчесе була. 1942 елның 26 июнендә Мясной Бор авылы янында бәрелештә каты яралана һәм әсирлеккә төшә. Немецлар төзегән «Идел–Урал» легионында яшерен оешма эшендә катнаша. Яшерен оешма әгъзалары легионерларның Кызыл Армия һәм партизаннар ягына чыгуын, хәрби әсирләрнең восстаниесен оештыра. 1943 елның августында, әлеге хәл булырга тиешле датага берничә көн кала, Җәлил һәм аның көрәштәшләре гестапо тарафыннан кулга алына. 1944 елның 25 августында Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә гильотинада җәзалап үтерелә. Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме (вафатыннан соң) 1956 елның февралендә бирелә. 1957 елда шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» циклы Ленин премиясенә лаек була (вафатыннан соң). Җәлил исеме кече планетага бирелә,Татарстандагы бистә, илдәге күп кенә шәһәрләрнең урамнары һәм проспектлары аның исеме белән атала. Татарстанда иң яхшы яшь авторларга Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе тапшырыла.

1950 нче еллар башы. Хәрби әсир Муса Җәлил күптән исән түгел. Шагыйрьне һәм аның «Идел–Урал» легионына кергән яшерен оешмадагы иптәшләрен немецлар 1944 елның августында ук Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә җәзалап үтерә. Ләкин 1946 елда ук СССР ДКМ тарафыннан Муса Җәлил исеменә ачылган эзләү эшен беркем дә архивка озатырга җыенмый. Кемнәрнеңдер ялган күрсәтмәләренә нигезләнеп ясалган нәтиҗәләр буенча ул исән һәм яшеренеп ята. Кайдадыр Көнбатышта, бәлки, безнең илдәдер дә. Җәлилне Ватанга сатлыкҗанлыкта һәм дошманнарга эшләүдә гаеплиләр.

ПЛЁТЦЕНЗЕЕ ТӨРМӘСЕНДӘ ҖӘЗАЛАНГАН ШАГЫЙРЬ

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

ШИКЛӘР ЙОМГАГЫНДА

Вафат булган шагыйрьгә әлеге ялган шикләр авырлык китерә алмый. Ләкин туганнары – Әминә ханым һәм Чулпан «хыянәтче»нең хатыны һәм кызы исәпләнә, аларга бик кыенга туры килә. Шагыйрьнең башкаладагы Столешников тыкрыгындагы фатирына тәүлек әйләнәсе күзәтү оештырыла, хатынын Лубянкага даими чакырып торалар. Җентекләп сөйләвен таләп итәләр: кем килгән, нәрсә турында сөйләшкәннәр. Фашист тоткынлыгында, гаять авыр шартларда язылган шигырьләре әрәм: аларны бастырырга рөхсәт бирмиләр.

Шунысы да кызык: бу вакытка әсирләрнең тоткынлыкта килеш яшерен оешма төзүләре, үлем көткәндә дә баш имәүләре турында күп нәрсә инде мәгълүм була. Элеккеге хәрби әсир Нигъмәт Терегулов ТАССР Язучылар берлегенә Җәлилнең әсирлектә язылган дистәләрчә шигыре теркәлгән блокнотны китереп биргән. Шагыйрьнең камерадашы, Каршылык хәрәкәтендә катнашкан бельгияле Андре Тиммерманс та шагыйрьнең соңгы үтенечен инде үтәгән – Брюссельдәге совет илчелегенә Моабит төрмәсеннән алып чыккан шигырьләр дәфтәрен тапшырган.

Ә ЦЕНЗУРА КАРШЫ...

Шагыйрьнең шигырьләре, аларның самимилеге һәм сафлыгы – аның гаепсез булуына, какшамас рухына иң шәп дәлил кебек. Моның шулай булуына 1948–1949 еллар тирәсендә Моабит дәфтәре белән беренче мәртәбә танышкан Константин Симонов ихлас ышана – әлеге шигырьләрне аңа бер татар язучысы күрсәткән, дип сөйлиләр. Имеш-мимешләргә, уйдырмаларга игътибар итмичә, ул шигырьләрне «Новый мир» журналында бастырырга карар кыла. Лев Френкель сүзгә-сүз тәрҗемәсен ясый, Симонов кыска гына кереш сүз яза, шигырьләрне җыялар, тик цензура үткәрми. Симонов Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгына мөрәҗәгать итә, әмма рөхсәтне барыбер ала алмый...

Кискен борылыш 1952 елда була. Июльдә Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы Татарстан комитетының дүртенче бүлеге башлыгы подполковник Качалов партия өлкә комитеты үтенече буенча «М. М. Җәлиловның үлеме фактын төгәлләштерү» максатында Мәскәүгә мөрәҗәгать итә. Якынча бер айдан соң СССР ДКМның Дүртенче бүлегеннән җавап алына. «Эзләнүченең 1944 елда вафат булуы сәбәпле, аңа карата ачылган оператив эзләү эше ябыла», дип хәбәр ителә анда.

ҖӘЛИЛ ҖЫРЛАРЫ ЭЗЕННӘН...

1953 елның апрелендә, Сталинның үлеменнән соң, инде «Литературная газета»ның баш мөхәррире Константин Симонов тагын бер мәртәбә Җәлил шигырьләрен бастырып чыгарырга омтылыш ясый. Бу юлы инде главлит (ягъни цензура), тиешле органнар белән киңәшләшкәннән соң, хәбәр итә: каршы килмибез...

Соңрак «Литературка»да Җәлил шигырьләре һәм илгә аның батырлыгы турында сөйләүче мәкаләләр тагын бер тапкыр дөнья күрәчәк. 1956 елның 3 мартында басма Юрий Корольковның «Җәлил җырлары эзләре буйлап» дигән мәкаләсен бирә. Берничә айдан соң, 1956 елның сентябре башында, Константин Симонов үзе Бельгиядәге Кнокке дип аталган курорт шәһәрендә оештырылган Халыкара поэзия фестивалендә трибунадан Муса Җәлилнең тол калган хатынының хатын укуы турында сөйли. Анда «күренекле татар шагыйренең төрмәдә язган шигырьләренең кульъязмаларын коткарып кала алган, Муса Җәлил белән бергә фашистлар төрмәсендә тоткынлыкта булган Бельгия патриоты Андре Тиммермансның күркәм гамәле турында» язылган була. «Камерадагы күрше» дип аталган мәкаләдә Константин Симонов әңгәмәнең әдәби чигенешләрсез һәм төзәтмәләрсез бирелгән стенограммасы белән таныштыра. Әңгәмәдәш – Андре Тиммерманс – Муса Җәлилнең соңгы көннәренең шаһиты, шагыйрь турында бәяләп бетергесез мәгълүмат бирә алган кеше, язучы аны Бельгиядә эзләп таба.

...Советлар Союзы Герое исеме Муса Мостафа улы Җәлиловка (Муса Җәлилгә) 1956 елның февралендә (вафатыннан соң) бирелә. Немец-фашист басып алучылары белән көрәштә күрсәткән гаять зур батырлыгы һәм ныклыгы өчен.

БЕЛЕШМӘ:
Харис Габдрахман улы Якупов, рәссам. 1919 елның 23 декабрендә Казанда туган. Өченче дәрәҗә Сталин премиясе (1951), РСФСР-ның И. Репин исемендәге Дәүләт премиясе (1976), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1958) лауреаты. 1951–1975 елларда – ТАССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе. Тарихи, шулай ук портрет, пейзаж һәм башка жанрларда эшләнгән картиналар авторы («Хөкем алдыннан», «Татарстан АССР төзелү турындагы декретны имзалау» (Лотфулла Фәттахов белән берлектә), «Көчле кешеләр», «Пролог», «Чаллы гүзәлләре» һ.б.). Рәссамның әсәрләре Мәскәүдә Третьяков галереясында, Шәрык халыклары сәнгате музеенда, Дәүләт тарихи музеенда, Пхеньянның Сынлы сәнгать музеенда һ.б. саклана. Казанның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясында рәссамның даими экспозициясе эшли.

ХАРИС ЯКУПОВ: «ВАКЫТ КҮП ЯРАЛАРНЫ ТӨЗӘТӘ, ӘММА СУГЫШ КАЛДЫРГАННАРЫ БИК ТИРӘН ҖӨЙ КАЛДЫРДЫ...»

Әхмәт Шакиров

Солдат сугыштан алып кайткан трофейның бәһасе юк: сугыш тынып торган арада окопларда һәм землянкаларда ясалган 250 рәсем турында бара сүз...

Рядовой Харис Якупов фронттагы беренче рәсемен 1941 елда – беренче алыштан соң биш ай узгач ясый. Елец шәһәрен немецлардан азат итә башлагач, кыска гына вакытка тын алырга бушаган арада кулына карандашын ала. Аңа кадәр каләм-кәгазь кайгысы булмый әле: чигенү, бомбага тотулар, каты алышлар... Пехота, балчык-җиргә күмелеп, кан эчендә булса да, җиңәчәкләренә тәмам ышанган немецларны тоткарларга тырыша...

Беренче җиңү канатлар куя, сугышчылар шатлыкка күмелә. Тынлык дәвам иткән арада Якупов, Казан сәнгать училищесының элекке студенты, күргәннәрен кәгазьгә төшереп калырга ашыга: азат ителгән шәһәрне, сугышның кызган вакытындагы солдатларны, безнең батареяларның ут ачуын, дошманның җимерелгән техникасын... Тагын әсирлеккә төшкән немецларны, аларның кызганыч, мескен кыяфәтен – әле бер ай элек кенә оятсыз рәвештә безнең позицияләргә үрмәләгән дошманнар димәссең дә.

Аның фронтта язылган беренче портретларында – нәкъ менә әсирләр. Һәм кыска гына язулар: «Әсир ефрейтор», «Әсир немецлар»... Еллар узгач, рәссам болай ди: башта полкташларымны сурәтләргә ояла идем, көләрләр дип курыктым. Әмма тегеләре аның чын рәссам икәнен шунда ук күреп ала. Озакламый ул үзенең иптәшләрен – кызылармиячеләрне дә кәгазьгә төшерә башлый. «Снайпер» (1941), «Дустым старшина Коппа» (1942) әнә шулай туа... Якуповның поход галереясында сакланып калган рәсемнәре арасында портретлар алай ук күп түгел. Хикмәт шунда: рәссам аларны сугышчыларның үзләренә бүләк итә торган була, ә тегеләре аларны хат белән өйләренә сала. Сугыш кырыс: кайбер гаиләләрдә Якупов ясаган рәсемнәр сугышта һәлак булган әти, ул, ир кешенең бердәнбер сурәте буларак сакланып кала...

Фото tatar-inform, rinfom.ru сайтларыннан алынды

Бер тапкыр кулына карандаш алгач, Харис Якупов Җиңүгә кадәр сугышның графикадагы хроникасын алып барудан туктамый. Шул ук вакытта солдат-рәссам күргәннәрен сурәткә төшереп кенә калмый, ә моны мөмкин кадәр төгәллек белән башкарырга тырыша, янына өстәмә язулар да теркәп бара. Фронтта ясалган рәсемнәрнең читләрендә кирәкле мәгълүматлар да бар: кайда ясалуы, торак пунктның исеме, кыска гына аңлатма язуы, хәтта командованиенең боерыклары, искән җилнең юнәлешенә кадәр...

Шулай итеп, фронтовик рәссамның эшләре гадәти рәсемнәрдән сугышның документаль шаһитларына әйләнә. Аларның соңгысында – Чехиянең башкаласы һәм автор кулы белән язылган язу: «Безнең гаскәрләр Прагага керә. 1945». Харис Якупов Җиңүне шунда каршы ала.

...2005 елда Харис Якупов, картиналары Третьяковкада һәм башка бик күп галереяларда урын алган автор, үзенең сугыш чоры рәсемнәре куелган күргәзмәне ачканда, болай ди: «Минем өчен, рәссам буларак, сугышта күргәннәрем бөек академия булды. Мин сугыш темасына багышланган шәхси күргәзмәмне оештыру теләге белән яшәдем. Бөек Ватан сугышы ерак үткәндә калды. Аның турында күп нәрсә онытыла, хәтердән җуела. Әмма ул елларның каты бәрелешләре онытылмый. Безнең алгы сызыктагы көрәш траншеялар, окоплар, мина кырлары буйлап кына үтмәде, ул безнең йөрәкләр аша да узды. Вакыт күп яраларны төзәтә, әмма сугыш калдырган җәрәхәтләр бик тирән җөй калдырды. Сугыш – безнең белән, ул һаман да төшләремә керә. Куркыныч булып, котны алып...»



БЕЛЕШМӘ:
Виктор Антонович Тёмин, фотожурналист. Тәүге фотосын Минзәләдә мәктәптә укыганда төшерә. «Известия ТатЦИК», «Красная Татария» газеталарында, соңрак «Правда»да фотохәбәрче булып эшли. Төньяк полюска беренче экспедициягә, челюскинчыларны коткаруны фотога төшерә, Арктикага берничә экспедициядә катнаша. Халхин-Голда, Хәсән күле буендагы бәрелешләрне, совет-фин сугышын төшерә. Бөек Ватан сугышы елларында – «Правда»ның фронт хәбәрчесе. Нюрнберг процессында «Правда» корреспонденты буларак катнаша. Совет журналистикасы тарихына иң оператив фотохәбәрчеләрнең берсе буларак кереп кала. Өч Кызыл Йолдыз ордены, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Минзәлә шәһәренең мактаулы гражданины.

ЧИГЕНҮДӘН ҖИҢҮГӘ КАДӘР. ВИКТОР ТЁМИННЫҢ СУГЫШ ФОТОГРАФИЯЛӘРЕ

Әхмәт Шакиров

Рейхстаг өстенә Җиңү байрагын беренче булып кем күтәргәнлеге турында тарихчылар дистә еллар дәвамында бәхәсләшә. Ә менә бөтен дөньяны гизеп чыккан атаклы фотоның авторы кем булуы хакында бернинди бәхәс тә тумый. 1945 елның 1 маенда ут эчендәге рейхстаг өстендә җилфердәгән Җиңү байрагын бер генә кеше фотога төшерә ала. Ул «Правда» фотохәбәрчесе Виктор Тёмин була.

Баште фото – «Правда» газетасында, ә аннары дөньяның башка эре басмаларында дөнья күрә. Бу бердәнбер кадрны ясау өчен нәрсәләр эшләргә туры килүе турында бик азлар гына белә. Җиңү байрагын якыннанрак төшерү өчен, Тёмин командованиедән самолёт сорый. Ләкин иң катлаулысы, куркынычы да бу булмагандыр, мөгаен. Чөнки Берлинда әле атышлар тынмаган, шуңа күрә У-2 очкычын бәреп төшерү ихтималы да зур була.

УТ ЭЧЕНДӘГЕ РЕЙХСТАГ ӨСТЕНДӘ

«Вазгыять бик катлаулы иде, шуның аркасында без, кызганычка каршы, кызыл байрак җилфердәгән рейхстаг янынннан бер генә тапкыр очып уза алдык, – дип яза үзенең истәлекләрендә очучы Иван Ветшак. – Бу бердәнбер фото менә шулай төшерелде».

Аннары Тёминга тиз арада плёнканы Мәскәүгә, редакциягә илтеп җиткерергә кирәк була. «Правда» фотохәбәрчесенә «Дуглас» самолётын биргәләр. Бернчә сәгатьтән очкыч Үзәк аэродромга, Мәскәү үзәгенә диярлек төшеп утыра, ә икенче көнне рейхстаг өстендәге Җиңү байрагының фотосы газетаның беренче битен бизи...

Тёминга «Дуглас»та очарга беркем дә рөхсәт итми, ул аны, 1 нче Белоруссия фронты командующиеның булмаган фәрманына сылтап, урлап алып китә, дигән легенда да яши. Георгий Жуков бу хакта ишеткәч, имеш, бик ярсыган, әмма «Правда»дагы фотоны күргәч тынычланган. Фотохәбәрчене чакырып алган һәм: «Самолёт урлаган өчен

Фото: Минзәлә туган якны өйрәнү музее, russiainphoto.ru

Рейхстаг өстендә җилфердәгән Җиңү байрагы фотосы «Правда» газетасының беренче битендә урын ала.

сине атарга кирәк, ә фотоң өчен син Герой исеменә лаек – Кызыл Йолдыз ордены алачаксың...» – дигән.

Мөгаен, бу легенда гынадыр, гәрчә Виктор Тёминга чыннан да Кызыл Йолдыз ордены тапшырылса да. Хезмәттәшләре арасында тапкырлык һәм оперативлык ягыннан аңа тиңнәр булмый: 1920 нче еллардан, Минзәлә мәктәбе укучысы буларак, «Красная Татария» газетасында фотохәбәрче булып эшли башлаганнан бирле бу шулай. Сүз уңаеннан, Виктор Тёмин үзенең күп кенә тарихи сурәтләрен «Лейка»да төшерә. Фотоаппаратны аңа 1929 елда Казанга килгән вакытында Максим Горький бүләк итә.

1945 ел. Берлинда урам сугышлары.

3. 1944 ел. СССР чиге торгызылды.

НЮРНБЕРГ ПРОЦЕССЫ. КИЛӘЧӘК БУЫННАР ӨЧЕН

«Кукрыникс»ларның берсе – рәссам Борис Ефимов бер мәзәк хәлне искә ала. Нюрнберг процессына барырга тиешле журналистлар утырган самолёт очып китәргә әзерләнә, шул чакта очкычның ишеген шакыйлар. Бу соңга калган фотохәбәрче Виктор Тёмин була. «Кертмәскә!» дип боера делегация җитәкчесе. «Тёмин безне барыбер Нюрнбергта каршы алачак» – дип кисәтәләр аны журналистлар. Нәкъ шулай килеп чыга да.

Нюрнбергта Виктор Тёмин Халыкара хәрби трибуналның эшен иң баштан ук - хөкем карарларын чыгарып, аларны үтәтә башлаганчы ук яктыртырга рөхсәт алган сигез фотожурналистның берсе була. Аның суд барышында ясалган фотосурәтләре – намусларында миллионлаган кеше гомере булган җинаятьчеләрне хөкем итүне яктырткан кырыс документаль дәлилләр. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә утырган рейх башлыкларының, аларның адвокатларының фотолары, дүрт бөек держава вәкилләре – гаепләүчеләрнең фотосурәтләре. Һәм соңгы документлар – трибунал карары буенча җәзаланган хәрби җинаятьчеләрнең мәетләре...

Нюрнбергта Виктор Тёмин төшергән кайбер фронт фотолары Халыкара хәрби трибуналда катнашучыларына тәкъдим ителә. Юк, бу фотокүргәзмә түгел, алар – фашистлар кылган явызлыкларның дәлиле.

1945–1946 еллар. Халыкара трибуналда катнашучыларга нацистлар кылган явызлыклар турындагы фильм күрсәтелә. Геринг, коты очып, битен куллары белән каплый.

1945–1946 еллар. Герман Геринг төрмә баландасын ашый.

1944 ел. Майданек.

1944 ел. Майданек мичләрендә яндырылган поляк, яһүд, русларның гаилә фотолары.

1944 ел. Майданек концлагере. Крематорий миче.

1945 ел. «Миссури» линкорында Япониянең капитуляциясе турындагы актка кул кую.

1945 елның 30 апреле. Берлинда урам сугышы.

СУГЫШНЫҢ СОҢГЫ ФОТОСЫ

1945 елның 2 сентябрендә Виктор Тёмин, совет фотохәбәрчеләреннән берүзе, «Миссури» дип аталган Америка линкоры бортында Япониянең капитуляциясе турындагы актка кул куюны төшерәчәк. Иң яхшы төшерү ноктасын сайлау өчен, аңа АКШ морпехларының өч боҗрасы аша үтеп керергә туры килә. Аларны «җайлау» өчен берничә банка кара уылдык сарыф итәргә, хәтта үзен «Сталинның шәхси фотографы» дип таныштырырга да туры килә. Югыйсә, бернинди тарихи сурәт тә килеп чыкмас иде – Тёминга мәрхәмәтле союзниклар билгеләгән урын һич кенә дә рәтле фото төшерерлек булмый. Һәм бу Икенче бөтендөнья сугышының соңгы фотосы санала.

Аны нәкъ менә Виктор Тёминнның төшерүе, мөгаен, иң югары дәрәҗәдәге гаделлек тантанасыдыр. Сугышның башыннан ахырына кадәр – 1418 көн – ул «Красная звезда» һәм «Правда» газеталарының фотохәбәрчесе сыйфатында хәрәкәттәге армиядә була. Чигенү ачысын, калаләрыбызны утка тотуларын, илнең көнчыгышына таба атлаган, сугыштан качкан халык төркемен дә ул үз фотоларында теркәп калдыра. Мәскәү һәм Севастополь оборонасын, ут эчендәге Сталинградны... Һәм гаделлек тантанасын: туган илебезне азат итүне, Берлиндагы урам сугышларын, рейхстаг һәм Бранденбург капкасына килеп җиткән солдатларыбызны төшерә.

P.S. Сугыштан соң Виктор Тёмин Татарстанга берничә тапкыр килә. 1973 елда Минзәләдә фотокүргәзмәсен оештыра. Аның шәһәргә үзе бүләк иткән фронт фотолары хәзерге вакытта Минзәлә туган якны өйрәнү музеенда саклана. Редакция үтенече буенча музей аларны бастыру өчен «Татарстан»га бирде. Фотоларга күз салыгыз: каршыгызда – фотографияләрдә чагылыш тапкан сугыш елъязмасы. Бернинди цензура һәм бозуларсыз. Автор мәңгеләштергәнчә.

1945 елның мае. Рейхстаг янында Лидия Русланова концерты.

1977 ел. Фотожурналист Виктор Тёмин белән Бөтенсоюз радиосы дикторы, Советлар Союзының халык артисты Юрий Левитан.

ХӘТЕРНЕҢ ДӘҺШӘТЛЕ БИТЛӘРЕ

1948 елда Казан Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторы галимнәре Хәмит Ярми, Халидә Гатина һәм булачак язучы, ул вакытта Казан университеты студенты Нурихан Фәттахов сугыштан соң беренче тапкыр Татарстанның Актаныш, Калинин (бу район 1959 елдан Актаныш һәм Мөслим районнарына бүлеп бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнарына фольклор экспедициясенә чыга. Сугыш тәмамланып өч ел узган. Әмма тыныч тормыш башлануга карамастан, сугыш турындагы истәлекләр дә, ул калдырган яралар да яңа була әле. Бу экспедицияләр вакытында галимнәр белән аралашучыларның, мәгълүмат бирүчеләрнең дә күбесе – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар. Алар Бөек Ватан сугышы турында истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, дошман тылына разведкага барулары, сугышчан дуслары турында да сөйлиләр.

Сезне дә шушы фольклор экспедициясе вакытында Халидә Гатина белән Нурихан Фәттахов язып алган сугыш истәлекләре белән таныштырырга телибез. Язмаларны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге тәкъдим итте. Сөйләүчеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үзгәрешсез диярлек бирәбез. Сугыш ветераннарының җанлы сөйләме истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга, шул чорның дәһшәтен тоярга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Фотолар Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фондыннан.

САЛИХ ШАКИРОВ: «БЕЗ АЛЫП КАЙТКАН ДОКУМЕНТЛАР КЫЙММӘТЛЕ БУЛЫП ЧЫКТЫ»

Илсөяр Закирова

Чираттагы истәлекне Нурихан Фәттах 10 июльдә Салих Шакировтан язып ала.

Салих Шакиров разведка бүлеге командиры була, истәлекләрендә дә немец тылына «тел» алырга барган вакытта булган вакыйгаларны искә төшерә. Сугыш турындагы истәлекләре белән уртаклашканда, Такталачык авыл советы рәисенә – 37 яшь. Ул Бөек Ватан сугышын гвардия капитаны дәрәҗәсендә тәмамлый. Күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Байрак орденына лаек була, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

– Без Сухая Мечетка* балкасында оборонада тораек. 1943 елның гыйнварында бу. Сталинградка кертмәс өчен, немесләр бик нык оборона тотты. Немесләрнең оборона хәлен һәм аларның көчләренең ныклыгын белү өчен, безнең разведотрядка задача куелды – «тел» алып кайтырга.

Бер төнне барган разведка уңышлы чыкмады. Командованиенең задачасы үтәлмәде. Шул ук задачаны үтәү өчен миңа приказ бирелде. Мин штаб начальнигының разведка буенча ярдәмчесе булып эшләй идем. Үзем белән 12 сугышчыны алып, немесләр оборонасында торган пулемет кырындагы бер сакчыны алырга китәргә тиешбез. «Тел» булырга тиеш инде бу. Анда бару өчен без көндездән наблюдение үткәрдек. Аның хәрәкәтләрен өйрәндек.

Сакчыдан 20 метрлар ерактарак немес блиндажы барые. Күзәткән чакта бигрәк тә сакчыларның алышыну вакытына игътибар бирдек – ничә сәгатьтән соң алар алышыналар. Немесләрнең һәр ике сәгать саен алышынып торуын белдек. Күзәтү нәтиҗәләре безгә «тел» алып кайтырга мөмкинлек барлыгын күрсәтте. «Тел»не алырга иң җайлы вакыт дип, смена алышыр вакыт җиткән чакны сайладык. Чөнки бу вакытта сменада торучы немес солдаты арыган була. Шулай итеп, без үзебезнең операцияне үткәрү өчен төнге сәгать икене билгеләдек. Ак халатлар кидек, кинжал һәм автоматлар белән коралландык, көндездән билгеләнеп куйган сукмаклардан немес ягына чыгып киттек. Без чыгып киткәндә, төнге сәгать бер иде.

Төн айлы, якты. Шулай да, бераз кар төшкәнгә, томанланып тора. Немес часовоена барып җитәргә бер йөз метр калганда, бер ышык урынга туктап, дүртәрләп өч группага бүлендек. Бер группа туп-туры часовой

Калинин районы Әмәкәй авылында. 1948 ел.

* Сталинградның төньягында, Портяновка поселогы янындагы елга исеме.

кырына барырга тиеш булды. Ике группа, ике яклап часовойның ике ягыннан барып, артыннан төшәргә тиеш булды. Беренче группа часовойны тере килеш кулга алырга тиеш. Ә ике группа блиндаждагы җал итүче немесләрне блиндажы-ние белән юк итәргә тиеш, гранаталар ыргытып. Монысы соңыннан булырга тиеш инде.

Беренче группаның башлыгы итеп казах егете Чембаевны билгеләдем. Калган ике группаның берсе белән үземә алдым җитәкчелекне, ә икенчесенә Әхмәтдинов дигән җегетне куйдым. Ул – Башкортстаннан. 12 кешедән татарлар – икәү, казахлар – икәү, калганнары руслар, украиннар иде. Без һәрберебез билгеләнгән вакыт буенча тиешле объектка барып җиттек. Группалар арасында төнге вакытта элемтә средствосы булып кесә фонаре утын күрсәтергә тиеш идек. Аны немес күрмәскә тиеш.

Барып җиттек. Беренче группаның эш башлавын көтеп торабыз. Беренче группа немес часовоена 4-5 адым калгачтын, часовой сискәнеп, пулемётына ябышты. Ләкин бу вакытта часовойга соң иде инде. Сугышчылар барып часовойны буып алдылар. Авызына чүпрәк тутырып, капчык кигертеп, алып та киттеләр. Немеснең эше бетте. Пулемёты сакчысыз калды. Бу безнең өчен җайлы момент тудырды. Мин үземнең группадан ике солдатка, пулемёт кырына барып, сменага килүче икенче немесне көтәргә куштым. Аларның берсе пулемёт янында немес часовое кебек булып торырга тиеш иде, икенчесе – күренмәй торырга.

Минем солдатлар барып җитүгә, блиндаждан алмашка немес часовое чыгып, пулемёттан биш адымнар чамасында туктап калды. Шикләнде күрәсең, үзенчә әкрен генә нәрсәдер эндәшә башлады. Безнең солдат, немесчә белмәгәч, берни эндәшми. Шул арада минем группадагы бер солдат шуышып барып, тегенең артына төште. Аның, әкрен генә барып, «Хальт!» дип кычкырып җибәрүенә немес каушап төште, кулын күтәрде. Минем солдат торды да тегеңә ташланды. Шул арада пулемёт кырында торган ике солдат та килеп җиттеләр. Немескә тын алырга да ирек бирмәенчә, авызына бияләйне тыгып, кулын артка бәйләп, тиз генә алып та сыптырдылар безнең якка.

Задача болай уңышлы гына чыккачтын, үзебез дә шатландык, тагын да җөрәкләндек. Мин хәзер ике группа белән дә блиндажга нападать итәргә карар кылдым. Блиндажга нападать итү өчен ике группаны да берләштердем. Ике солдатны пулемёт кырына җибәрдем һәм аны блиндажга таба хәзер тотарга куштым. Сержант Максименкога блиндаждан чыгып торган торбадан тыңларга куштым. Сержант Максименко торба кырына барып колагын салды да миңа ымлый. Аның ымлавы буенча мин дә шуышып кына барып җиттем. Тыңлыйбыз икәүләп, сүләшкән-ниткән тавыш ишетелми, гырлап

1948 ел. Халидә Гатина, Шәһидә Максудова, Нурихан Фәттах юлда.

1948 елның җәе.

җоклаган тавыш ишетелә. Гырлауларына караганда, Максименко, ике кеше булырга тиеш, ди. Мин өч кеше булырга тиеш, дим. Төтен торбасыннан карамакчы булдым. Торбадан карыйм: кечкенә ут җанып тора. Бер немеснең җоклап җатканы күренә, башка берни күренми. Максименкога әйтәм, ничек кенә итеп боларны тавышсыз юк итеп китәргә. Максименко әйтә, ишекне ачып, автоматтан атып бетереп китәргә кирәк, ди. Мин әйтәм, тавыш чыга, күрше блиндажлардан ишетерләр, үзебезнең арт яктан төшәрләр. Тавышсыз гына немесләрне юк итеп китү өчен, Максименконы, аның кырындагы ике солдатны алып, блиндажның ишек кырына килдем. Аларга әйттем, эшнең уңышлы чыгуы менә шушыларга бәйләнгән дип, кинжалларга күрсәттем. Алар шундук аңлап алдылар. Һәрберсе, кинжалларын тотып, тикшереп карадылар. Блиндажга керү белән, һәрберебез берәр немескә ташланырга тиешбез.

Ишекне иплән кенә ачтык. Ут начар яктырта, күпме кеше барын болай ачык күреп булмай. Вакыт та җук. Ишекне ачу белән әчкә ташландык. Ләкин дүртебезгә өч кенә немес булып чыкты. Максименко белән икебезгә бер туры килде. Шулай итеп, немес блиндажы белән эшне бетердек. Блиндажда эленеп торган полевой сумканы, өстәлдә яткан кәгазьләрне тиз генә алып, тышка чыктык. Тышта ул-бу җук, безне сизмәгәннәр. Пулемёт кырында калган ике солдат аның җозагын алып җаталар иде. Шушында шакылдау ишетелеп, күрше блиндажда сөйләшкән тавышлар килә башлады. Безгә ашыгырга кирәк. Югалтусыз тизрәк штабка кайтып керергә.

Эшне сизеп алдылар немесләр. Без үзебезнең якка чыгып китә башлагач, пулемёттан ут ачтылар. Ләкин соң иде инде. Үзебезнең яшерен юлдан кайтып китәргә була иде безгә. Без инде кайтып җитәбез, дигәндә генә, миномёттан ут ачып, Максименконы яраладылар. Аны иптәшләр күтәрде. Шул килеш кайтып җиттек штабка. Безне монда бик көткәннәр икән. Югалтусыз-нисез, шундый уңышлы үткәрелгән операциягә бик шатландылар. Солдатлар, офицерлар – бар да рәхмәт укый, кулны кыса, разведчиклар, гадәтенчә, стопка сузалар. Максименконы медсанбатка җибәрделәр.

Без алып кайткан полевой сумканы һәм башка документларны штаб начальнигы капитан Дятелга бирдек. Безнең алып кайткан документлар командование өчен бик кыйммәтле булып чыкты. Җитмәсә, документларны раслау өчен безнең ике «тел» дә бар. Без алып кайткан документларның һәм «тел»ләрнең күрсәтүе буенча командование өчен уңышлы һөҗүмгә күчәргә мөмкинлек булды. Икенче көнне безнең частьлар немескә каршы һөҗүмгә күчте, немесне оборонасыннан куып алып чыгып китеп, әчкә таба кысрыкладык.

Шушы уңышлы үткәргән разведка операциясе өчен минем үземә Кызыл Байрак ордены бирделәр. Калган сугышчыларның унысына – орденнар, икесенә «Батырлык өчен» медале бирделәр.



186 **ТАТАРСТАНЛЫ** Советлар Союзы Герое була

46 **ТАТАРСТАНЛЫ** – Дан орденының тулы кавалеры

Казанда сугыш елларында

10 000 **«ПЕ-2» БОМБАРДИРОВЩИГЫ,**
11 553 **ТӨНГЕ «ПО-2» БОМБАРДИРОВЩИГЫ ҖИТЕШТЕРЕЛӘ.**

Сугышның беренче айларында ТАССР Язучылар берлегенең **53** әгъзасы арасыннан **25е фронтка китә.** Алар арасында **Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян, Сибгат Хәким, Гадел Кутуй** була.

Фронтка
700 мең
КЕШЕ КИТӘ.

Сугышка китүчеләр арасында –
10 мең
ХАТЫН-КЫЗ

1940 ел белән чагыштырганда, ТАССР сәнәгате җитештергән тулай продукция күләме
1941 елда – 1,4 тапкырга,
1942 елда – 2,4 тапкырга,
ә 1944 елда 3 тапкырдан күбрәккә арта.

Илдә бердәнбер булган Казан кетгут заводы **ЯРАЛАРНЫ БӘЙЛӘГӘНДӘ КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН КЕТГУТ ҖЕПЛӘРЕ** чыгара. Аны җитештерү сугыш елларында **5 тапкырдан күбрәккә арта**. Бу **йөзләгән солдатның гомерен саклап калырга** булыша.

Татарстанга
70тән артык
завод һәм фабрика, ФТИ
эвакуацияләнә һәм үзенең эшен башлый.

ТАССР сәнәгате Бөек Ватан сугышы елларында фронт ихтыяҗлары өчен
600 дән артык
продукция төре
җитештереп чыгара: хәрби самолётлар, корал, артиллерия һәм укчы хәрби припаслар, атаклы «катюша»лар өчен реактив снарядлар һ.б.

ТАССР сугышка
1 млн **ШИНЕЛЬ,**
1,5 млн **ПЛАЩ-ПАЛАТКА ОЗАТА.**
Татарстанлылар көн саен бер полкны киендерә, бер дивизияне аяк киеме белән тәэмин итә.

ТАТАРСТАННЫҢ ҖИҢҮГӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

Республика илгә бирә:

- **131 млн пот икмәк,**
- **59 млн пот ит,**
- **39 млн пот бәрәңге һәм яшелчә,**
- **200 млн литр сөт,**
- **ярты миллион пот йон**

Татарстанлылар сугышчыларга җыя:

- **23 мең кыска тун,**
- **54 мең пар итек,**
- **59 мең телогрейка һәм шаровар,**
- **106 мең пар җылы эчке кием һәм башка кием-салым.**



Казанга СССР Фәннәр академиясенең һәм Белоруссия Фәннәр академиясенең президиумнарын, **20 гә** якын **ФТИ** не эвакуацияләләр. Биредә **100 дән артык** академик һәм Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы эшли: Отто Шмидт, Сергей Вавилов, Александр Несмеянов, Евгений Тарле, Игорь Курчатов, Пётр Капица һ.б.

300 меңгә
ЯКЫН КЕШЕ ӘЙЛӘНЕП КАЙТМЫЙ.

СУГЫШКА КИТКӘН ҺӘР ИКЕ КЕШЕНЕҢ БЕРСЕ ДИЯРЛЕК ҺӘЛАК БУЛА.

РЕСПУБЛИКА ҮЗ ХАЛКЫНЫҢ 11,5%ЫН ЮГАЛТА.

Татарстанлылар оборона фондына

262 МИЛЛИОН СУМНАН

артык акча юллый. Җыелган акчага «Красная Татария» һәм «Колхозник Татарии» танк колонналары, «Совет Татарстаны» авиадивизиясе, бронекатер, бронепоездлар һ.б. төзелә.

Бөтенсоюз социалистик бәйгесендә югары күрсәткечләр биргән һәм **1944 елда хезмәттәге каһарманлык өчен ТАССР сәнәгатенең 22 коллективына Дәүләт оборона комитетының Кызыл байраклары тапшырыла.** Почёт байрагы «По-2» самолётларын җитештергән коллективта мәңгегә калдырыла.

75 еллыгы уңае белән **Казанга «Хезмәт даны шәһәре»** дигән мактаулы исем бирелә. Әлеге исем анда яшәүчеләр сугыш елларында хәрби һәм гражданлык продукциясе белән даими тәэмин иткән, сәнәгать җитештерүен өзмәгән, массачыл хезмәт каһарманлыгы күрсәткән шәһәрләргә бирелә.

Бу елда **«Хезмәт даны шәһәре»** исеме **Яшел Үзәнгә** бирелде. Сугыш елларында монда **117 бронекатер һәм 13 су асты көймәсе җитештерәләр, 4 миллионнан артык артиллерия снаряды ясыйлар.**

ФОТО: «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ АРХИВЫННАН

Мәктәп укучыларының һәммәсе дә югары уку йортларына керергә омтылган чорлар үткәннәрдә калып бара. Белгечләр әйтүенчә, бүген Россиядә яшьләр арасында урта һөнәри белем алу трендта. Бу тенденция Татарстанда ничегрәк чагыла? Урта һөнәри белем алу буенча кайсы юнәлешләрне күбрәк сайлыйлар? Көллият һәм техникумнарда һөнәри белем бирү дәрәҗәсе югары таләпләргә туры килсен өчен, республикаданиләр эшләнә? Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов белән әңгәмәбез шул хакта.

ТӨПЛЕ БЕЛЕМ.
ЯШЬЛӘР КӨЛЛИЯТ ҺӘМ ТЕХНИКУМНАРНЫ САЙЛЫЙ

Евгения Чеснокова

– Андрей Иванович, Татарстанда тугызынчы сыйныфны тәмамлаучылар арасында техникум һәм көллиятләрне сайлаучылар арта, дип әйтеп буламы?

– Соңгы биш-алты елда бу тенденция көчәя бара. Моңа республикада лицейлар һәм көллиятләр нигезендә ресурс үзәкләре ачу буенча программа да этәргеч бирде. Ул 2014 елдан гамәлдә, шул вакытта урта һөнәри белем бирү системасына республика бюджетыннан миллиардлаган акчалар бүлеп бирелде.

Эшче һөнәрләрен популярлаштыруга безнең WorldSkills, «Абилимпикс» (сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен) кебек ярышларда катнашуыбыз да импульс бирде. Сез, әлбәттә, 2019 елда Казанда узган WorldSkills стандартлары буенча дөнья чемпионатын хәтерлисездер. Аннан безгә саллы матди база гына түгел, белгечләр әзерләү буенча заманча методикалар, яңа технологияләр дә калды.

Өстәвенә, шулай туры килде: предприятиеләр урта һөнәри белем бирү системасына йөз белән борыла, аңа ярдәм күрсәтә башлады. Бу бигрәк тә соңгы елларда актуальләшеп китте, чөнки күп кенә тармакларда кадрлар, бигрәк тә эшчеләр җитмәве ачыкланды.

Нәтиҗәсе күз алдында – күп кенә көллиятләргә һәм техникумнарга укырга керү өчен конкурслар барлыкка килде. Узган ел йомгаклары буенча гына да тугызынчы сыйныфны тәмамлаган мәктәп укучыларының 58 проценты урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә укырга керде.

– Советлар Союзының соңгы елларында да күп үсмерләр сигезенче сыйныфтан соң һөнәри техник училищеларга укырга бара иде. Нигездә, алар мәктәптә өчлегә укыган балалар була иде...

– Хәзер алай түгел, хәзер бишлегә укучылар да көллиятләргә килә, кайбер уку йортларына укырга керү бер дә җиңел түгел.

– Кайсы юнәлешләр бүген иң популяр булып санала?

– IT-технологияләр, машина төзелеше, нефть тармагы белән бәйле булганнары – әйтик, Казан авиация көллияте, Әлмәтнең политехник һәм һөнәри көллиятләре, Лениногорск нефть көллияте... Сервис һәм мәдәният белән бәйле күп кенә белгечлекләргә конкурс бик җитди. Медицина көллиятенә һәрвакытта да конкурс зур, ул әлек тә зур була иде, киләчәктә дә шулай булачак. Педагогик белгечлекләр популяр булып кала, Казанның педагогика көллиятенә бер урынга 6-8 кеше дәгъва итә.

– Бәлки, күпләр техникум һәм көллиятләргә укырга кергәндә, һөнәр турында уйламыйдыр, ә югары уку йортына керү җиңелрәк булыр, дип саныйдыр?

– Безнең мәгълүматларга караганда, көллият һәм техникумны тәмамлаган-

Фото: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

нарның 20 проценты гына турыдан-туры вузларга укырга керә. Калганнары эшләргә бара.

– Хәзерге заман яшьләре прагматиграк булып чыгамы?

– Күрәсең, шулай. Карьера баскычларын алар бүгенге көннәреннән үк планлаштыра. Шуңа да бүген һөнәри белемгә ихтыяҗ зур.

– Сез ресурс үзәкләре турында искә алдыгыз. Бүген андый үзәкләр белән калган көллиятләр арасында аерма зурмы?

– Уртача алганда, ресурс үзәкләре, әлбәттә, яхшырак җиһазландырылган. Ләкин шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: соңгы елларда ресурс үзәкләре булмаган урта һөнәри белем бирү учреждениеләре дә яхшы гына үсешкә ирешә. Өстәвенә, «Профессионалитет» дип аталган федераль проектка эләгү өчен конкурста катнашып, үсешләренә этәргеч алу мөмкинлеге бар. Проект көллиятләр өчен бик зур уку-укыту программасын әзерләгән һәм төбәкнең алдынгы предприятиеләре өчен заманча кадрлар әзерләүгә юнәлтелгән. Әлеге проектта безнең 16 көллият катнаша, шушы көннәрдә генә тагын икесе кушылды. 2016 елдан алып, барлыгы 18 көллият катнаша.

– Проектта катнашу көллиятләргә нинди мөмкинлекләр ача?

– Федераль үзәк аларга 70 тән 100 миллион сумга кадәр акча бүлеп бирә. Проект шартлары буенча тагын төбәк һәм җирле предприятиеләрдән дә финанслар бүлеп бирү каралган. Мәсәлән, Казан авиация көллияте әлеге проектта 2026 елдан катнаша башлаячак, һәм аның үсешенә федераль үзәк, республика бюджетларыннан һәм предприятиеләрдән барлыгы 180 миллион сум бүлеп бирү каралган. Бу саллы акчалар, аңа яңа җиһазлар сатып алырга, әзерлекнең яңа юнәлешләрен ачарга була.

Шулай ук проект шартлары буенча эш бирә торган предприятиеләр көллият белән идарә итүдә катнашырга тиеш. Алар хәтта программага үзгәрешләр кертә, аны кыскарта, студентлар әзерләү барышын үзләренең бурычларына яраклаштыра ала.

– Предприятиегә үзенең уку-укыту үзәген ачу отышлырак түгелме? Күпләр шулай эшли дә бит?

– Чыннан да андый үзәкләр бар – мәсәлән, вертолёт заводында, КАМАЗда, «Алабуга Политех» көллияте бик яхшы билгеле. Әмма бер нечкәлеге бар: закон буенча тулы урта белемне гомуми белем бирә торган дисциплиналардан башка гына оештыру мөмкин түгел. Шуңа да предприятиләргә үзләрендә практиканы оештыру уңайлы, ә теоретик база буенча көллиятләр белән хезмәттәшлек итү кулай. «Алабуга Политех» шулай эшли дә.

– Урта һөнәри белем бирү системасында педагогик кадрлар белән эшләр ничегрәк тора?

– Проблемалар бар. Алар күп яктан мәктәпләрдәге кебек үк – кайдадыр укытучылар җитми, олы яшьтәге укытучылар күп. Шунысын да билгеләргә кирәк: бу системага яшь укытучылар да килә. Татарстан Рәисе күрсәтмәсе белән бездә урта һөнәри белем бирү системасында иң яхшы укытучы конкурсы уза, аның акчалата бүләкләре дә бик саллы. Анда бик күчле яшь педагоглар катнаша.

– Уку-укытудагы трендларга яңадан әйләнеп кайтсак, бүген югары белем һөнәри уңышка ирешү өчен мәҗбүри шарт түгел дигән нәтиҗә ясап буламы?

– Мин, мөгаен, өзеп кенә әйтмәс идем. Әмма шундый өлкәләр бар: эш бирүче өчен диплом түгел, ә хезмәткәрнең эшли белүе мөһим. Син югары белемең булмый торып табиб булып эшли алмыйсың, ә менә IT-тармакта югары уку йорты дипломы булмаса да ярый. Совет чорында бездә һәм тулаем дөньяда шундый бер чор булды: һәр буында югары белемле кешеләр саны 20–25 процент кына тәшкил итә иде. Хәзер – 60–70 процент. Күпләр гомернең 4–5 елын югары белем алуга багышламый гына да уңышка ирешеп булуын аңлый.

БҮГЕН ТАТАРСТАНДА 100 ТЕХНИКУМ ҺӘМ КӨЛЛИЯТ ЭШЛИ, ШУНЫҢ 88Е – ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ. 49 РЕСУРС ҮЗӘГЕ БАР. ТАГЫН 22 БҮЛЕКЧӘ УРТА ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ БУЕНЧА ЭШЛИ, ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ СТРУКТУРАЛАРЫНА КАРЫЙ. ЕЛ САЕН УРТА ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНӘ 18 МЕҢ КЕШЕ КАБУЛ ИТЕЛӘ.

– IT-технологияләр турында сүз чыккач, бу турыда сорау бирмичә кала алмыйм: алар белән бәйле һөнәрләр якын киләчәктә элеккечә трендта булачакмы әле, әллә аларга алмашка башкалары киләме?

– Мин бу җәһәттән белгеч түгел, үзем күргәннәрне генә әйтә алам. Хәзер IT-өлкә бик зур үзгәрешләр кичерә. Ун ел элек кенә әле бу өлкәнең күп кенә юнәлешләре турында берәү дә белми иде, алар юк иде. Хәтта биш ел элек, тар даирә белгечләрдән кала, ясалма фәһем турында белүчеләр бар идеме? Ә бит ул, минемчә, киләчәктә бик күп профессионалларны алыштырачак. Мәсәлән, классик программалаштыручылар бүгенге кадәр кирәк булмаячак, кодларны ясалма фәһем язачак. Барысы да тиз үзгәрә, тагын биш елдан трендта нәрсә буласын бүген әйтүе дә кыен. Әмма классик һөнәрләр барыбер калачак. Укытучылар, табиблар, аш-су осталары, төрле сервис хезмәткәрләре – монда кешене берни дә алыштыра алмый.

ХАЛЫКАРА СЕРВИС КӨЛЛИЯТЕ:

СОВЕТ ҺӨНӘРИ УКУ ЙОРТЫННАН ПРОФЕССИОНАЛИТЕТКА КАДӘР УЗГАН ЮЛ

1925 елда Казанда сатучылар әзерли торган Контора мәктәбе ачылганда, йөз елдан соң аның һөнәр белән сәнгать арасына күпер салырлык халыкара белем бирү үзәгенә әйләнәсен беркем дә фаразламагандыр әле.

Заманча Халыкара сервис көллияте (ХКС) – 1000 нән артык студент ул. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаучылар бирегә диплом алырга гына түгел, үзләренең уңышлы киләчәгенә өметләнеп тә килә. Биредә шулай ук квалификацияне күтәрергә яки башка һөнәр үзләштерергә теләүче өлкәнрәк яшьтәгеләр дә укый ала.

Көллияттә халыкка хезмәт күрсәтү тармакларының 4 юнәлеше буенча белем бирелә: азык-төлек, кунакханә, сәүдә, матурлык индустриясе. Аларны 50 дән артык педагог укыта

Хәзерге вакытта Татарстан туристлар күп йөри торган төбәккә әйләнә бара. Россия шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килүчеләр саны ай саен арта. Россиякүләм һәм халыкара чаралар да күбрәк үткәрелә. Шунлыктан профессиональ дәрәҗәдә сервис күрсәтү кадрларына ихтыяҗ көннән-көн арта. Моның белән бергә, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына таләпләр дә катгыйлана. Һәр клиентка игътибарлы мөнәсәбәт һәм профессиональ хезмәт күрсәтү сорала.

– Йөз еллык тарихның барлык детальләрен дә торгызу – катлаулы бурыч, бигрәк тә үзең шаһит булмаган вакыйгалар турында сүз барса, – ди көллият директоры Фәридә Ковалёва. – Әмма юбилей елы кысаларында без яңа стендта уку йорты төзелү тарихының кыскача елъязмасын чагылдырдык һәм соңгы еллардагы казанышларыбызны да күрсәтә алдык.

Җитештерү практикасы күләмен арттыру һәм, профессиональ әзерлек сыйфатын саклап калып, уку вакытын кыскарту көллият партнёрларының күптәнге хыялы була. Нәкъ менә шул бурычларны хәл итү өчен, ХСК белем бирүне җитештерү белән интеграцияләүгә юнәлтелгән «Профессионалитет» федераль проектында катнаша. 192 урта һөнәри белем бирү йорты арасында көллият 30 җиңүченең берсе була.

– Белгечләр әзерләүнең яңа стандартын булдыручылар сафына Казанда

Фото: Александр Ефремов, college-service.org РЕКЛАМА

беренче булып керүебез белән без бик горурланабыз, – ди Фәридә Рәхиб кызы.

«Профессионалитет» проекты укыту тәртибен тамырдан үзгәртә: хәзер студентлар уку вакытының 70 процентын практикада уздыра, теориягә исә 30 проценты гына бүленә. Мондый формат уку чорын дүрт елдан өч елга калдыру мөмкинлеген бирә, көллият тәмамлаучыларны көндәшлеккә сәләтлерәк итә. Яңа программа буенча беренче чыгарылыш 2026 елда планлаштырыла, һәм көллият үз студентларына зур өметләр баглый. Әгәр элек җитештерү практикасына өлкән курсларны гына җибәрсәләр, хәзер тармак предприятиеләре беренче курс студентларын да бик теләп ала. Практика өчен еш кына шактый яхшы акча да түләнә.

Әмма студентлар һәм укытучылар аңында чын революцияне Халыкара WorldSkills (хәзер бу «Профессионаллар» хәрәкәте) чемпионатында катнашу ясый. 2012 елда көллият әлеге хәрәкәткә Татарстанда беренче булып кушыла. Шул вакыттан бирле матди-техник

революция башлана: халыкара стандартларга туры килгән, заманча җиһазландырылган яңа лабораторияләр булдырыла. Азык-төлек тармагында таныш булмаган ингредиентлар, яңа җайланмалар һәм технологияләрне белүне таләп иткән модульләр пәйда була. Компетенцияләрдәге модульләрнең берсе «сәнгать классын» эшләү буенча бирем була, анда булачак кондитерлар, ашчылар, икмәк пешерүчеләр иҗат могҗизасы күрсәтә һәм камыр, шоколад, карамель, экзотик җиләк-җимешләрдән искиткеч җәүһәрләр тудыра. Инновацион косметика чараларыннан креатив образлар тудыручы косметологлар да иҗатта алардан калышмый.

– Бу чыннан да сәнгать иде, – дип елмая директор. – Чит ил партнёрлары, атап әйткәндә, АКШның Техас штатыннан кондитер Стив Манион ярдәмендә без шоколад һәм карамель белән эшләү технологиясен үзләштердек, ә Бөекбританиядән килгән пластик хирургның осталык дәресендә бит тиресен тәрбияләү буенча яңа технологияләрне өйрәндек. Һәм шуны аңладык: камиллеккә чикләр юк икән!

Шунлыктан халыкара хезмәттәшлек көллият эшендә төп юнәлешләрдән берсенә әйләнә. 2010 елдан бирле студентлар һәм укытучылар, әйдәп баручы белгечләр белән кат-кат очрашып, Европаның 14 иле һәм АКШ белән тәҗрибә уртаклаша. Бу чит ил технологияләрен укыту процессына кертүгә һәм уку йортының тизләтелгән үсешенә булыша.

Бүген көллиятне тәмамлаучылар предприятиеләргә югары профессиональ әзерлек белән һәм чын җитештерүдә эшләргә әзер булып килә. Алар яхшы белә: автомат кул хезмәтен алыштыра ала, әмма креативлыкны алыштыра алмый. Җитештерүнең ничек эшләвен аңласаң, гараждагы кечкенә генә икмәк пешерү йортыннан да тулы бер челтәр үсеп чыгарга мөмкин. Һәм, предприятиегә килгәч, алар рентабельлелекне арттыру өчен нәрсәне үзгәртергә кирәклеген дөрес чамалый ала.

– Безнең максат, – ди Фәридә Рәхиб кызы, – студентны җаваплылыктан курыкмаска өйрәтү. Менә шуңа күрә дә диплом яклаганда шеф-поварлар һәр студент өчен җан ата: чөнки алар ризык әзерләү остасы гына түгел, бәлки процессларны оптимальләштерә, сатучылар белән сөйләшүләр алып бара, бәя куя белә торган белгечләр дә. Һәм безнең студентыбыз: «Бу предприятиедә миңа ышаналар», – дип әйтә икән, димәк, эшебезгә иң югары бәя бирелгән дигән сүз.

Халыкара сервис көллиятенә кыю планнарының тормышка ашуын, яңадан-яңа үрләр яулавын телибез!

college-service.1mcg.ru

rescentermkskazan@mail.ru

Директорның кабул итү бүлмәсе:
8 (843) 522-62-02
Кабул итү комиссиясе:
8 (843) 522-51-50

ӘЛМӘТ ҺӨНӘРИ КӨЛЛИЯТЕ – КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ ҮЗӘГЕ

Дмитрий Сивков

Эшче һөнәрләре – хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган һөнәрләрнең берсе. Бу җитештерүнең үсүе һәм импортны алмаштыру программасын гамәлгә ашыру белән бәйле. Шушы көннәрдә илле еллыгын билгеләп үтә торган уку йортын тәмамлаучылар да Татарстан Республикасында квалификацияле эшче кадрлар кытлыгын өлешчә каплый.

Әлмәт һөнәри көллияте директоры Анжела Шәрипова.

ЗАМАН ТАЛӘБЕНӘ ҖАВАП БИРӘБЕЗ

70 нче еллар уртасындагы Әлмәт шәһәре. Нефть төбәге башкаласы шәһәр предприятиеләренең саны, алар җитештерә торган продукциянең артуы белән бергә бик тиз үсә башлый. Бу, үз чиратында, төпле, һөнәри яктан белемле эшче кадрлар әзерләүне таләп итә.

1975 елда ачылган 65 нче техник училище кадрлар әзерләү үзәгенә әйләнә. Укыту-җитештерү комплексы төзелешен «Радиоприбор» берләшмәсенең Әлмәт филиалы финанслый һәм алып бара. Укыту остаханәләре базасында әлеге заводка кирәкле эшләр башкарыла. Ягъни, асылда, уку йорты эшчәнлегенең башында ук предприятиеләр белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Бу илле ел узганнан соң да төп эш юнәлешләренең берсе булып кала бирә. Көллият шәһәрнең В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Таграс» холдингы, «ОМК Әлмәт заводы», «Римера-Алнас», «ТМС Групп» ҖЧҖ ИК, «Әлмәт электр челтәрләре» АҖ филиалы, «Татойлгаз» АҖ, «МехСервис ФҖБ» ҖЧҖ, «Радиоприбор» Әлмәт заводы» ААҖ, «Транснефть – Прикамье» АҖ, «Газпром» ГАҖ кебек шәһәрнең иң яхшы предприятиеләре белән уңышлы хезмәттәшлек итә.

Әлеге предприятиеләрнең кадрлар бүлеге уку процессында актив катнаша, студентларның укудагы өлгерешләрен күзәтеп бара, практикалар оештыра һәм аттестацияләргә килә. Укытуны шул рәвешле алып барганга, көллият хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган, көндәшлеккә сәләтле белгечләр әзерли. Соңгы елларда көллиятне тәмамлаучыларның эшкә урнашу дәрәҗәсенең югары булуы да – 92 процент – шуны раслый.

Бүген Әлмәт һөнәри көллияте машина төзелеше һәм металл эшкәртү

Фотолар Әлмәт һөнәри көллиятеннән алынды. РЕКЛАМА

сәнәгате өчен белгечләр әзерләүнең күп баскычлы системасын тәкъдим итә. Ул квалификацияле эшче, хезмәткәр, шулай ук урта звено белгече дипломын алырга мөмкинлек бирә.

Ярты гасыр эчендә уку йорты 15 меңгә якын белгеч әзерләгән, башлыча икътисадның реаль секторы өчен. Һәм бу сан һәрвакыт арту ягына бара. Хәзерге вакытта көллияттә 937 студент белем ала, шуларның 306 сы укуны быел тәмамлый.

БАРЫСЫН ДА КАДРЛАР ХӘЛ ИТӘ

Уку йорты тарихындагы мөһим вакыйгалар... Ярты гасыр эчендә алар шактый була, мәсәлән: 31 нче һөнәр училищесын (2009 ел) һәм 84 нче Рус Акташы һөнәр училищесын (2010) көллияткә кушу; «Бөтенроссия мактау китабы» федераль реестрына кертү (2009); 2010 ел – кадрлар әзерләүнең нәтиҗәле системасын формалаштырырга ярдәм итү максатыннан «дуаль белем бирү»нең немец моделен (уку вакытының 40 процентын – теория, 60 процентын практика алып тора) һәм уку сыйфаты белән идарә итүнең фин тәҗрибәсен кертә башлау; 2013 ел – «Алнас» ҖЧҖ белән уртак «Татарстанның киләчәк көллияте» мәгариф проектын гамәлгә ашыру; 2018 ел – «Сәнәгать» юнәлеше буенча ТР һөнәри белем бирүнең ресурс үзәге статусын алу (РҮнең төп өстенлекләре – оптимальләштерү, һөнәри программаларның эчтәлеген яңарту, эш бирүченең уку процессында һичшиксез катнашуы); 2019 ел – «Римера» дәүләт корпорациясе, Әлмәт һөнәри көллияте, РФ Оборона министрлыгы һәм Самара өлкәсенең Мирный бистәсендәге хәрби часть арасында килешүне имзалау (хәзер көллиятне тәмамлаучылар әлеге частьта хезмәт итә, ә завод һәм көллият җитәкчелеге квартал саен Көллиятне тәмамлаучылар ассоциациясе вәкилләре, студентлар һәм ата-аналар өчен хәрби частька сәфәрләр оештыра).

Россиянең иң яхшы токаре Айдар Әшрәпов Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән.

Яшь белгечләрнең күнекмәләрен үстерүдә ел саен үткәрелә торган «Һөнәре буенча иң яхшы» һөнәри осталык конкурслары мөһим этәргеч булып тора, аларны көллият үз остаханәләре базасында үткәрә. Һәм бу эш башка дәрәҗәләрдә дә бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Мәсәлән, узган ел Татарстан Республикасы «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының төбәк этабында көллият ике алтын, берәр көмеш һәм бронза медальгә лаек була. Өстәвенә, көллиятне 2024 елда тәмамлаган Айдар Әшрәпов «Һөнәре буенча иң яхшы» Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының «Иң яхшы токарь» номинациясендә җиңүче була. «Римера-Алнас» компаниясе белгечен бу уңышы белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзе котлый.

Үзенең эшчәнлеге дәвамында әлеге урта һөнәри белем бирү йорты исемен берничә мәртәбә үзгәртә, әмма аның югары квалификацияле инженер-педагогик составы заманча белем бирү стандартларына туры китереп эшләвен тәэмин итә. Житештерүгә өйрәтү осталары, укытучылар һәм хакимият хезмәткәрләре арасында көллият җитәкчелеге әлеге уку йортында 30 елдан артык эшләүчеләрне билгеләп үтә. Алар – Лилия Егорова, Елена Елисеева, Надежда Колесникова, Татьяна Маслова, Светлана Михайлова, Миләүшә Рәфигуллина, Сәрия Сәйфуллина, Николай Сороковнин, Гөлчирә Фәйзуллина, Светлана Хисаметдинова, Любовь Чекова һәм Валентина Мулеева.

Уку-өйрәтү процессы һәм аның нәтиҗәләре өчен төп җаваплылыкны алган директорларны билгеләп үтми булмый. Алар арасында – Павел Айкашев (1975–1976 еллар), Николай Клюшников (1976–1999 еллар), Иван Рябов (1999–2014 еллар), Артур Миңнәхмәтов (2014–2018 еллар), Гүзәл Бакиева

Көллият администрациясе һәм уку йортында 30 елдан артык эшләгән җитештерүгә өйрәтү осталары.

(2018–2021 еллар), Анжела Шәрипова (2022 елдан).

Әлмәт һөнәри көллияте күркәм уңышларга җитәкчелекнең һәм барлык педагогларның уртак хезмәте бәрабәренә ирешә. Уку йортының төп эш нәтиҗәсе – көллият тапшырган дипломнар киштәдә тузан җыеп ятмый, белгечләргә һөнәри карьералары башында таяныч булып тора. Моңа мисаллар шактый. Әйтик, «Радиоприбор» заводында Сергей Назимов – башкарма директор урынбасары – баш инженер, ә Илдар Садыйков һәм Руслан Әхтәмов цех җитәкчеләре булып эшли. Геннадий Иванов – «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы – Әлмәт электр челтәрләренең технологик тоташтыру буенча директор урынбасары, Рамил Сөнгатов – җитештерү контроле һәм хезмәтне саклау бүлегенең әйдәп баручы инженеры, Айрат Миңнәхмәтов – «Татнефть» ГАҖдә энергетика идарәсенең баш белгече.

Уку йортының: «Без югары квалификацияле белгечләр һәм көндәшлеккә сәләтле шәхесләр әзерлибез!» дигән девизы әнә шул рәвешле тормышка ашырыла.

УЙНАП ӨЙРӘНҮ

Евгения Чеснокова

Татарстан укучылары әдәпле җәяүле һәм йөртүче булырга өйрәнә.

– Мин юл аркылы чыкканда самокаттан төшеп, аны үзең белән янәшә алып барырга кирәклеген белдем!

– Ә мин юлда барганда колакчыннар киеп йөрергә ярамаганлыгын аңладым, чөнки якынлашып килә торган машина тавышы ишетелмәскә мөмкин!

– Ә менә бу билге «Төп юл» дигәнне аңлата!..

...Бу Казандагы бер мәктәпнең башлангыч сыйныф укучыларының җаваплары. Алар «КидСпейс» һөнәрләр шәһәре локацияләрендә юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча квест үттеләр. Квесттан соң алып баручыларның сорауларына дөрес итеп җавап бирделәр һәм бүләкләр алдылар. Бүләккә юлда күренергә ярдәм итә торган яктылык кайтаргыч брелок һәм юл иминлеге темасына кагылышлы биремнәр язылган дәфтәр алдылар.

СВЕТЛАНА БИКЧӘНТӘЕВА,
«Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» ДБУ директоры урынбасары:

–Мәктәп укучылары өчен «Юл хәрәкәте кагыйдәләрен беләм, үтим» уен курсында балалар юл куркынычсызлыгы кагыйдәләрен өйрәнеп кенә калмый, ә юлда үзеңне дөрес тоту әдәбен дә үзләштерә. Уеннарда күбрәк укучылар катнашкан саен, юлларда тәртип бозучылар саны да шулкадәр азрак булыр, дип өметләнәбез.

– Кечкенә сыйныф укучылары өчен «Юл хәрәкәте кагыйдәләрен беләм, үтим» уенын Казанда инде бишенче ел оештырабыз, – дип сөйли «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» ДБУ директоры урынбасары Светлана Бикчәнтәева. – Әлеге вакыт эчендә 8,5 мең укучы белем алды. Быел тагын 4,5 мең баланы укыту планлаштырыла. Шунысы да бар: мондый уеннарны Казанда гына түгел, республикабызның башкалага якын биш районында: Югары Ослан, Биектау, Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсендә оештырабыз. Гомумән, квестлар географиясен елдан-ел киңәйтергә һәм бөтен республиканы колачларга ниятлибез.

«Юл хәрәкәте кагыйдәләрен беләм, үтим» проекты «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» ДБУ тарафыннан ТР буенча ЭЭМ Дәүләт автоинспекциясе һәм ТР Фәннәр академиясенең Тормыш иминлеге фәнни үзәге ярдәмендә тормышка ашырыла. Светлана Бикчәнтәева сүзләренә караганда, уку программасының үзенчәлеге аны бирү форматында: бу – уен зоналарына («Мин йөртүче», «Мин җәяүле»,

Фотолар проектның матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

РӨСТӘМ ГАРИПОВ, Татарстан Республикасы буенча юл хәрәкәте иминлеге баш дәүләт инспекторы:

– Ел башыннан Татарстанда 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 58 юл-транспорт һәлакәте теркәлде, нәтиҗәдә бер баланың гомере өзелде, 65е җәрәхәтләнде. Кызганычка каршы, балалар травматизмы балигъ булмаганнар арасында үлемнең төп сәбәпләре арасында кала бирә. Шуңа күрә дөрес профилактика чаралары, шул исәптән мондый квестлар юл хәрәкәтендә катнашучы балаларның сәламәтлеген һәм гомерләрен саклап калырга мөмкинлек бирә.

«Мин ДАИ хезмәткәре», «Мин пассажир») бүленгән интерактив квест. Һәр зонада укучылар юл билгеләре белән танышалар һәм күп файдалы мәгълүмат алалар: ни өчен машинада куркынычсызлык каешын эләктерергә кирәк, моны ничек дөрес эшләргә, хәрәкәт вакытында ни өчен йөртүчене борчырга ярамый, машиналар күп булган урам чатларында үзеңне ничек тотарга, светофор утына карап, самокатта, велосипедта ничек дөрес йөрергә тиешсең, Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәре йөртүчегә, җәяүлегә нәрсә өчен штраф салырга мөмкин.

– Оештыручыларның юл хәрәкәтен өйрәнү программасын укучыларның яшенә җайлаштырып кына калмыйча, программаны даими яңартып торулары яхшы, – ди проектның кураторы Елена Тихонова. – Мәсәлән, шәһәрдә электр самокатлары катнашында инцидентлар күбәя башласа, квестта нәкъ менә әлеге транспорт төренә караган биремнәрне күбрәк бирәләр. Шунысы да яхшы: балаларны җәяүле яки велосипедчы сыйфатында юлда үзләрен дөрес тотарга гына түгел, бәлки, әдәпле пассажир һәм йөртүче булырга да өйрәтәләр. Балаларның әти-әниләре руль артында кагыйдәләрне үтәмәгән вакытлар да була бит, мәсәлән, куркынычсызлык каешын эләктермиләр. Ә балалар мондый очракларда әти-әниләрен кисәтә ала, дип уйлыйм, без шуңа да өметләнәбез. Ә бит вакыт тиз бара – балалар үзләре дә якын киләчәктә машина йөртүче булачак. Алар инде бүгенге олыларның хаталарын кабатламас, дип тә ышанабыз.

Башта проект башлангыч сыйныф укучыларына гына йөз тота. Әмма узган ел программаны киңәйттеләр.

– Без уртанчы сыйныф укучыларына күчмә белем бирү блогын өстәдек, – дип аңлата Светлана Бикчәнтәева. – Бу безнең төп максатчан аудиториябез, чөнки статистика буенча юл-транспорт һәлакәтенә ешрак унбер-унөч яшьлек балалар эләгә. Дәресләр Казанның 17 мәктәбендә узды, һәм анда бер мең ярым укучы катнашты. Күчмә уеннар бик ошады – педагоглар бу эшне хуплады. Быел көз көне без яңадан уртанчы сыйныфлар өчен укулар оештырачакбыз.

ӘЛФИЯ АЙДАРСКАЯ: «ҮЗ МИССИЯМНЕ ҮТӘДЕМ, ДИП САНЫЙМ»

Руфия Фазылова

Җырчы һәм композитор Сара Садыйкова белән актёр һәм режиссёр Газиз Айдарскийның бердәнбер кызлары – балерина Әлфия Айдарская янында булып кайттык. Шушы көннәрдә аңа 100 яшь тула. Татарстанның атказанган артисткасы Казан үзәгендәге ике бүлмәле фатирында ялгызы яшәп ята. Маникюры ясалган, фатиры җыелган, суыткычы тулы ризык...

Әлфия Айдарская сугыш чорына туры килгән яшьлеге, әнисенең Муса Җәлил белән дуслыгы турында сөйләде һәм тагын бик күп истәлекләр, серләре белән бүлеште.

– Әлфия апа, кәефләр ничек? Ялгыз гына яшисез, сезгә кемнәр ярдәм итә?

– Берәү дә ярдәм итми. Ике көн элек кенә идәннәрне юып чыгардым. Көн саен булмаса да, кибеткә дә үзем йөрим. Дөрес, хәзер башым әйләнгәли. Шулай да үз көнемне үзем күрәм әле, шөкер. Хәлемне белергә килүчеләр дә байтак: укытучылар, журналистлар, сәнгать әһелләре...

– Әлфия апа, яшьли вафат булгангамы, этиегез Газиз Айдарскийның иҗаты гел күләгәдә калган кебек. Югыйсә ул Мәскәү кадәр Мәскәүдә татар театры булдырган кеше. Сез шулай дип уйламыйсызмы?

– Уйлыйм. Ни кызганыч, эти иртә вафат булган. Утыз дүрт яшь кеше гомере өчен бик аз. Эти вафатыннан соң, Мәскәүдә татар театры да ябылган. Исән булса, әллә ниләр майтарган булыр иде, дим.

Эти туберкулёз белән чирләде. Ул вафат булганда, миңа 8 яшь иде. 1933 елның октябрь аенда хастаханәдә үлде. Әнинең бик нык бәргәләнгәне истә, аны этинең мәетеннән көчкә аерып алдылар. Хәтерлим, этине озату мәрасимендә бик күп кеше чыгыш ясады. Аннан соң без әни белән йөк машинасының кузовына утырып кайттык. Хушлашу мәрасимендә безнең янда гел бер абый булды, ул миңа елмаеп карады. Башымнан йомшак кына сыйпап куюы да истә. Соңыннан гына ул абыйның шагыйрь Муса Җәлил икәнен аңладым.

– Әтиегезне ничек истә калдырдыгыз?

– Әтине биш яшемнән генә беләм, чөнки эти белән әни башта Мәскәүдә укыганнар, аннары эшләгәннәр. Ә мин Казанда – Биш-

Фотолар: Александр Ефремов, Әлфия Айдарскаяның шәхси архивыннан

балта бистәсендә әби белән бабай тәрбиясендә үстем. Биш яшемдә беренче тапкыр Мәскәүгә, әти белән әни янына кунакка бардым. Ул вакта бер авыз русча белмим һәм моңа бик ояла идем. Ешрак күргәнгә, әнидән кыенсыну булмады, ә менә этигә башта кем дип эндәшергә дә белмәдем. Тәрәзәдән Айдарскийны күреп, әнигә: «Әнә, синең кешең кайтып килә», – дип әйтә идем. Шулай да этигә тора-бара ияләндем, ул миңа карата назлы, игътибарлы булды. Өчәү бергә паркта һава сулап йөргәнне хәтерлим. Тагын бер вакыйга истә калган: эти белән күзәтү тәгәрмәченә мендек, аска карасам, әни безгә елмаеп кулын болгый. Мәскәүне шундый биеклектән күрү үзенә күрә бер вакыйга булган иде.

– Газиз Айдарскийның кабере дә юк икән...

– Әйе, эти исән вакытында ук мәетен крематорийда яндырырга кушкан. Әлеге эшләр белән ул вакытта Муса Җәлил шөгыльләнгән. Алар этием белән бик якын дуслар булганнар. Хастаханәгә дә Газиз Айдарскийны ул урнаштырган, тик аяныч, өч көннән эти барыбер мәрхүм булган. Мәетне крематорийда яндыргач, көлен банкага салып, әнигә биргәннәр. Беренче елларда әни аны өйдә өстәл астында саклаган. Соңрак әни ул банканы Камал театры музеена тапшырган. Тик 1987 елда, Камал театры хәзерге Тинчурин театры бинасыннан Татарстан урамына күченгәндә, ул банканы югалтканнар... Эзләтеп-эзләтеп карасак та, барыбер очына чыга алмадык. Әни бу хәлгә бик борчылды, әлбәттә.

– Әтиегез Муса Җәлил белән бик дус булган, үзегез дә әйтеп уздыгыз. Сара апа аларның дуслыгы турында нәрсәләр сөйли иде?

– Муса Җәлил белән этинең идеаллары уртак булган. Ул чорда Мәскәүгә бик күп татар яшьләре укырга килеп, заманына күрә зур эшләр башкарганнар.

Сугыш башланганчы, әниләр Казанда Муса Җәлил белән күрше бүлмәдә яшәгән. Әни ул чагында Казан дәүләт опера һәм балет театрында эшләде. Муса абый да шунда хезмәт куя, тик ул гаиләсен вакытлыча Мәскәүдә калдырган була. Шуның өчен дә иртәнге чәйгә ул еш кына әни янына кергән. Әле мин дә ул чакларны яхшы хәтерлим: Муса абый кулына зур гына чынаягын, сыер маен, ак ипиен күтәреп, бөтен коридорны шар ярып килеп керер иде. Телгә үткен, бик чибәр кеше булып истә калган. Муса Җәлилне «халык дошманы» дип игълан иткәч, әни бик борчылды. «Мин моңа ышанмыйм, алай була алмый», – диде.

– Әлфия апа, сез – сугыш чоры баласы. Шул турыда да күбрәк сөйләшсәк иде. Сугыш башланган көнне хәтерлисезме?

– Хәтерлим. Мин ул чакта А.Я. Ваганова исемендәге Ленинград дәүләт хореография училищесының (хәзерге Рус балеты академиясе – *авт.*) икенче курсында укый идем. Безне Ленинградтан эвакуацияләделәр, чөнки анда мәхшәр башланды. Башта Уфага кайттым, тик әнинең мине Казанга кайтарасы килде. Ул да түгел, Уфага үзе дә килеп җитте. Татар дәүләт опера һәм балет театрына эшкә чакырабыз, дигән кәгазе дә бар иде. Шулай итеп, әнигә ияреп, Казанга кайттым. Сугышның беренче кышы бик авыр булды, 40 градус салкын. Карл Маркс урамы, 59 нчы йортта яшәдек. Бүлмәбез боз кебек, «буржуйка» мичен ягабыз, утын юк. Җылынып өчен бөтен нәрсәне, хәтта укыганнан соң, китапларны да яга торган идек. Өстә – бишмәт, аякта киез итек. Әле итеге дә юк, әнигә каяндыр табып бирделәр. Татар дәүләт опера һәм балет театрында бер ел да эшләмәдем, штат кыскартылды. Әни дә кыскартуга эләкте. Нишләргә? Яшәргә кирәк.

Казанның 543 нче заводына кеше кирәк дигәч, шунда бардым. (Хәзерге «Сантехприбор» заводы. 1941 елда Луганск шәһәреннән

Әлфия Айдарская әнисе Сара Садыйкова һәм улы Ростислав белән.

Бибигайшә һәм Гариф Садыйковлар – Әлфия Айдарскаяның әби-бабасы.

«Бахчасарай фонтаны» балеты. Зарема ролендә.

– Балерина буларак лаеклы ялга чыккач, Казан циркында эшләдем, – диде Әлфия Айдарская.

эвакуацияләнә һәм 6 нчы тегү фабрикасы территориясендә урнаштырыла. Завод ул чакта сугыш патроннары эшләп чыгара – *авт.*). Мине шунда 2 нче цехка алдылар. Вазыйфам – хәрби товарны үлчәп тору. 12 шәр сәгать ялсыз эшләдек. Шуның өчен кырык сум хезмәт хакы түлиләр. Аны әни белән икегә бүләргә кирәк.

Акчасы – бер хәл, кибетендә ризыгы юк. Кайбер көннәрдә өстәлебездә бер стакан кайнар су гына була торган иде. Бер кило бәрәңге тапсаң, бәхет инде! Аннары талоннар бирә башладылар. Су буе чират торып, ипи, май аласың.

1943 елда завод янындагы кибеткә балыклар кайта башлады. Гел шунда кереп йөргәч, кибетчеләр таныйлар, шуның өчен дә балыкны күбрәк бирәләр. Мин исә балыкны алам да колхоз базарына төшеп китәм. Кибет бәясеннән арттырып сатам: хәзер алып бетерәләр. И, әни янына сөенеп кайтам инде, акча эшләдем бит. «Кызым, әле ярый син булгансың, ачка үләр идек», – дип, әни мактый иде үземне. Сугыш елларын менә шулай зур авырлык белән үткәрдек.

– Балерина булу теләге каян барлыкка килде, Әлфия апа?

– Казанда, Бишбалта бистәсендә яшәгәндә, безнең ишегалдына көн саен бер сукыр скрипкачы кереп йөрде. Аның скрипкада уйнаганын ишетеп алуга, буялмаган агач баскычтан шуып төшеп, бии башлый идем. Нәрсә уйнаганын аңламыйм, әмма бу көй миңа шундый якын иде. Югары сәнгатькә тартылу шуннан башланмадымы икән?

1935 елда әни мине үзе белән Уфага, гастрольләргә алды. Ул вакытта инде танылган җырчы иде ул. Уфада без аның дусларында яшәдек. Әни – репетициядә, ә мин ялгызым урамнарны карап йөрим. Берсендә, шулай шәһәр буйлап йөргәндә, игълан күреп алдым: «Башкорт һәм татар милләтеннән булган, 12 яшькәчә малай һәм кызларны Ленинград балет мәктәбенә укырга чакырабыз», – диелгән иде анда. «Ленинград» сүзе мине сихерләгәндәй итте, анда бит бер тапкыр да булганым юк. Әмма күз алдыма театр, биючеләр, музыка килеп басты... Ике дә уйламыйча, шушы белдерү эленеп торган бинага кердем.

Анда 300 ләп бала җыелган иде. Хәтерлим, аякларыбызны капшап-капшап карадылар, төрле якка боргаладылар. Аннары ритмны тоемлау, ишетү сәләтен тикшерделәр. Шуларның барысын да эшләп чыктым. Нәтиҗәдә, ишегалдында медицина тикшерүе узарга куштылар. Шуннан соң дүрт көннән вокзалга килергә әйттеләр. Баксаң, бары тик 12 баланы гына сайлап алганнар! Мин моны соңыннан гына белдем.

– Әниегез, белгәч, шаккаттымы? Ун яшьлек бала өчен бик зур, көтелмәгән адым булган бит...

– Әлбәттә, шаккатты. Миңа калса, ул башта бик ышанмады да. Безне училищега 1 еллык сынау срогы белән генә алдылар. Ярар, ошамаса китәр, дип тә уйлагандыр. Тик мин теш-тырнагым белән ябыштым. Яшермим, уку бик авыр булды. Ленинградта бөтен кеше русча сөйләшә, ә мин белмим. Тик шуны ачык аңлый идем: тырышып укымасам, өйгә кайтарып җибәрәчәкләр. Нәтиҗәдә, бер ел эчендә рус телен яхшы өйрәндем. Әлбәттә, укытучыларыбызның зур тырышлыгы да бу. Кечкенәдән хәтер яхшы иде: бер күрсәм, барысы да исемдә кала. Көн-төн китап укыдым, шуның нәтиҗәсендә диктантларны гел «5»кә яздым.

Бию элементларын да шулай – беренче тапкырдан ук истә калдыра идем. Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлагач, балетмейстерыбыз Гай Таһиров мине Мәскәүгә – Зур театрга җибәрде. Минем максат – Рейнгольд Глиэрның «Красный мак» балетын истә калдырып, кайткач, шуны кабатлап күрсәтү. Барысын да истә калдырдым. Гай Таһиров мактаган иде.

– Сез 20 елдан артык Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшләгән артистка. Кайсы рольләрегез белән аеруча горурланасыз?

– Артист өчен һәр роле якын инде ул. Алай да мәңгегә истә калган рольләр була... Укуны тәмамлагач, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында беренче зур ролем Аданның «Жизель» балетында Мирта партиясе булды. Ул вакытта балет труппасы белән СССР Зур театрының элеккеге биючесе Леонид Алексеевич Жуков җитәкчелек итә иде. Репетицияләрдә беркайчан да беркемгә дә тавышын күтәрмәде, һәр артистка ягымлы итеп эндәшә иде. Мин исә яшь актриса, һәр хәрәкәтемне сынап кына карый... Репетицияләрдә миңа бармак очына гына басарга куша. Ә бу бер дә җиңел түгел. Аяк бармаклары канга кадәр

Әни кочагында. 1934 ел.

ышкылып чыга, ә сиңа йөгерергә, сикерергә яки «йөзәргә» кирәк. Һәм көн саен шул ук хәл кабатлана... Юкка гына: «Балерина хезмәте – ат хезмәте ул», – димиләр. Леонид Алексеевич алдында барыбер сер бирмәдем. Нәтиҗәдә, ул миңа мактау сүзләрен җиткерде. Тик канга баткан аяк бармакларымны күреп, әнинең йөрәге өзгәләнде. «Ташла балетны, икенче һөнәр сайла», – баштарак гел шулай дип әйтә иде. Нинди ташлау! Бу бит үз-үзеңә хыянәт итү була!

Нәҗип Җиһановның «Зөһрә»сендә – Җамал, Петр Чайковскийның «Лебединое озеро»сында – Одеттаны һәм башка күп кенә партияләрне башкардым. Әле Камал театрында «Хуҗа Насретдин» спектаклендә көнчыгыш халыклары биюен биедем. Балерина буларак лаеклы ялга чыккач, Казан циркында эшләдем. Шөкер, бик кызыклы, актив тормыш белән яшәдем һәм бер дә үкенмим.

– Әлфия апа, инде әниегез Сара Садыйкова турында да сөйләшми мөмкин түгел. Ул сезгә карата таләпчән булдымы, әллә инде, киресенчә, йомшак идеме?

– Әнкәй бик сабыр, гадел, шул ук вакытта таләпчән кеше иде. Ленинградта укыганда дәү әнием вафат булган, тик бу яман хәбәрне әни миңа әйтмәде. Укуыма зыян килер дип уйлаган. 1940 елда дәү этием дә бакыйлыкка күчкән, бу кайгылы хәбәрне дә миннән яшергән. Дәү этине аеруча яраттым, ул миңа карата бик мәрхәмәтле, игътибарлы иде.

Казанга кайткач, башта әни миңа карата кырысрак булды кебек. Тик мин аның өчен әнигә бер тамчы да үпкәләмим, шул рәвешле тормышка өйрәткән, дим. Аның ярдәме белән генә хатын-кыз эшләренең барысына да өйрәндем. Сер түгел, башта – әби, бабай тәрбиясендә, аннан Ленинградта тулай торакта яшәгәндә, йорт эшләрен бөтенләй белми идем. Кайчагында әни, ачуы килеп: «Бу кадәр дә Айдарский булырсың икән!» - дип әйтә торган иде. Ә инде аңа ошый торган гамәл башкарсам: «Вот, моя школа!» – дип мактый иде.

– Сезгә шушы көннәрдә 100 яшь тула. Болай матур картаюның сере бармы, Әлфия апа?

– 100 яшь дип уйлап куям да... куркыныч булып китә. Дөресме икән, дим. Югыйсә күңел бер дә ышанмый. Кеше 120 яшькә кадәр яши ала, дип укыдым. Шулай булгач, өмет бар әле...

91 яшемә кадәр көн саен физкультура ясадым. Хәзер ташладым, андый теләк юк. Бүген менә шулай үз дөньямда, үткәннәр белән яшәп ятам. Бик яхшы ир белән тордым, тик ул 1985 елда ук вафат булды. Данлыклы виолончелист Всеволод Грекуловны хәзер дә аерым даирә кешеләре хәтерли, белә. Бердәнбер улым да дөньялыкта юк, ул да музыкант иде. Әнә шулай итеп ялгыз калдым. Дөрес, бер генә көнне дә бушка уздырмыйм. Әле дә Сара Садыйкова җырларыннан торган концертлар оештырам. Соңгысы 6 майда Актёрлар йортында булды. Әнинең, этинең мирасын барлап, күп китаплар бастырдым. Алар каршында үз миссиямне үтәдем, дип саныйм...

Хәмидә Гарипова

ЯЗ ИСЕ

Дәвамы. Башы басмабызның 4 нче санында

(хикәя)

...Март ахыры иде. Ә бу айның акылы керәле дә чыгалы икәнлеген беләсез инде. Төнлә шактый ук суытып җибәргән: кичтән җырлашып йөгерешкән гөрләвекләр тынып калган. Юл уртасындагы күлләвекләрнең өстен боз челтәрләре чуарлаган. Әминә райүзәк белән Кошман авылы арасындагы Быкыр ермагын иртән тыныч кына узды. Районда йомышларын йомышлап, авыр почта букчасын иңнәренә асып, кайтыр якка кузгалганда, вакыт төштән авышкан иде.

Яз кояшы нурларын мулдан сипкәнгә, көн яхшы ук җылытып җибәргән. Аяк астындагы кар кай арада юеш боламыкка әйләнгән? Чабатасы күтәртмәле, туласы калын булса да, аякчуларына дым тартуын тойды. Иң мөһиме, иңкүлектән ташу суы төшкәнче, мәкерле ермакны исән-имин үтеп өлгерергә кирәк. Хәвефле урынга якынайган саен, йөрәге ешрак тибә башлады. Кызның колагына ап-ачык итеп язгы суның кар астыннан шаулап акканы ишетелде, тик әлегә ул юл өстенә чыкмаган иде. Күрәләтә хәтәр урынга аяк басуы куркыныч, әлбәттә, әмма кирегә юл юк бит.

Иңкүлек аша пар сызык булып сузылган, караеп-калкыбрак торган атлы чана юлы,

Р.Әхмәтшин, Н.Сысоев картиналары



өстән караганда, шактый ук ышанычлы кебек күренде. Әминә, тәвәккәлләп, вак кына адымнар белән алга атлады. Кыз чокыр уртасына кереп җиткән мәлдә, аяк астында нидер чытырт итте. Сәке зурлыгы юл катысы, кызы-ние белән убылып төште. Ул җан ачысы белән: «Батып үләм лә! Кот-ка-рыгыз! – дип кычкырып җибәрде. Аның әрнешле авазы әрәмәлек буйлап өскә, урман ягына таба сузылып менеп китте, ала-кола шәрә басу өстендә кайтаваз булып кат-кат яңгырады. Әрәмәлек уртасындагы ялгыз карамадан, канатларын шап-шоп бәреп, карт козгын күтәрелде, карлыккан ямьсез тавышы белән яман каркылдап, агач астына сузылып яткан үзеише ач бүрегә хәбәр җиткерде:

– Кар-р! Сор-р-ры-кай, тор-р-р! Ят-ма хөр-р-р-рәсән-лә-неп! Бер-р-рәү бат-т-ты бу-г-ай! Шун-нда барр-рыйк! Фор-р-р-саттан фай-да-ла-нып кал-л-лыйк! Там-ак ял-л-гап алыйк!

Тәнне куырып ала торган зәһәр салкын су, әүвәл кызның биленә чаклы җитте, ә бераздан көчәеп күкрәгенә кадәр үрмәләде. Ул, коты алынып, башы өстенә күтәреп тоткан почта сумкасын, бар көченә селтәнеп, алга таба томырды. Сумка лапылдап чокыр кырыена килеп төште. Аллага шөкер! Юкса, Сталин заманының закуннары аяусыз. Әгәр, ачыгавызланып, хатларны-гәзитләрне, пособие-пенсия акчаларын ташуга агызып җибәрә калса, ярь-яшь башыңны Зөя төрмәсендә черетәчәкләрен көт тә тор.

Ургылып төшкән ташу суы менә-менә үз эченә йотып ала дигән мәлдә, кызның гәүдәсен яман авырттырып, сынык җепсә кисәге агып килеп бәрелде. Әминә, мәче җитезлеге белән шуны эләктереп тә алды, ни арада үрә бастырып, су төбенә кадап өлгерде. Агач белән этенеп, җыйнак гәүдәсен пружина кебек атындырып, соңгы көче белән алга томырылды һәм сумкасы янәшәсенә, ләпелдек җиргә килеп төште. Кызның күзләренә кайнар яшь тамчылары бәреп чыкты. Иң мөһиме – ул исән!

Ничек тә тизрәк торып басарга кирәк. Лычма су булган киемнәре галәмәт авырайган. Тешләре тешкә тими барабан кага, бөтен тәне калтырана, аяк-куллары, аркабилләре, берьюлы меңәрләгән энә чәнчегәндәй итеп, көйрәп авырта башлады. Кыз, яңа туган бозау кебек, әүвәл дүртаякланды, аннан соң, үзен мәҗбүр итеп, тырышып-тырмашып, хәле киткән аякларына басты.

Әле авылга чаклы шактый ерак иде. Түзәргә, ничек кенә булса да өйгә кайтып егылырга кирәк. Түр як тәрәзәсеннән күзен алмыйча, газиз баласының исән-имин кайтып керүен әнисе түземсезләнеп көтәдер. Кайтып җитә алса, юеш киемнәрен сыгып, мич башына, аралыкка җәеп әләр, хатларын-гәзитләрен сәке өсләренә, мич кашларына, киштәләргә таратып куеп булса да, ничек тә киптерү әмәлен табар иде әле. Мәтрүшкәле кайнар чәй эчеп җибәрсә, мич уентыгыннан алып, бәрәңге ашап куйса, хәле яхшырмый калмас.

Егәре киткән аякларын сөйрәп алга атлавы мең газап булса да, кыз ничек тә кызурак барырга тырышты. Туктап хәл алырга утырса, ул үзенең бөтенләйгә тора алмаячагын яхшы аңлый иде. Җитмәсә, күтәртмәле чабатасының бер шакмагы урынынан кубып чыкты. Бераз чатанлап атлаганнан соң, җен ачуы белән икенчесен каерып алды, турыдан саз ярып бара башлады. Ниһаять, көч-хәлгә авыл башына килеп җитте.

Басу капкасына сөялеп, бер мизгел уйланып торды. Җиткү кыз, үзенә күз атып, якын итеп, сүз катып йөргән Хәлимнәр турысыннан суга төшкән чебеш кыяфәтендә узарга читенсенде. Тәрәзә аша күреп калуы,

йә капка төбендә очравы бар. Яхшы түгел... Тәвәккәлләп, өенә бакча артларыннан кына кайтырга булды. Ногманнар турында үзәнлек бар-барын, әмма ул Быкыр ермагы кебек тирән түгел лә. Алда – Изгеләр зираты. Анда бу якларга ислам динен таратырга шәһри Болгардан килгән сәхабәләр күмелгән, дип сөйлиләр. Монда алыш булган, дәһриләр мөселманнарның изге канын койган, ди. Дөрестерме-юктырмы, төнлә бу тирәдә утлы өрәкләр биегәнен күрүчеләр булган, имеш. Әнисе аны: «Кызым, Изгеләр зираты яныннан узарга туры килсә, берүк әрвахлар рухына дога кылмыйча үтмә!» – дип, кат-кат кисә килде, югыйсә. Үз хәле хәл булгангадыр инде, мөгаен, Әминә бу юлы анасының киңәшен бөтенләйгә исеннән чыгарды. Гөнаһ шомлыгына, димәсәң, янәдән куркыныч тозакка килеп капканлыгын сизми калды. Монда Ычтапан бияләе чаклы гына әрәмәлек бар. Әүвәле, тал чыбыкларына тотына-тотына, кырын буенча ару гына килде Әминә, артык киң булмаган сулы ермакны, «ә» дигәнче, сикереп чыкты. «Монысыннан да исән-имин котылдым!»-дип куанып, иркен суларга өлгермәде, үр өстендә ят шәүлә барлыгын сизеп алды. Күзләрен күтәреп карагач, әйтерсең лә, кызны елан чакты. Кар таучыгы өстендә, кызыл авызын ачып, озын телен салындырып, үтә дә ябык, әмма зур гәүдәле бүре ыржаеп утыра иде.

– Илаһым, бакча артына кайтып җиткәч, ач бүредән талатканчы, ник Быкыр ермагында гына тончыктырмадың мине? – дип, мышкылдап елап җибәрде кыз.

Ерткыч сак адымнар белән, як-якка чайкалгалап, әкрен генә аңа таба якынлаша башлады. Ул үтә дә хәлсез иде. Йоннары ялтырап тормый, сырты әллә нинди алачола, кабыргалары беленгән аркасына, уйдык-уйдык утраучык булып, ябагасы укмашып каткан, пычрак йон учмалары арык янбашларыннан да чукланып салынып тора. Күзләре алай ук хәтәр ялтырамый кебек, әллә ничек сәер карый сыман. Әллә кызга гына шулай күренә инде? Корсагы астында ике рәт булып тезелеп киткән имчәкләре буп-буш. Кыз аптырап авыл ягына каерылып карады. Күзгә-башка һичкем чалынмады. Карашы белән таллык ягын айкап алды. Шул мәлдә сукмак читендәге кар астыннан бер метр чамасы озынлыктагы корыган ботак очы чыгып торуын шәйләде. Шуны иелеп алганда, кызның күз аллары әлҗемөлҗе килде. Йолкыш булса да, ерткыч бүре белән күзгә күз карашып, монда катып торудан бер мәгънә дә юк. Бәхетең булып, гомерең киселмәсә дә, үпкәгә суык тидерүеңне көт тә тор! Юлда кайтканда, тәне кызыша, юеш киемнәреннән пар күтәрелә иде, ә хәзер аның гәүдәсен тоташ калтыравык алды.

Кыз, бер мизгел уйланып торгач, иреннәрен кысты. Бу яшьтән һич кенә дә шушы имгәк бүре авызына керәсе килми иде. Ятып калганчы, атып кал дигәндәй, ул кинәт тураеп басты. Ни булса, шул булыр, дигәндәй, таягын мылтык шикелле итеп бүрегә төзәп, күзләрен акайтып, дошманының куе соры танавына туп-туры карап, ышанычлы адымнар белән кыргый җанварга таба тиз-тиз атлап китте. Кызның күзләрендә хәтәр чаткылар кабынганын күреп, сизгер бүре ырылдап куйды, аннан туктап калды. Арт санына утырды. Әмма Әминәнең ясалма кыюлыгы биш-алты адым атлаган арада эреп юкка чыкты. Ул тагын күзләрен усал бүрегә текәп катып калды. Күпне күргән ана бүре хәлсез генә шыңшып алды. Ул кызның күз карашындагы әле баярак кына дөрләп янган утлы нәфрәтнең сүнүен, аның гаҗизлеккә алышынуын чамалады. Корбанын Быкыр ермагыннан бирле эзәрлекләгән бүрегә тагылып, ерткыч җанварны күздән язмыйча, астанрак кына очып килгән карт козгын, табигатьнең ике баласы: ана бүре белән яшь кыз арасында сүзсез генә барган үзара тартышуны, һавада әйләнә-тулгана, бик кызыксынып күзәтте. Кемнең җиңәчәген бик тә беләсе килде аның. Киек җанвар өстен чыкса, үләксә калдыкларын чукып, аның да тамагы туячагы көн кебек ачык иде.

Хәзер бүре миңа ташланачак, сары казык тешләрен бугазыма батырачак, селәгәйле авызы белән битләремне, күкрәкләремне, ботларымны умырачак, дип, коты очып уйлады кыз. Күзләреннән эре-эре яшь тамчылары тәгәрәште. Күңеленнән генә әнисе белән бәхилләште ул. Авыл ягына тагын бер каерылып карады. Куркуыннан усак яфрагы кебек калтыранган кыз туңуын сизми иде инде. Ул, бөтен вөҗүде белән Ходайдан ярдәм сорап, авыз эченнән генә пышылдап, белгән догаларын укырга керešте: «Аллаһуммә әхфәзна йа файяз, мин җәмигыль бәлайә вәл әмраз»...

Ана бүренең күз читләре эренләп, юешләнеп тора иде. Корбанының хәленә кергән сыман, гыжылдап, авыр сулап куйды. Әгәр кешечә сөйләшә алса:

– Мин дә синең кебек бичара шул. Туып үскән газиз урманымнан сугыш куып чыгарды. Мәскәү астында туплар шартлый, дөньяның асты өскә килә башлагач, сезнең төбәккә көчкә качып котылдык. Үзеңә бер дә тимәс идем дә бит. Әрәмәлек арасындагы өнемдә ачка тилмереп яткан балаларыма ашатырга, букчаңда берәр нәрсәң юкмы соң, ичмасам? – дигәндәй, нурсыз соры күзләрен кысып, кызга сынап карап

торды. – Безнең мондый хәлгә таруыбызга сезнең авыл кешеләре генә гаепле бит. Гомерлек парымны – зур яллы ата бүрене абзардан сарык бәрәне әләктереп чыгып килгәндә сезнекеләр атып үтерде. Олы хәсрәтемнән җиленемдә сөтем корыды, үзем чирләп егылдым, тәмам йолкыш хәленә калдым. Ялгызым гына өч сабыемны ашатып туйдырулары мең газап. Ач балаларым тәмам хәлсезләнде, бүген урыннарыннан кузгала алмыйча, тилмерешеп ятып калдылар. Синең иртәле-кичле бу сукмактан узуыңны күп мәртәбәләр күргәнем булды. Парым янымда, тамагым тук чакта үзеңә тимәдем ич! Хәзер икебез дә чарасыз мәхлүклар, – дип әйтер иде сыман.

Кыз тирән итеп сулады да тагын бер адым алга атлады. Таягына таянып калмаса, һичшиксез җиргә авачак иде. Ә тәҗрибәле ана бүре нәкъ менә шул мизгелне түземсезләнеп көтә дә инде...

Кинәт авыл ягыннан ачы итеп сызгырган, ярсып эт өргән, һаваны ярып, чыбыркы шартлаткан тавышлар килеп иреште. Табан асты тимерләнгән ат чанасының чыелдап кузгалганы аерымачык ишетелде. Әлеге авазларның ни-нәрсә аңлатканлыгын кыргый киек кыздан алданрак абайлап алды:

«Яллы ата бүрене атып үтерүченең сызгыруы бит бу!» Ул аны, һич ялгышмыйча, йөзләгән аваз арасыннан танып алыр иде. Егетнең башындагы йонлач бүрекнең язгы шаян җил алып килгән үтә дә якын исе танавына килеп бәрелүгә, ана бүренең тәне дерелдәп куйды, күзеннән сыңар яшь бөртеге сытылып чыкты. «Шул бәдбәхет! Газиз балаларының әтисенең башына җиткән явыз аучы! Яхшы чакта моннан таюың хәерлерәк. Аның белән очрашып, сабыйларын тома ятим калдырмас ич инде...»

Йолкыш койрыгын ябык сыйраклары арасына кысып, өмете өзелгән күз карашын каралып ямьсезләнгән карга төбәп, шыпан-шыпан әрәмәлеккә кереп сызды. Карт козгынның: «И-и-и, пеш-ш-мә-гән, авыз-з-зы-на кер-р-р-рәм дип тор-р-рган р-ри-зыкны ыч-кын – дыр-р-ды», – дигән үкенечле авазы һаваны телеп узды.

Ач бүре күздән югалуга, Әминәнең тез буыннары кинәт камырдай йомшарып китте. Ул юеш сумкасын куенына кыскан хәлдә, олаудан шуып төшкән бодай көлтәседәй сузылып, юл читендәге юеш карга ауды. Егет, чанага аякларын аерып баскан көе, утлы чыбыркысын баш өстендә хәтәр болгый-болгый, атын кызга таба куа иде.

– Нәрсә, кабак кәлҗемәсе кебек мәлҗерәп төштең? Бүредән курыктыңмыни, матурым! Тор тизрәк! Салкын тидерәсең бит! Чанага утыр! – дип өзек-өзек боерыклар бирсә дә, кыз кымшанмады. Хәлим тиз

генә чанадан сикереп төште. Калтыранган юеш гәүдәне җәлт кенә көчле кулларына күтәреп алды. Гаҗәпсенеп:

– Нишләп бөтен җирең манма су соң синең? Бәрлегә чумып чыкмагансыңдыр бит? – дип, сорау арты сорау яудырды. Тик аңа җавап бирүче булмады. – Әйдәле, матуркаем, очыртып кына өеңә кайтарып куйыйм үзеңне! – дип, егет ныклы адымнар белән чанасына таба атлады.

Ул аңын җуйган сөйкемле кызга үтә дә ягымлы караш ташлады. Аның нәфис битләреннән, уймак иреннәреннән, ап-ак муеныннан, ефәк чәчләреннән исерткеч яз исе килә иде...



БАТЫРЛЫК ҺӘМ ДӘҺШӘТ КАЙТАВАЗЫ

Луиза Янсуар

Бөек Ватан сугышын кичеп кайткан язучыларның әсәрләре бүгенге көндә онытыларак төшә кебек, нигездә авторларның юбилейлары йә сугышның үз түгәрәк даталары уңаеннан искә алына. Әмма зур һәм тирән тарихи борылышларның кабатланган бер чорында әйләнеп кайтып укып карасак, бик зур гыйбрәт алырлык...

КЕШЕ ЙӨРӘГЕ АША УЗГАН СУГЫШ

Әмирхан Еники – «Кем җырлады», «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Мәк чәчәге» һ.б.

Сугышның беренче көннәреннән Әмирхан Еники рядовой солдат буларак Калинин һәм 1 нче Балтыйк буе фронтларында көрәшә. Сугыш аның йөрәгендә дә, иҗатында да тирән эз калдыра.

Аның сугыш турындагы хикәяләренә бер үзенчәлек хас – әдип турыдан-туры яу кырында барган вакыйгаларны сурәтләми. Ул сугышның кеше психологиясенә ни рәвешле тәэсир итүен, йөрәге аша ничек узуын сурәтләргә омтыла. Сугыш язучы өчен мәңгелек һәм нигез кыйммәтләрне ваемларга бер этәргеч, чөнки нәкъ менә киеренке, критик мизгелләрдә сынала да, бар асылы белән ачыла да адәм баласы.

Яшәү һәм үлем чигендә, сайлау алдында калган каһарманнарын кешелеклелек һәм вөҗдансызлык, гаделлек һәм сатлыкҗанлык, мәрхәмәт һәм тар күңеллелек, галилек һәм түбәнлек критерийлары аша уздыра язучы. Шушылар аша ул үзенең укучысын әхлак темасына алып чыга.

Тагын бер үзенчәлек – сугышның ни дәрәҗәдә яшьнәп торган тереклеккә, матурлыкка, яшәүгә капма-каршы категория булуын күрсәтү, аның кеше табигатен гарипләвенә басым ясау. Шуңа да хикәяләрендә сугыш һәлакәтенә дучар булган геройларны табигать хозурлыгы, шау чәчәктә утырган болыннар, кошлар сайравы, үлән-гөлләрнең гүзәллеге әйләндереп алган...

Кечкенә генә эпизодлар белән детальләрдән олы масштабтагы гомумиләштерүләр, нәтиҗәләргә алып чыга безне Әмирхан Еники. Бу дөньяда яшәүдән дә бөек һәм кадерле берни дә юк дигән инануга.

КАҺАРМАНЛЫКНЫҢ НИГЕЗЕНДӘ НӘРСӘ ЯТА?

Габдрахман Әпсәләмов – «Ак төннәр», «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше», «Агыла болыт» һ.б.

Габдрахман Әпсәләмов сугышка 1941 елда алына. Башта Карелия фронтының диңгез бригадасы составында – миномёт расчёты командиры, разведчик, 1943–1946 елларда – фронт газеталарында хәбәрче. Аннары Япония белән сугышта катнаша.

Дәһшәтле елларны ул үзенең соңыннан язган барлык әсәрләрендә дә чагылдыра, хәтта инде сугыштан соңгы имин елларны колачлаган атаклы «Ак чәчәкләр» романында да. Ә күпчелек әсәрләре нәкъ менә сугыш чынбарлыгы, солдат язмышы, аның эчке кыйбласы, рухи бөтенлеге турында.

Батырлыкның нигезен, чыганакларын ачу юнәлешендә язылган әсәрләре арасында героик совет яшьләрен сурәтли торган «Алтын йолдыз», Бухенвальд лагерена багышланган «Мәңгелек кеше», төп персонажы Газинур Гафиятуллин булган «Газинур», Муса Җәлилгә һәм аның намуслы исемен илгә кире кайтаруга зур көч куйган Гази Кашшафка нисбәтле «Агыла болыт» романнары иҗатында төп урынны алып тора.

Әлеге әсәрләр рус һәм поляк, украин, үзбәк, латыш һ.б. телләргә тәрҗемә ителеп, басылып чыга һәм СССР буйлап тарала.

Владлен Харламовның «Җиңү» картинасы. Фото: tatkniga.ru

УРАУ ЮЛЛАР АША – ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНӘ

Нәби Дәүли – «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион»

Нәби Дәүли Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, әмма 1941 елның августында Орша шәһәре тирәсендә барган авыр сугышларның берсендә чолганышта кала, әсир төшә. 1942 елның яз башында Германиягә озатыла. Башта аны Бухенвальдта тоталар, аннары ул Баден-Баден, Магдебург шәһәрләре янында концлагерьларда михнәт күрә. 1945 елның апрелендә берничә иптәше белән лагерьдан кача, Совет Армиясенә кушыла һәм сугышны фронтта тәмамлый.

1945 елның декабрендә Казанга кайта, әмма аны, немец лагеренда әсирлек кичергән кеше буларак, читкә тибәрәләр – әдәбият һәм матбугат өлкәсендә эшләргә рөхсәт бирмиләр. 1956 елга кадәр ул Казанның төрле оешмаларында кара эшче, каравылчы, рәссам-бизәүче булып эшли. Бастырмасалар да, язу эшен дәвам итә: шигырьләр, поэмалар белән беррәттән, проза һәм драматургия әсәрләре дә тудыра.

Нәби Дәүлинең иң танылган әсәрләре – «Яшәү белән үлем арасында» повесте белән «Җимерелгән бастион» романы. Бу әсәрләр хәзерге көндә дә тәэсир итү көчен югалтмый. Автобиографик материалга һәм әсирлек чорындагы фактурага нигезләнеп язылган бу әсәрләр гомумкешелек турындагы уйлануларга да алып чыга. Нәрсә ул фашизм? Кешелек дөньясы, төрле чорларны узып, цивилизацияле тормышка килеп җитеп тә, ни өчен мондый ерткычлыкка бара ала? Бу сорауларга җавапны без Нәби Дәүлинең язмышлар галереясы аша табабыз һәм тетрәнәбез.

АЛАР ОНЫТЫЛМЫЙ

Ибраһим Гази – «Онытылмас еллар» трилогиясе

Яшьли ятим калып, кечкенәдән үк төрле михнәтләр күреп үскән бу бала Тәтеш балалар йортында тәрбияләнә. 20 нче елларда әдәбиятка килә, инде каләме ныгыган язучы буларак, 1943 елда сугышка керә. Күзләре начар күргәнгә, аны фронтта татар телендә чыга торган «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарына хәрби корреспондент итеп билгелиләр.

Ибраһим Гази иҗатының иң югары ноктасы узган гасырның 50-60 нчы елларына туры килә. Сугыш вакыйгаларына ул хикәя-повестьларында да әйләнеп кайта, бу хакта публицистик язмаларында да еш уйлана. Әмма аның исемен татар әдәбиятының алтын фондына кертеп калдырган, чын мәгънәсендә масштаблы тарихи-иҗтимагый полотно буларак бәяләнә торган әсәре – «Онытылмас еллар» трилогиясе.

Бу әсәрен әдип гомере буена эшли. Аның беренче өлеше «Балконлы йортта» исеме белән 1934 елда ук басылып чыга. 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Авыл җыены», «Патшаны төшергәч», «Озын Миңнулла» исемнәре астында тагын аерым бүлекләре дөнья күрә. Сугыштан соң автор үз күңелендә күптәннән яшәгән эпик әсәренә яңадан әйләнеп кайта.

1949–1966 еллар дәвамында бер-бер артлы аның өч кисәген («Малай чак», «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт», «Канатланыр чак») бастырып чыгара. Трилогия аерым-аерым китаплар рәвешендә рус телендә дә дөнья күрә.

«Онытылмас еллар» трилогиясе өчен Ибраһим Гази 1969 елда ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.



СУГЫШ ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ БАРЫСЫН ДА САНЫЙ БАШЛАСАК, КУЛДАГЫ БАРМАКЛАР ГЫНА ҖИТМӘС. ШУЛАР АРАСЫНДА ИҢ БИЛГЕЛЕ, ҮЗ ЧОРЫНЫҢ ЙӨЗЕН БИЛГЕЛӘГӘН КАЙБЕРЛӘРЕНӘ ГЕНӘ ТУКТАЛАБЫЗ. БОЛАРНЫ ҺӘР ТАТАР УКУЧЫСЫ ҮЗ ГОМЕРЕНДӘ БЕР МӘРТӘБӘ БУЛСА ДА УКЫРГА ТИЕШ, ДИП УЙЛЫЙМ:

Муса Җәлил – «Моабит дәфтәрләре»

Гомәр Бәширов – «Намус» романы

Шәйхи Маннур – «Муса» романы

Мирсәй Әмир – «Саф күңел», «Ялантау кешеләре» романнары, «Миңлекамал» пьесасы

Мөхәммәт Мәһдиев – «Кеше китә – җыры кала», «Фронтовиклар», «Без – кырык беренче ел балалары» повесть-романнары

Фатих Кәрим – шигырьләре һәм «Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы» һ.б. поэмалары, «Шакир Шагиев» пьесасы, «Язгы төндә», «Разведчик язмалары» повестьлары

Хисам Камалов – «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» повесть-романнары

Шамил Рәкыйпов – «Кайда син, Жан?», «Таңнар һаман матурмы?», «Кызлар-йолдызлар» повесть-романнары

Фатих Хөсни – «Йөзек кашы» повесте

Нурихан Фәттах – «Кырык дүртнең май аенда» повесте

Риза Ишморат – «Дошман лагеренда», «Ватан кызлары», «Кайту» пьесалары

Гадел Кутуй – «Сагыну», «Без – сталинградчылар» нәсерләре, «Рөстәм маҗаралары» фантастик повесте

Хәсән Сарьян – «Бер ананың биш улы» повесте

Ибраһим Гази – «Онытылмас еллар» трилогиясе

Сибгат Хәким – шигырь цикллары һәм «Сары капкалы йорт», «Курск дугасы», «Дала җыры», «Бакчачылар», «Әзлиләр Европа буйлап» поэмалары

Казанныбызда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

ИГЪТИБАР!
ТАССР Министрлар Советының 1987 елның 27 июлендәге карары белән Казанның тарихи һәйкәлләре һәм мәдәни объектлары исемлегенә кертелә.

Габитовлар йортының элеккеге халәте.

ӘДӘБИЯТ, ТЕАТР ҺӘМ ИНКЫЙЛАБЛАР КАЙНАГАН ЙОРТ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Казан шәһәренең иң аулак, тын Ульянов урамы инкыйлабка кадәр Беренче Тау (Первая Гора) дип йөртелгән. Биредә сакланып калган агач йортлар әле байтак. Шуларның берсе – 31 нче йорт – Кытайдагы Мәскәү илчелегендә хезмәт куйган, соңыннан билгесез рәвештә юкка чыккан Шәрәфетдин Габитов йорты.

«Шимбәчеләр». Утыралар (сулдан уңга): Г. Мостафин, Ә. Терегулова, Р. Мәликов. Басып торалар (сулдан уңга): Х. Ямашева, М. Терегулова, Х. Ямашев.

XIX гасырда бу территорияне актив үзләштерә башлыйлар. Төзелеш планы 1839 елда губерна архитекторы Фома Петонди тарафыннан раслана.

Асты таш, өсте агачтан эшләнгән типик Казан сәүдәгәр утары булган йорт ул – әллә ни чуар бизәлмәгән, тәрәзә йөзлекләре дә гадәти кәрнизләрдән гыйбарәт. Әмма аның уникаль мәдәни-иҗтимагый тарихы бар.

«ШИМБӘЧЕЛӘР» БИШЕГЕ

XX гасыр башында Бу йортта 1903 ел ахырында бертуган Исмәгыйль һәм Гариф Габитовлар «Шимбәчеләр» әдәбият-сәнгать түгәрәге оештыра. Түгәрәккә демократик фикердәге татар зыялылары, шәкертләр йөри. Гадәттә шул чор татар интеллигенциясе яшәгән йортларда җыеннар уздырыла торган була: Терегуловлар, Әхмәровлар һәм менә Габитовлар. Шимбә очрашалар, атамалары да – шуннан.

1903 елның кышында шимбәчеләрнең театр труппасы Фатих Әмирхан һәм Газиз Гобәйдуллин җитәкчелегендә Габитовлар йорты-

Фото: Александр Ефремов

ның икенче катында татар телендә беренче өй театры уйный. Галиәсгар Камалның төрек язучысы Нәмикъ Кәмал әсәренә нигезләнгән «Кызганыч бала» спектакле була ул. Тамашачылар – түгәрәк әгъзаларының туган-тумачалары, якыннары һәм дуслары.

Әйтергә кирәк, Габитовлар йорты Гафур Коләхмәтов, Шәриф Сүнчәләй, революционерлар Мулланур Вахитов, Хөсәен Ямашев һ.б. кебек XX йөзнең күренекле шәхесләрен дә хәтерли.

РСДРП (Б) ФАТИРЫ

1905 елдан Габитовлар йорты (ул вакытта инде сәүдәгәр Сухановларныкы) РСДРП (б) Казан комитеты фатирына әверелә. Бу йорт революцион вакыйгалар белән тыгыз бәйле. Йорт флигелендә 1908–1918 елларда комитетны оештыручыларның берсе – Абрам Комлев яши.

Революциядән соң йорт күпфатирлыга әверелә. Ул хәзерге көнгә чаклы шулай булып кала. ТАССР Министрлар Советының 1987 елның 27 июлендәге карары белән Казанның тарихи һәйкәлләре һәм мәдәни объектлары исемлегенә кертелә, сакларга тиешле урын дип табыла.

БУЛМЫЙ КАЛГАН МӘДӘНИ КОМПЛЕКС

Шәрәфетдин Габитовның оныгы, соңыннан Австралиядә гомер иткән шагыйрә Ләйлә Садри (Габитова) шушы йортта туа. Габитовларның нәсел дәвамчыларыннан кем Кытайда (Ильяр Габитов), кем Казахстанда (Торсынтай Габитов) төпләнгән.

2000 нче еллар башында Габитовларның Кытайда, Австралиядә һәм Казахстанда яшәүче токымнары Татарстан җитәкчелеге алдында бабалары йортын кире кайтару мәсьәләсен күтәрә. Үз хисапларына төзекләндереп, мәдәни комплекс – мөһаҗирләр музее, кунакханә, татар ашлары йорты ачып, Казанның 1000 еллыгы хөрмәтенә шәһәргә бүләк итмәкче булсалар да, эш барып чыкмый.

2023 елда йорт капиталь ремонт кичерә: су бирү системасын, түбәсен, фасадын төзекләндерәләр. Әлегә ул үз урынында тыныч кына тора бирә. Без фотога төшерергә килгәндә, йорт каршына асфальт җәяләр иде, бик таптанып йөрергә ирек бирмәделәр. Шулай да без аны объективка эләктереп алдык – калсын тарих өчен, дидек.

АЛТЫНЫГЫЗНЫ КЫЙММӘТКӘ САТЫГЫЗ, АКЧАСЫН ШУНДА УК АЛЫГЫЗ!

• КАЗАНДАГЫ ФИЛИАЛЛАРЫ • ЗӘРКӘНЧЕ ӨЕГЕЗГӘ БУШЛАЙ КИЛӘЧӘК •

583/585 нче келәймә – 1 г өчен 4500 сум, 750 нче келәймә – 1 г өчен 6500 сум. Тәңкәләр, көмеш, стоматология коронкалары – кыйммәт хактан.

ШУНДА УК АКЧА АЛЫРГА ЯИСӘ КАРТАГА КҮЧЕРТТЕРЕРГӘ БУЛА!

8 (800) 551-84-34

Зәркәнчене чакыру

«Аурум» алтын һәм зәркән эшләнмәләрен сатып алу компаниясе – бу өлкәдә иң зур федераль компанияләрнең берсе. Ул зәркән эшләнмәләрен дәүләт үрнәге буенча кабул итә. Алтын валютасы биржасына йөз тота, заманча төгәл итеп бәяли.

«Аурум» компаниясе рәсми рәвештә эшли, Федераль пробир палатасының лицензиясенә ия.

1. «Аурум» компаниясенә мөрәҗәгать итүнең өстенлекләрен һәм уңайлыкларын карап узыйк.

«Аурум» федераль челтәре биржада теркәлгән бәягә йөз тота, дәүләт үрнәгендә эшли, штатында һөнәри яктан әзерлекле зәркәнчеләр тупланган. «Аурум» компаниясе сезнең алтынга, зәркән эшләнмәләренә һәм кыйммәтле металлга, алар нинди генә хәлдә булса да, югары бәя тәкъдим итә. Сатып алганда, «Аурум» алтынның авырлыгын гына түгел, ташларның бәясен дә исәпкә ала. Сатып алганда бәясе күп тапкырларга югары була. Сез шунда ук алтын һәм зәркән эшләнмәләрегезгә иң югары хак аласыз, шунда ук акча алырга яисә картагызга күчерттерергә була.

2. «Аурум»га алтын сатуның үзенчәлеге нидә?

Россиядә алтын сатып алу буенча иң зур федераль челтәрләрнең берсе. Үзенең зәркән кибетләре бар. Эшләнмәләрнең бер өлеше шунда сатыла. «Аурум» компаниясенә тапшырылган эшләнмәләргә шактыйга күбрәк акча алачаксыз, чөнки аларның бер өлеше аның үз кибетләрендә сатылачак, алтын ватыгы буларак кулланылмаячак.

3. «Аурум» компаниясе өегезгә килеп сатып алу мөмкинлегенә ия.

Сезнең уңайлык өчен яңа сервис. Безнең югары һөнәри осталыкка ия булган зәркәнче (фотода ул үзе, алай тынычрак, шулай бит?) бушлай сезгә уңайлы вакытта өйгә, эшкә килә ала, кафеда очрашу билгеләргә була. Үзендә кирәкле бөтен кораллары да бар, сезнең алда бәяли, сорауларыгызга җавап бирә.

Өегезгә килеп сатып алу – бу никадәр уңайлы? Укучыбыз Расторгуева Валентина Ивановнадан сорыйбыз:

– Шалтыраттым. Күңелгә ятышлы яшь кенә бер егет килде. Чәй белән сыйладым. Артём өстәлгә үзенең эш коралларын чыгарып тезде. Ничек итеп келәймәсен билгеләвен, кыйммәтле ташларны бәяләве турында сөйләде. Бик мавыктыргыч. Гәпләшеп алдык... Ахыр чиктә, миңа иске, инде кулланылмый торган йөзек һәм алкаларым өчен 73 000 сум тәкъдим итте. Ризалаштым, акча шунда ук картага килде. Биредә намус белән эшлиләр!

«Аурум» компаниясе турында тулырак мәгълүмат белән www.aurum-skupka.gold сайтында танышырга була

БУ ИГЪЛАННЫ КҮРСӘТЕГЕЗ ҺӘМ ӨСТӘМӘ 500 СУМ АЛЫГЫЗ!

Казан: «Тукай мәйданы» метро станциясе, Пушкин ур., 5/43 йорт

Лицензия – Л023-00119-77/00389972 2021 елның 22 декабреннән
РЕКЛАМА. «АУРУМ» ҖЧҖ. ОГРН: 1207700387245. Юр. адресы: 127051, Мәскәү ш., Петровка ур., 26 йорт, 2 корылма, 1 подвал, 29 бүлмә.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

AIGUL.USMANOVA
КЕЙТЕРИНГ

Мәшәкатьсез генә матур һәм мул өстәл. Хәләл ризык

Аш тактасына зәвыклап тезелгән ризык

Безгә иң мөһим чараларны ышанып тапшыралар

Казан, Крутая ур., 3
+7 (843) 203-45-00
+7 (937) 154-00-16

kazan.aigul-usmanova.ru
aigul.usmanova_kazan
aigul.usmanova1

*Айгуль Усманова
Реклама. ИП Усманов Линар Марселевич